Безнен МИРАС

04

апрель 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Без – мираслы халык!

23 мартта «Яңарыш» республика фонды биш еллыгын билгеләп узды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Яңарыш» фондының Химаячеләр Советы рәисе Минтимер Шәймиевка Рәхмәт хаты тапшырды, ярдәм күрсәткән иганәчеләргә олы рәхмәтен җиткерде.

С.Исхаков фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнен МИРАС 12 +
04(39)
апрель 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан гамәлгә куелды. 2012 елның май аеннан чыга.



74

28 **КЕМНӘР СОҢ БЕЗ — ТАТАРЛАР?**
Рабит Батулла

71 **ЖУКОВ ШОФЁРЫ.**
Морад Дусай

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Йөрәгемдә йөртәм сине.** *Гамил Афзал*

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

4 **Кытай татарлары: мәдәният, тарих һәм хәзерге заман** *(Түгәрәк өстәл)*
16 **Кытайда татар мәктәпләре.** *Әлфия Йосыпова*
21 **Ата-баба васыяте.** *Марат Закир*
24 **«Нинди батыр бала!»** *Гөлчирә Ханнанова*
26 **Габдулла әфәнде Тукай.** *Хатип Халиди*

ТАРИХИ МИРАС

28 **Кемнәр соң без — татарлар?** *Рабит Батулла*
35 **Ш.Мәрҗани мирасында татарларның милли һәм дини тормыш-көнкүреше.** *Илдус Заһидуллин*
39 **«Шиһабетдинемез бер иде...»** *Ленар Гобәйдуллин*
44 **Мәрҗанинең йорт тормышындагы кайбер гадәтләре.** *Зәйнәп Кәримия*
46 **Олуг галимебез шәех әл-Мәрҗани хәзрәтләре хакында хатирәләрем.** *Габдулла бине Гобәйдулла*

ТАТАР ГАМЕ

48 **«Усал эт төсле тик чәйнәш...»** *Заһир Шәйхелисламов*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

52 **Төрки дөнья һәм дөньяга караш.** *Рафаэль Мөхәммәтдинов*

ҖИҢҮ — 70!

58 **Җиңү алып килгән татар генералы.** *Александр Филиппов*
65 **Фронтовик артистлар.** *Рәдиф Сәгъди*
71 **Жуков шофёры.** *Морад Дусай*

ӘДӘБИ МИРАС

74 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
79 **Кирпеч ясаучы Шапур һәм Хуҗа Мозаффар хикәяте.**
85 **«Тукай мондый түгел иде...»** *Ләлә Мортазина*
87 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
88 **Тукай турында истәлекләр.** *Вафа Бәхтияров*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

94 **Үз халкының баласы иде...** *Тәлгат Галиуллин*
100 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

101 **Татар түбәтәйләре.** *Руфия Мөхетдинова*

СӘНГАТИ МИРАС

102 **Кемнәр идек, кемнәр булдык...** *Ләбиб Лерон*

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

106 **Кояшлы рәссам.** *Дания Гайнетдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

110 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның апрель ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ТАБИГЫЙ МИРАС

116 **Татар имәне**

ШАЯН МИРАС

117 **Көлке көлә килә...**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Апрель*

Заказ №О-836. Тираж – 1577 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 01.04.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Солтан Исхаков һәм Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Сөембикә-ханбикә». 1999 ел. Киндер, майлы буяу. *К.Муллашев рәсеме*



Гамил Афзал
(1921-2003)

ЙӨРӘГЕМДӘ ЙӨРТӘМ СИНЕ

…Ял иткәндә,
Ятып укыйм кичтән сине.
Тору белән, алып укыйм иртән сине.
Ак кәгазьдәй намусыма судья итеп,
Гомер буе йөрәгемдә йөртәм сине.

Тукай — остаз, Тукай — шагыйрь, Тукай — ага,
Кызыл гөлләр башын игән сиңа таба;
Идел суы, синең яннан узган чакта,
Дулкыннарын әкрен генә ярга кага.

Җырларыңа хозурланып, ил шатлана,
Бүрек салып керәбез без җыр бакчаңа;
Яшең белән сугарылган бу гөлләргә
Баккан саен, сабыйлардай, җан сафлана.

Күңелләрдә озак еллар, озак еллар
Янып торган, уйнап торган нурларың бар;
Туган илнең ташларына хисең белән
Ядкяр итеп уеп язган юлларың бар.

Туган халкым йөрәгенең ярасы син,
Ил алдында ил күзенең карасы син;
Токымнарың юлларында юлдаш булып,
Халык белән мәңгелеккә барасың син.

КЫТАЙ ТАТАРЛАРЫ: МӘДӘНИЯТ, ТАРИХ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ

30 гыйнварда «ТАТМЕДИА» АҖнең конференц-залында «Безнең мирас» журналы редакциясе «Кытай татарлары: мәдәният, тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл» уздырды. Утырышта «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры урынбасары **Сөмбел Таишева**, «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры киңәшчесе, Татарстанның халык шагыйре **Равил Фәйзуллин**, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев**, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, язучы **Вахит Имамов**, КФУның Россия тарихы һәм якын чит илләр кафедрасы профессоры, тарих фәннәре докторы **Диләрә Госманова**, КФУның татар филологиясе һәм мәдәниятара коммуникацияләр бүлеге мөдире, профессор, филология фәннәре докторы **Әлфия Йосыпова**, академик Миркасыйм Госмановның (1934-2010) хатыны **Салисә** ханым **Госманова**, Кытай татарлары **Фәрит Мөслимов** белән **Нурмөхәммәт**, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** катнашты.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Барчабызга да мәгълүмдер ки, татарлар дөньяның барлык кыйтгаларында яши: Америка, Австралия, Финляндия, Германия, Төркия, Польша, Балтыйк буендагы илләр, Гарәбстан... Һәм, әлбәттә, Кытай. Бүген сүзебез, аерым алганда, Кытайда яшәүче татарларга нисбәтле булыр. Кытайда якынча биш меңнән артык татар яшәве билгеле (чагыштыру өчен: Америкада — 1 мең, Төркиядә — 25 мең, Финляндиядә — 1 мең тирәсе, Азия белән Австралиядә — 1 меңгә якын, Германия, Польша һәм Европаның башка илләрендә 8 мең чамасы милләттәшебез гомер итә. — Ред.). Безнең бай мирасыбызның бер өлеше чит ил (шул исәптән — Кытай) архивларында һәм китапханәләрендә саклана. Ул мирасны барлау, аны җентекле өйрәнү һәм халкыбыз хозурына кайтару — безнең изге бурычларыбыздан берседер...

Разил ВӘЛИЕВ:

— Татар халкын сигезме, унмы, уникеме миллион, дип саныйбыз. Әмма аның бер өлеше генә Татарстанда (2 миллионнан аз гына артыграгы) яши, миллион ярым чамасы — Башкортстанда, калганы — Россиянең төрле төбәкләрендә, төрле илләрдә. Дөньяның кайсы гына иленә барсам да, татар эзләмичә калганым һәм татар тапмыйча кайтканым булмады... дисәм... фәкать Көньяк Кореяда гына татар таба алмадым. Моңа, мөгаен, вакытым җитмәү сәбәп булгандыр. Япониядә дә татарлар белән очраштым, Англиядә дә, Америкада да, Канадада да, Финляндия, Төркия, Германиядә дә... Бөтен җирдә татар бар. Без бу татарларны һәрберебез күз уңында тотмасак, аларны белеп кенә түгел, аларны өйрәнеп кенә түгел, алар белән һәрвакыт элемтәдә тормасак, минемчә, безнең халкыбызның бөтенлеге булмас иде һәм без, зур халык буларак, киләчәктә яшәүгә дәгъва да итә алмас идек.

Менә шушы турыда уйлаганда бернәрсә хәтергә килә. Без гаиләдә сигез бала идек, янә — әткәй-әнкәй, әбибабай. Әби һәрвакыт дисбе тартып утыра иде. Бервакыт шуның җебе өзелеп китте дә 99 төймә идәнгә чәчелде. Без апа белән төймәләрне җыя башладык, җыйгач, бер җеп алып, төймәләрне тездек. Әби, әлеге дисбене тартып карады да, аны бер читкә куеп, башкасына үрелде. Гаҗәпләнеп, сорау бирдек: «Әби, нигә безнең дисбе белән укымыйсың?» — дибез. «Улым, ул дисбенең бер төймәсен югалткансыз, — диде әби, — бер төймәсе җитмәгәч, ниятем дөрес булмый, Аллаһы Тәгалә аны кабул итми», — ди. Мин моны ни өчен әйтәм? Дөньяның төрле төбәкләренә сибелгән татарлар да шул дисбенең төймәләре шикелле. Әгәр дә без аларның берсен генә югалтсак та, иманыбыз түгәрәк булмас, догабыз кабул кылынмас.

Мин инде Кытайга барырга күптән хыялланып йөри идем. Иң беренче чиратта, анда Миркасыйм ага Госманов яшәгән, ул укыган җирне күрәсем килә иде, чөнки без аның белән бик тә якын идек, һәрвакыт аралашып яшәдек, фикердәшләр булдык. Бервакыт мине ул анда алып барырга кодалап та карады, әмма билетлар, виза алынгач та, Дәүләт Советында эшләрем чыгып, анда бара алмый калдым. Алар «Кара алтын» банкы идарәсе рәисе Ринат Абдуллин белән икесе барып кайтты.

Сәфәрләре турында бик тә мавыктыргыч итеп, матур итеп сөйләделәр. Миркасыйм аганы кайда гына очратсак та, нинди генә мәҗлес булса да, ул Кытай, Голҗа турында сөйләмичә калмый иде. Минем өчен кытай татарлары нинди дер әкият илендә яшәгән кешеләр сыман тоелды. Барып карагач, мин аның чыннан да шулай икәнлегенә инандым. Иң сокландырганы — андагы татарларның мәгърифәтле булуы. Мин анда бозылып, азып-тузып йөргән бер генә татар кешесен дә күрмәдем.

Татар бөтен җирдә дә гыйлемле булган, бар җиргә дә мәгърифәт нуры чәчеп йөргән. Моннан дүрт ел элек бугай, Туфан ага Миңнуллин белән без Казандагы бер төрек гаиләсенә ифтар мәҗлесенә бардык. Шунда бу төрек кешесе безгә бер вакыйга сөйләде. XIX гасыр азагында татар мөһаҗирләре, Төркиягә күченгән вакытта, Кара диңгез буена килеп җиткәннәр. Көймә белән диңгезне кичеп чыгарга кирәк, әмма көймәдә урын аз, боларның әйберләре бик күп икән. Әйткәннәр: барыбыз да сыеп бетик, дисәгез, сезгә икешәр генә төенчек алырга туры киләчәк. Шулай иткәннәр. Утырганнар. Теге ярга чыккач, төенчекләрен чишеп җибәрсәләр, бер төенчектә — самавыр, икенчесендә — китап, ди. Менә бу — татар халкын күзалларга мөмкинлек бирә торган бер күренеш. Татарның һәрбер җиргә, әйтик, Кытайга барганда да, бер төенчегендә — самавыр, икенчесендә китап булгандыр. Алар матди якны кайгыртып, үз гаиләләрен киендерү, йорт салу белән генә шөгыльләнмәгән, иң әүвәле мәчетмәктәп сала башлаган, китап, газета-журнал чыгарган. Шул сәбәпле, кая гына барсаң да, татарны мәгърифәтле, гыйлемле халык, диләр. Төрекләр дә, татар ул — галим халык, ди. Кытайда да без шуны ишеттек. Анда, әйе, 5-6 мең чамасы татар яши. Бу — Кытайда иң аз санлы милләтләрнең берсе. Әмма Кытайдан килгән кешеләр минем сүземне җөпләр: статистика мәгълүматлары буенча, андагы татарлар белем, мәгърифәтлелек ягыннан

беренче урында тора. Алар: «*Без аз, әмма без Кытайның зур казандагы ашына салган бер чеметем тоз шикелле: әгәр дә ул тоз салынмаган булса, Кытайның ашы тәмле булмас иде*», — дип горурланып сөйли. Чыннан да, алар үзләренең дә кадерен белә һәм аларның да кадерләрен беләләр.

Анда казакъ, уйгыр шагыйрьләре белән очраштым. Аларның татар әдәбиятына булган мөнәсәбәтләре мине аеруча шатландырды. Уйгыр шагыйрьләре Тукайны татарча да, уйгырча да яттан сөйли. Бездә әле ул дәрәҗәдә беләләр микән? Ә Кытайда уйгырлар татар әдәбиятын, бигрәк тә Тукайны искиткеч яхшы белә. Гыйззәтулла әфәнде Хәсән сөйләве буенча, Тукайның «Эшкә өндәү» шигыре, кытай теленә тәрҗемә ителеп, андагы дәреслекләргә дә кергән. Бу татарга булган мөнәсәбәт турында сөйли.

Мине тагын бернәрсә — андагы татарларның башка милләт кешеләре белән аралашканда үз-үзләрен югалтмаулары шатландырды. Без, мәҗлестә бер генә урыс кешесе утырса да, алар җырын җырлый башлыйбыз, аларча сөйләшә башлыйбыз. Көннәрдән беркөнне, кич белән Голҗа урамы буйлап барганда, ресторанның тәрәзәсеннән татар җырын ишеттем. Монда татарлар җыелып мәҗлес үткәрә икән, дип, кызыксынып, ресторанга кердем. Керсәм, анда бер татар да юк, кытайлар гына, һәм алар «Ай урагын салып иңбашына», дип татарча җырлап утыра. Шаккаттым: Кытай татарлары шулкадәр зур халыкка да үзләренең җырларын өйрәтә алган! Миллиард ярым исәпләнгән кытай Голҗа шәһәрендә татар җырын җырлый! Россиядә башка милләт кешеләре татар җырларын җырлыймы икән? Бу — бик зур нәрсә. Димәк, татарга хөрмәт, ихтирам бар. Ихтирам булсын өчен үз-үзеңне күрсәтә белү, үзең белән горурлана, үз бәяңне белү кирәк. Юлга кузгалганчы, бер дустым көлемсерәп кенә әйткән иде: нигә Кытайга барып йөрисең, андагы 5-6 мең татар күпмени инде ул? Мин аңа: әгәр дә 5-6 мең сарык булса, ул бик аз, әгәр дә 5-6 мең арыслан булса, ул бик күп була, дидем. Менә мин дә, Кытайга барып, 5-6 мең арыслан күреп кайттым.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Биредә Миркасыйм ага Госманов белән ярты гасырдан артык бергә гомер иткән шәхес утыра. Ул — хөрмәтлебез Салисә ханым. Ни кызганыч, аңа Кытайда, ире Миркасыйм туган Голҗада беркайчан да булырга туры килмәгән... Вәләкин ул Голҗа татарлары, аларның язмышы, яшәеше турындагы күп нәрсәләрне Миркасыйм агадан ишетеп белгәндер...

Салисә ГОСМАНОВА:

— Миркасыйм белән гомер иткәнемә бик шат мин. Нинди кеше белән гомер итүең турында башта әллә ни уйламыйсың икән! Инде менә еллар узгач, Миркасыймнан аерылгач кына, нинди шәхес белән яшәгәнемне аңладым. Безне кавыштырган өчен Ходай Тәгаләгә бик зур рәхмәт! Миркасыйм Казанда 52 ел яшәде. 1958 елда килгән иде. 2010 елда вафат булды. Урыны җәннәттә булсын! Дөрес, ул туган-үскән җирләрен сагына иде. Җәй вакытларында алар тау өстенә җәйләүгә китә торган булганнар, ауга йөргәннәр. Аның күзе бик үткен иде. Әллә кайдагы нәрсәне дә күрә иде ул. Шулчакларда ауга йөрүе турында кат-кат, сагынып-сагынып сөйләр иде. Йөргән-күргәннәрен китаплар итеп язды...

Миркасыйм: «Мин татар халкы өчен эшлим», — диде. «Шәхесләребез» сериясеннән китаплар чыгара башлаганда, мин: «Миркасыйм, бу эшне үзең генә башкара алмассың», — дип әйттем. Ул исә: «Күпме башкара алам,

шуның кадәр эшлим», — диде. 70 яшендә кафедрасыннан китте. Күңележаны белән тулаем «Шәхесләребез»гә күчте.

Миркасыйм тормышны, халыкны, дус-ишләрен, казакъча һәм уйгырча җырларны бик ярата иде. Ел саен Илһам Шакиров катнашында уза торган сәйранга — Аккош күленә җыелдык. Кунаклар арасында Миркасыйм үзе дә җырлап җибәрә иде. Миркасыйм белән бергә урамга чыккач, баш иеп исәнләшеп китүчеләр байтак була иде. Миркасыйм, сине белмәгән кеше бу Казанда, Татарстанда юктыр, дип әйтә идем. Кая барсаң да аны беләләр, чит илгә күп йөрде, анда да дуслары бихисап булды...

«Шәхесләребез» сериясеннән Миркасыйм турындагы китап чыкканга барыбыз да бик шатбыз. Мин бу китапны күрә аламмы-юкмы, диеп яшәгән вакытта кулыбызга төште ул. Сәхифәләрен кат-кат актарам. Бик сагынабыз аны, балалары, оныклары сагына... Гомер итәрлек исәнлеге бар иде... Йөрәге түзмәде... Эшендә яныпкөеп йөрде.

2005 елда Казанга укырга Кытай балалары килде. 25 кеше булганнардырмы... Барысын да Товарищеская урамындагы химия-технология институтының бер ташландык бинасына урнаштырдылар. Берзаман бер бала авыргач, мине чакырдылар да, шунда бардым. Баргач, шаккаттым: болар шулкадәр мескенлеккә төшкәннәр ки! Шуннан бик ярсып өйгә кайттым. Миркасыймга сөйләдем. Миркасыйм бу хакта Разил Исмәгыйль улына әйтте. Туфан Миңнуллин килде, институттан кешеләрне чакырдык. Алар белән каты гына сөйләштеләр. КХТИ җитәкчелеге, яхшы ремонт ясыйбыз, дип сүз бирде. Казанның меңьеллыгы вакыты иде ул. Аларны кайдадыр бер урман эченә илтеп ташлап, бәйрәм итәргә дә чыгармаганнар. Мин әйтәм, болар җинаятьчеләр түгелдер бит инде, нигә аларга Казан татарлары белән бергә бәйрәм итмәскә? Шундый вакытта үзем дә аларга күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итәргә тырыштым: савыт-сабаларны, кием-салымнарны, аннары урын-җирләр биреп булыштым. Алар мине хөрмәт итәләр, барысы да рәхмәт әйтәләр, Аллага шөкер. Хәл кадәри ярдәм итәргә тырыштык. Күбесе укып, зур кешеләр булды. Монда чебешләр кебек килгәннәр иде, бөркетләр булып киттеләр. Бик уңган, тырыш халык алар. Әле дә мине онытмыйлар: яныма киләләр, бәйрәмнәрдә тәбриклиләр. Дөрес, араларында бозылып, бераз тәртипсезләнеп йөрүчеләр дә булгалады...

Берзаман Миркасыйм бик матур әйбер оештырды: Корбан бәйрәме, Ураза гаете көннәрендә аларның барысын да җыеп кунак итә башладык. «Аларны ятим итмик, алар читтә мосафир булып йөрмәсеннәр, монда килсеннәр, без җылылык күрсәтик», — диде. Бүгенгә кадәр, Аллага шөкер, бу традиция дәвам итә.

Разил ВӘЛИЕВ:

— Салисә ханым, кайвакытта бозылып йөрүчеләре дә булды, дидегез. Алар ректорга, деканга әйтәбез, дисәң дә, әти-әниегезгә әйтәбез, дисәң дә курыкмыйлар, ә Миркасыйм агага әйтәм, дисәң: «О-о-о, юк-юк, берүк, берүк әйтә күрмәгез!» — дип ялваралар иде.

Салисә ГОСМАНОВА:

— Дөрес, Миркасыймны бик хөрмәт иттеләр. Миркасыйм: «Биш кеше генә калсын, биш кеше генә һөнәр алсын, белем алсын. Шуңа да без риза», — ди иде.

Разил ВӘЛИЕВ:

— Бүгенге көндә Миркасыйм ага укыган мәктәп исән. Әлеге татар мәктәбе — бик матур мәктәп. Уйгырлар, татарлар, казакълар, бергәләшеп, киләчәктә анда мәгърифәт музее ачарга хыялланып йөри иде.

Әлфия ЙОСЫПОВА:

— Әйе, заманында бинаны җимерүдән саклап кала алганнар...

Разил ВӘЛИЕВ:
— Чынлап та, бик матур мәктәп!.

Ләбиб ЛЕРОН:
— Салисә ханым Миркасыйм ага турында бик матур китап чыгуы турында әйтте. Узган ел август ахырында үткәрелгән «Төрки телле әдәби журналлар форумы»нда катнашучыларга «Җыен» фондының башкарма директоры Фуат абый Рафиков бу затлы китапны бүләк итеп өләште. Әле шушы утырыш башланыр алдыннан гына Диләрә Миркасыйм кызы: «Әти турында тагын китап чыгарырга җыенабыз», — диде. Ходай насыйп итсен!

Диләрә ГОСМАНОВА:

— Разил әфәнде Кытайда булуы турында әйтеп китте инде. Ул әтием күргән, әтием йөргән җирләрдә булган. Ни кызганыч, безгә андый бәхет эләкмәде. Әтием 2000 елда барган чакта безгә барырга мөмкинлек булмады. Аннары, сәламәтлеге начарлану сәбәпле, бара алмады.

«Шәхесләребез» сериясендәге җыентыкка мин аның Кытайга баруы турындагы юлъязмасын махсус керттем. Әти шул язмасында болай ди: «Бу минем туган-үскән җир белән күрешү дә, саубуллашу да. Бу минем соңгы сәяхәтем булыр!» Әйтерсең лә, ул башка бара алмаячагын сизгән.

Әтием, бәлки, Кытайда татар тарихын иң әйбәт белүче кешеләрдән булгандыр. Ул үзе дә шунда үскән. Икенче яктан, зур галим, тарихчы, материалларны яхшылап өйрәнүче кеше буларак та, әһәмиятле китап язган*. Әлеге китабы хәзер дә актуаль булып кала килә. Кытай татарлары тарихын белергә теләгәннәргә мин, беренче чиратта, шул китапка янәдән мөрәҗәгать итәргә өндәр идем.

Кытайда татарлар ике зур төркемнән гыйбарәт. Бер төркеме Төньяк-көнчыгыш Кытайда, Маньчжурия якларында урнашкан. Икенче төркем — Көнбатыш Кытайда Шәркый Төркестан яки Шенҗаң-Уйгыр автоном районы. Икенче төркемнең оешу тарихы бик тә кызыклы. Алар, нигездә, XIX гасырның уртасында күченгән. Әтием: «Безнең гаилә Казан арты якларыннан, Олы Мәңгәр авылыннан чыккан», — дип әйтә иде. Заманында, җир җитмәү сәбәпле, алар көнчыгышка күченергә мәҗбүр була, язмыш аларны, әтием әйткәнчә, «һиҗрәт дулкыннары белән» чит җирләргә илтеп ташлый. Шулай итеп, алар яңа ватаннарына урнаша, тамырларын бик тирән җибәреп, көчле мәхәллә хасил итеп яши.

Киләчәктә тагын да күбрәк документлар белән тулыландырып, шул китапның яңа басмасын чыгарсак, бу өлкәдә аеруча яшь тарихчылар эшләсә, бик әйбәт булыр иде. Бәлки, Кытай татарлары арасыннан, Голҗа яки Өремчедән бер кеше чыгар һәм әтиемнең эшен дәвам итәр, дип ышанам.

Ләбиб ЛЕРОН:
— Әгәр дә танышып барган булсагыз, Диләрә ханым «Безнең мирас» журналында әтисе Миркасыйм Госмановның археографик экспедицияләр вакытында язып барган көндәлекләрен бастырып чыгаруда ярдәм итте. Шулай ук «Та-

*Ред.: Сүз М.Госмановның «Ябылмаган китап, яки чәчелгән орлыклар: Шәркый Төркестан турында тарихи очерклар» (1996) дигән китабы турында бара.

тарстан» радиосы хезмәткәре Нәсим Акмалның Миркасыйм Госманов белән әзерләгән интервьюсы да Диләрә ханымның катнашы белән журналыбызда басылды. Рәхмәт аларга!

Күптән түгел генә Кытай татарларына кагылышлы яңа китап басылып чыкты. Аның төп авторларыннан берсе булган Әлфия Шәүкәт кызы Йосыпова — безнең арабызда.

Әлфия ЙОСЫПОВА:

— Казанга Кытай татарларыннан беренче төркем килеп укый башлагач, Татарстан хөкүмәте янә икенче төркем алырга, дигән фикергә килде. Шул уңайдан университеттан балаларны сайлап алу өчен укытучылар җибәрделәр. Без — физик Рөстәм Дәминов һәм мин — 2008 елда университет вә Бөтендөнья татар конгрессы юлламасы белән Кытайга, анда яшәүче татарларның балаларын сайлап, Казанга алып кайтырга дип, сәфәргә чыгып киттек.

2008 елдан башлап бүгенгә кадәр Кытай белән Казан арасындагы сукмак шактый ныгыды. Хәзер ел саен, хәтта елына ике мәртәбә Кытайга барырга һәм аннан килгән милләттәшләр белән һәрдаим очрашып торырга туры килә. Кытайга беренче барганнан соң, андагы татарлар һәм аларның тормышларындагы самимилеккә, андагы сафлыкка минем исем китеп кайтты. Андагы татарлар бөтенләй үзгә. Кытайда гомер итүче татарлар миңа, ничектер, чын татарлар кебек тоелды. Анда ку-

Миркасыйм ага Госманов Кытайдан килгән татар студентлары белән

накчыллык, кунакка хөрмәт, укытучыга, галимгә хөрмәт искиткеч зур. Алар Казанга, Миркасыйм Госмановка «табыналар». Алар елый-елый «Казан кичләре»н җырлый, ләкин берсенең дә Казанны күргәне юк. Алар ел саен Тукай кичәсен үткәрә. Голҗада татар белән бәйле мәктәп, мәчет, зират, урам бар. Кайчандыр Тукай урамы да булган… Бер урам Хәбиб Юнич исемен йөртә. Голҗа үзәгендә, олы урам уртасында татар имәннәре (карагач) бар. Бу агачларны кисәргә теләгәннәр. Әмма татарлар: «Бу — безнең бабаларыбыз истәлеге, алар утырткан агачлар, зинһар, кисмәгез!» — дигән. Татарга бәйле шушы урыннар белән танышып йөргәндә, мин Ильяр абый Габитовтан, Миркасыйм абыйның өен күрсәтегез әле, дип үтендем. «Кызганыч, Миркасыйм абыйның өе бүген сакланмаган, ләкин нигез янындагы агачлары бар, — дип мәктәптән ерак түгел ике агачны күрсәтте. «Менә шушы нигездә ул туып үсте, без бер партада утырып укыдык», — дип сөйләде Ильяр абый.

Шуннан кайткач, мин Россия дәүләт фәнни фондына «Кытайда яшәүче татарларның теле һәм фольклоры» дигән темага гариза бирдем. Алланың рәхмәте белән, әлеге грантны оттым. Ике ел дәвамында, шуның нигезендә, Кытайга барып, материаллар җыя башладык. Әлбәттә, без, тел галимнәре буларак, телгә кагылышлы материалларга тукталдык. Нәтиҗәдә бер төркем галимнәр катнашында «Кытайда яшәүче татарлар: теле һәм

фольклоры» исемле китап басылып чыкты.

Кытай татарлары теле — бик кызыклы, бай тел. Аларда бездә булмаган бик күп сүзләр сакланган, без әйткән урыс сүзләрен алар татар вариантында куллана. Шул ук вакытта тел уйгыр, казакъ алынмалары белән бик чуарланган. «Багана» дисәң, аңламыйлар, «столб» дисәң, беләләр. Һич уйламаган рус сүзләрен аңлыйлар, бездә актив кулланыла торган татар сүзен әйтсәң, аңламый да калырга мөмкиннәр.

Инде укучыларга килгәндә, Салисә апа күргән, аралашкан беренче төркемнән соң, хәзер инде дүртенче төркем килде. 10-15 көн элек кенә дүртенче төркем — 20 бала килеп, безнең әзерлек бүлегендә укый башлады. Беренче төркем укуларын тәмамлап китте. Кайберләре, Салисә апа әйткәнчә, бизнеста, кайберләре фән юлына кереп китте, аспирантура, магистратурада укучылар бар. Икенче төркем югары уку йортын быел тәмамлый.

Кытайдан килгән балалар, нигездә, гуманитар юнәлештә укый. Чөнки биредә алар медицина, хокук юнәлешләрендә гыйлем эстәсә, Кытайга кайткач, эш таба алмый. Бу урында Кытай медицинасының безнекеннән күпкә өстен икәнлеге хакында әйтеп тору кирәкмидер. Ә тел өйрәнүгә килгәндә, әлеге юнәлеш аларга кызык. Алар татар филологиясе бүлегендә укый. Бу бүлектә укуның тагын бер зур өстенлеге бар. Биредә аларга җиңелрәк. Беренчедән, уку нигездә татар телендә, икенчедән, безнең бүлектә ул балалар үзләрен гаиләләрендә кебек хис итә. Алар хәтта: «Апа, Миркасыйм абыйдан соң, ярый әле сез бар!» — дип миңа аркаланалар да. Шулай ук рус филологиясе һәм журналистика юнәлешләрендә укучы татар студентлары да бар. Студент — студент инде ул. Тырышлары, ялкаулары очрый. Әмма без бернәрсәгә шатланабыз: бу балалар Казанга килеп татар телен өйрәнеп китә. Аларда милли хис бик көчле, кая гына барсалар да, алар үз балаларына татар телен өйрәтәчәкләр. Кытайдамы, Татарстандамы, башка җирдәме, бу гаиләләрдә татар теле сакланачак. Аларга Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан да бик күп мөмкинлек бирелде. Миркасыйм абый да милли мәдәнияткә җәлеп итәргә тырышты. Театрда ул егет-кызлар барлык спектакльләрне дә карап чыкты. Шамил Закиров исән чакта аларга бушлай керү мөмкинлеге тудырылды. Барча концертка, зур чараларга да Кытайдан килгән студентларны тамашачы буларак чакырдылар.

Без аларга хәерхаһлы булырга тырышабыз, әмма таләпчәнлекне һич кенә дә киметмибез. Чөнки КФУда укып, аның дипломын алып чыгу студентларга бик зур җаваплылык өсти.

Разил ВӘЛИЕВ:

— Кытайдагы шушы 5-6 мең татар арасыннан бик күп мәшһүр кешеләр чыккан. Борһан Шаһиди үзе генә дә ни тора! Ул — Мао Цзедун урынбасарларының берсе. Бөтен Кытайда иң атаклы мәшһүр шәхесләрдән. Без Өремче каласындагы бөек затлар җирләнгән зиратта да булдык. Зиратта искиткеч матур эшләнгән кабер ташлары бар. Б.Шаһиди дә, Кытайның иң атаклы кешеләре белән бергә, шулар аллеясында җирләнгән. Бүгенге көндә татар хатын-кызлары арасында генерал бардырмы, белмим. Әмма 5-6 меңлек кытай татар хатын-кызлары арасында генерал бар. Ул — Рәгънә Акмуллина. Голҗа шәһәренең баш табибы — татар кешесе. Атлаган саен шундый затлы шәхесләр. Фәннәр Академиясенең мактаулы академиклары, андагы профессорлар, Кытай парламенты депутатлары... Кемнәр генә юк анда? Шаккатырлык! Бер Шәле авылы халкы кадәр татар. Алардан күпме кеше чыккан! Ильяр Габитов — искиткеч атаклы шәхес. Ул гомернең 18 елын төрмәдә утырган. Аның турында бер

роман язарлык. Без «Җыен» фонды белән бергә И.Габитовның шигырьләр җыентыгын китап итеп тә бастырып чыгардык. Әгәр дә Кытай татарлары турында китап чыга калса, аның 1-2 шигырен дә бастырсагыз, бик тә әйбәт булыр иде.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Безнең арабызда бер шәкерт тә бар. Ул Нурмөхәммәт исемле егет.

НУРМӨХӘММӘТ:

— Әссәламегаләйкем! Исәнмесез! Беренчедән, шуны әйтеп үтәсем килә, Кытайдагы ничә миллион кеше арасыннан Казанга килеп югары белем алырга безгә мөмкинлек биргәннәре өчен Татарстан халкына бик зур рәхмәт. Икенчедән, Казанга килгәч, кайбер эшләрдә авырлык туды. Әмма безгә булышкан Әлфия апа, Фәрит абый һәм башка кешеләргә рәхмәтемне җиткерәм. Мин бирегә Кытайдан килгән вакытымда татар әдәби телен бик яхшы белми идем, дөрес, аңлый идем, әмма җавап кайтара алмый идем. Мин кытай мәктәбен бетердем. Кытайлар миннән сорый иде: «Син татар егете, татарча беләсеңме?» — дип. Мин, беләм, дип әйтә идем. Казакъча сөйләдем. Алар аңламас иде. Әмма өйгә кайткач, оялудан битләрем кызарды. Аннан соң татар телен әйбәтләп өйрәнергә дигән максат куйдым. 2011 елда Казанга килергә мөмкинлек булды. Казанга килгәч, рус телен өйрәндек, ә татар теле өстәмә дәрес буларак укытылды. Биредә үземне чип-чиста татар итеп хис итә башладым. Кытайда яшәгәндә ун гына җөмлә белә идем: «Исәнмесез!», «Хәлләрегез ничек?», «Ничек яшисез?» һ.б. Казанга килгәч, күп сүзләрне өйрәндем һәм горурланып әйтә алам, хәзер Кытайдагы дусларым, татарча беләсеңме, дип сораса, әйе, мин татарча беләм, дип күкрәк сугарлык булдым. Хәзер, Аллага шөкер, минем балам да монда туды. Аңа да татар телен өйрәтәм. Шуңа мин бик шат.

Вахит ИМАМОВ:

— Разил абый «Кореяда татар тапмадым», дигән иде. Минем өстәп кенә әйтәсем килә: безгә мәгълүм шагыйрь Ринат Батталның оныгы Кореяда яши. Кореяда да, дим, Аллага шөкер, үзебезнекеләр бар.

1911 елда Иж-Бубый мәдрәсәсен ябып куйганнан соң, атаклы Габдулла Бубыебыз Голҗага киткән. (Иж-Бубый мәдрәсәсе — татар мәгърифәтенең мәркәзенә әйләнгән мәдрәсә иде.) Буби анда яшәгәндә мәчет ачалар. Безнең татарлар өчен дә сабак булырдай бер вакыйга бу! Шушында яшәгән татарлар, хәлфәләр, имамнар, йорттан-йортка йөреп, татар балаларын җыеп, мәчет янында мәдрәсә ачып җибәрә! Без менә татар мәктәбендә укытырга бала юк, дип сөйләшәбез, ә тегеләр нинди үрнәк күрсәткән. Дөрес, соңрак Г.Бубый, туберкулёз чиренә түзә алмыйча, кайтып китә һәм 1922 елда вафат була. Аның кабере, кабер ташы Иж-Бубый зиратында. Голҗада мондый бөек шәхеснең байтак вакыт балалар укытуы, имам булып эшләве анда яшәгән татарларга бик нык тәэсир иткән, алар өчен зур горурлык булгандыр, дип саныйм.

Кытайда татарлар тупланган икенче үзәк — Харбин, Маньчжурия. Шаккатмалы хәл: мөһаҗирләребез анда татар газетасына кадәр чыгарган! Шул рәвешле үзләренең динен, телен һәм мәдәниятен сакларга тырышканнар. Шушында ук Гаяз Исхакый килгән. Маньчжуриядә аның белән очрашу үткәргәннәр. Аннары инде, Советлар Союзы тәэсирендә Кытайда коммунистлар партиясе

төзелгәч, милләттәшләребез Япония, Төркия кебек илләргә һиҗрәт кыла башлый. Таминдар абый Мөхит Япония императорының киңәшчесе булып унике ел хезмәт итә! Татар акылы япон императорына да, кытайныкына да кирәк! Бу — татар халкының белемлелеге, зыялылыгы турында сөйли торган факт.

Без революциягә кадәр бөтен төрки дөньяда лидер булганбыз. Нинди атаклы кешеләр булган бездә! Хәзер бу биеклекне югалттык. Һәр татарның күңелендә «шушы лидерлыкны тагын кабат кайтарасы иде», дигән хис булырга тиеш. Без шушы уй белән, шуның өчен көрәшеп үләрбез дә инде...

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Без, әлбәттә, үткәнебез өчен горурланып утырабыз. Әмма киләчәк өчен яшибез бит! Безне алда нәрсә көтә? Уйлап карасаң, «кытай» дигән исем — бик зур исем, үзегез белеп торасыз, хәзерге дөньяның, Татарстан хөкүмәтенең һәм безнең алдынгы акыл ияләренең Кытайдагы милләттәшләрне барлавы — алдан күрүчәнлек, мин моны бик акыллы гамәл, дип саныйм. Һәрхәлдә, кытай татарлары югалачак түгел. Без быел Әдәбият елы, дип әйтәбез. Бу — безнең өчен бик яхшы фал, чөнки әдәбият дигәндә дә, тарих безнең яклы. Кайсы гына гасырны алсак та, без төгәл шәхесләр, әсәрләр, гамәлләр турында телгә алып сөйли алабыз. Ә кайбер халыклар шанлы булып күренсәләр дә, XV яки XVI гасырдан үзләренең тарихи шәхесләрен мисалга китереп сөйли алмый. Киләчәк турында уйлаганда, менә бу форсаттан файдаланырга кирәк. Кытай тирәсендә безнең берникадәр тамырлар бар икән, аны мөмкин кадәр күбрәк матбугат аша халыкка пропагандалау фарыз. Инде әдәбиятка килгәндә, Габитов кебек шәхесләр, безнең күзлектән караганда, Тукай түгелдер, әмма «Менә Кытайда безнең кемнәр бар!» дип күрсәтә белергә кирәк. Кытай татарлары турында әлеге китапны чыгарып искиткеч зур эш эшләгәннәр.* «Безнең мирас» журналының әлеге мәсьәләне кузгалтуы да зур гамәлләрдән. Кытай татарлары белән Идел-Урал буе татарлары арасындагы бәйләнешләрне киләчәктә тагын да калкурак итеп күрсәтергә кирәк, бу бик мәгънәле эш.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Монда мин бер проблема бар, дип уйлыйм. Ул да булса, Кытай архивларына кереп эшли ала торган галимнәр тәрбияләү мәсьәләсе.

Диләрә ГОСМАНОВА:

— Сез бик четерекле мәсьәләне кузгатасыз. Кытай архивларына чит мәмләкәт кешеләрен кертү катгый тыелган. Бу — дәүләт сәясәте.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Ни өчен алай икән?

Диләрә ГОСМАНОВА:

— Төгаен белмим, әйтә алмыйм.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Безнең Рәсәй өчен генә бикләгәннәрдер алар.

Диләрә ГОСМАНОВА:

— Юк, бүтәннәргә дә. Европадан да кертмиләр. Икенче юл бар. Шәхси куллардагы материалларны, архивларны өйрәнергә мөмкин. Тора-бара алар юкка чыгачак.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Кытайда унлап мөселман халкы яши. Заманында татарлар өстенлек иткән, хәзер өстенлек казакълар һәм

*Ред.: Сүз КФУ галимнәре чыгарган «Кытайда яшәүче татарлар» дигән китап турында бара.

уйгырларда. Мин уйгырларның да, казакъларның да хәлләре әйбәт түгелдер, дип беләм. Ә менә анда хәзер сезнең буын, Фәрит әфәнде, соңгы татарлардыр, әллә мин ялгышаммы?

Фәрит МӨСЛИМОВ:

— Бөтенесе Пётр I вакытыннан килгән сәясәт — татарларны юк итү. Хәзер дә бу сәясәт бара. Башка исемнәр кушалар, татар дигәне генә юк булсын. Шеньҗаңга, Шәркый Төркестанга татарлар 1830 еллардан күченә. Анда барып, Шәркый Төркестанны Рәсәйгә алып бирәләр. Шәркый Төркестан Рәсәй кул астына керә, аннан Кытай кайтарып ала. 1906 елда Кытайга күчкән татарларга күтәрелеп китәр өчен акча бирергә, дигән указ да чыга. Бу заманда күченгән татарларда татарлык күп дигәндә ике буынга бара, аннан юк була. Монда 500 ел дәвамында 80% татар үз телен оныткан дисәк, анда 99 % белми дияргә мөмкин. Шуңа күрә 2005 елдан Кытай татарларының бирегә килеп укый башлавы — Татарстан Республикасы башкарган иң зур эшләрнең берсе. Алар 38 бала килгән иде, хәзер шуларның биш-алтысы биредә эшли, алай гына да түгел, Кытай белән хезмәттәшлектә Татарстанга ярдәм итә.

Анда бит инкыйлабтан соң татарның акыллы, зыялы байлары да күченгән. Акыллы кешедән акыллы бала туа. Аларның хәзер балалары, оныклары үсеп килә. Күбесе Кытайда зур түрәләрнең ярдәмчесе, урынбасары булып эшли. Татарларны саклау авыр. Кытайның 2010 елда чыккан планы бар: Үзәк Кытайдан 150 миллион кытайны күчереп утыртырга, дигән карар ул. Күчеп килгән кытайларга торырга өй бирәләр, өч ел эшләтмичә, хөкүмәт аларга ярдәм итә. Җирле халыкны кытайлар басып китсә, татарларның саклануы шикле.

Андагы күп татарларның фамилияләре юк. Мәсәлән — Нурмөхәммәт. Аның фамилиясе дә Нурмөхәммәт. Исеме — әтисенең исеме. Менә сиңа Кытай куйган исем һәм фамилия. Әти исеме, нәсел-нәсәп күрсәтелми…

Вахит ИМАМОВ:

— Сан ягыннан аз булганнарны санга сугучылар аз.

Фәрит МӨСЛИМОВ:

— Хәзер Кытайда 5 меңнән артык татар яши, диләр инде. Аның да яртысыннан күбе татар түгел. Татарлар аз санлы халык булгач, аларга юл бирәләр, татарларга өч бала рөхсәт ителә, уйгырларга — ике генә бала. Шунлыктан казакълар, уйгырлар, хәтта дунгәннәр дә татар булып языла килә. Бу җәһәттән караганда, татарларга берникадәр юл бар. Әмма 5 мең татар белән генә нәрсә эшләп була?

Ләбиб ЛЕРОН:

— Сөйләшүебезне йомгаклар вакыт җитеп килә. Әмма без аны журналыбыз битләрендә дәвам итәрбез, дип уйлыйм. Миңа калса, утырыш бик җанлы, кызыклы булып, мәгънәлегамьле, эчтәлекле үтте. Хәл ителәсе мәсьәләләр бар, һәм алар, чынлап та, бик җитди.

Төрле кыйтгаларга сибелгән татарларыбызны барлау-саклауда, халкыбыз мәнфәгатен кайгыртуда максатчан эш алып барсак кына, бу эш-гамәлләргә бергә-бергә тотынсак һәм аларның уңай нәтиҗәсенә ирешү өчен даими көрәшсәк кенә теләкләребезгә ирешербез, иншаллаһ.

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

С.Исхаков һәм Л.Гобәйдуллин фотолары.

Голҗа шәһәрендәге татар кызларының «Нур мәктәбе» укытучылары вә укучылары. 1914 ел

КЫТАЙДА ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕ

Әлфия Йосыпова

(XIX гасыр ахыры — XX гасыр башы)

Кытайда яши башлагач, татарлар, иң беренче чиратта, милли мәгариф мәсьәләләрен көн тәртибенә куялар. Мәктәпләр ачалар, татар мәгарифен үстерү белән бергә, җирле халыклар (уйгыр, дүнгән, казакъ) мәгарифен үстерүгә дә зур өлеш кертәләр.

XIX гасыр урталарыннан алып, татарлар Кытайның Элә районына килеп урнаша. Алар башта Голҗа шәһәренең Ташләпкә (таш лавка), Кисек муен мәхәлләсе, Монгол Көрә, Күнәс, Нылка кебек авылларында тупланып яши. Ташләпкә мәхәлләсендә, зур татар мәчете һәм ике бүлмәле мәдрәсә төзеп, татар һәм башка милләт балаларына белем бирәләр.

XIX гасырның 80 нче елларыннан

алып, Голҗа, Атуш, Турфан, Өремче, Чүгүчәк, Кашкар кебек шәһәрләрдә гомуми белем бирү мәктәпләре ачыла.

1881 елда мәгърифәтче Хаҗи Ситдыйк Габитов, үз акчасына Казан шәһәреннән шул заманның мәшһүр дин эшлеклесе Кәфуласрар дамелланы Голҗага чакырып, татар мәчетенә имам итеп куя. Кәфуласрар дамелла җитәкчелегендәге мәчет мәдрәсәсендә ана теле, әдәбият, математика, славян әлифбасы кебек фәннәр укытыла. Татарларның саны күбәеп китү сәбәпле, мәдрәсә халык ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый башлый һәм, бу мәсьәләне хәл итү өчен, Хаҗи Шәрәфетдин Габитов Бәйтулла мәчете каршына дүрт сыйныфлы мәктәп һәм 10 бүлмәле тулай торак төзетә. Бу яңа мәдрәсәгә «Мәктәби Кәшфия» дип исем бирәләр. Мәдрәсәдә дәресләр кадими ысул белән үткәрелсә дә, тәртипләр башка мәдрәсәләрдән күпкә алга киткән, прогрессив була. Дәреслекләр Казаннан китертелә. Алар төрле типографияләрдә басылган була. Шуңа күрә дә халык телендә бу китаплар, дәреслекләр «Казан басмасы» дип атала.

1894 елда Чапчал Җагыстай авылында Казан университетын тәмамлап килгән мулла Әмин Әбәш дини дәресләр белән бергә дөньяви фәннәрдән дә дәресләр укыта башлый, балаларны төгәл, табигать фәннәре белән дә таныштыра. 1905 елда Искәндәр Хафиз исемле кеше, Голҗа шәһәреннән Гарифулла дигән укытучыны чакырып, үз өендә мәктәп ача һәм балаларны укытырга керешә. 1913 елда Баудынбай Мусабаев, Казаннан килгән татар зыялысы Хәдичә ханымны чакырып, кызлар һөнәр мәктәбен ача. Мәктәптә дин дәресе дә, тегү, чигү, туку дәресләре дә була.

Элә татарлары 1900 елларда яңарыш хәрәкәтендә барлыкка килгән яңача ысулны кабул итә. Казан, Уфа, Оренбург кебек шәһәрләрдән яңача уку-укыту әсбапларын алдырып, укытучылар чакырып, милли мәгарифне үстерә башлыйлар.

1910 еллар ахырында татарлар, сан ягыннан күбәю сәбәпле, Ташләпкә мәхәлләсенә сыймый башлый һәм, бер урында тупланып яшәү теләге белән, татар байлары акчасына буш җир сатып алып, яңа татар мәхәлләсе оештырыла. Аны татар мәхәлләсе дип атыйлар, ләкин җирле уйгырлар бу районны Ногай мәхәлләсе дип йөртә. Халык телендә тагын Нугай город (Новый город) атамасы да була.

1910 елда бер төркем татар зыялылары һәм алдынгы карашлы затлар, заманга лаеклы кызлар мәгарифенең мөһимлеген аңлап һәм чорга ярашып, махсус кызлар мәктәбе ачарга карар кыла. Укытучы мәсьәләсен хәл итү өчен, Казан шәһәреннән мәшһүр педагог Габдулла Буби һәм Хәдичә абыстайны Голҗа шәһәренә чакыралар. Татар җәмәгатьчелеге аларны бик җылы каршы ала һәм татар байлары, мәктәп төзү өчен, акча җыя башлый. Нәтиҗәдә, Ташләпкәдәге зур татар мәчете мәдрәсәсе урынына ике катлы мәктәп ачыла һәм аны «Мәктәби Нур» дип атыйлар. Мәктәптә «Нур» китапханәсе дә эшли. Китапханәдә татар байлары ерак җирләрдән, шул исәптән Казаннан кайтарткан татар китаплары да күп була, татар газета-журналлары да шактый туплана. Мәсәлән, «Таң», «Уклар», «Әл-ислах», «Тәрҗеман», «Әл-гасрел җәдит» басмалары бу китапханәдә җыелып бара. Бу мәктәп башлангыч һәм төп белем бирүне үз эченә алган бердәнбер кызлар мәктәбе була һәм аның даны бөтен Шенҗаңга һәм Урта Азиягә тарала.

1914 елда «Мәктәби Нур»да рәсми рәвештә дәресләр алып барыла башлый. Башлангыч сыйныфларда әлифба, математика, дин, әдәбият, табигать белеме, әхлак нигезләре, тәнтәрбия (физкультура), чигү дәресләре үткәрелә. Урта сыйныфларда әдәбият, ботаника, алгебра, геометрия, химия, физика, әхлак, тән-тәрбия, гарәп теле, шигырь һәм дин дәресләре бирелә.

1917 нче елда Сөйдүң өязендә ачыл-

ган Чулпан мәктәбендә Хәсән Акчурин мөдир һәм укытучы була. Тарихчы, мәгърифәтче Иминҗан Баудын, Октябрь инкыйлабыннан соң Казанга килеп, мәшһүр татар мәгърифәтчесе Идрис Апанаевтан фарсы, төрек телләрен өйрәнә һәм совет мәгариф системасы белән таныша. 1923 елда, Кытайга кайтканда, остазы Идрис Апанаевны үзе белән алып китә һәм Чапчал өязендә татар мәктәбе ача.

XX гасырның 30 нчы елларында татар зыялыларының бер төркеме, халыктан акча җыеп, яңа мәхәллә мәктәбен зурайтып төзи. 1936 елдан ул «Татар мәктәбе» дип атала һәм анда дәресләр үткәрелә башлый. Мәктәптә ана теле, математика, тән-тәрбия, дин, кытай теле, әдәбият, химия, физика, тарих, география, биология, рәсем дәресләре укытыла һәм бу дәресләр барысы да (кытай теленнән кала) татар телендә үткәрелә. Аның тарихы бик еракларга барып тоташа. 1868 елда Голҗада мәдрәсә ачыла, 1871 елда ул 14 сыйныфлы мәктәпкә әйләнә. Тирә-яктагы балалар килеп укысын өчен тулай торагы да булдырыла. Бу эшләрнең барысына да Казаннан килгән Шәрәфетдин әфәнде җитәкчелек итә. Татарча укыту 1925 елдан кертелсә дә, ул 1936 елда гына рәсмиләштерелә. Голҗадагы татар мәктәбе турында Ләйлә Садри үзенең истәлекләр китабында болай дип яза: «Голҗа татар мәктәбе иң яхшы мәктәп булып санала иде. Уку программасы югары. Укучылар урамда бәйрәм көннәрендә бик тәртипле, бик чиста тезелеп йөргәндә, бөтен кеше аларга сокланып карап кала иде. Элек иске шәһәр уртасында зур мәктәп ике катлы бинада иде, ә яңа калага Галиәхмәт абзый Садри тагы дүрт сыйныфлы мәктәп салдыргач, мәктәпнең бер өлеше шунда күчте. Кечкенә сыйныф балаларының бер өлеше шунда укый башлады. Соңыннан татарлар барысы бергәләп яңа калага зур итеп яңа мәктәп салдылар. 1938 ел ахырында барлык мәктәп шунда күчте...» [Садри 2003: 26]. Узган гасырның 50 нче еллар ахырында сәяси үзгәрешләр башлангач, бик күп татарлар Советлар Союзына, Австралиягә, Америкага күчеп китә. Укытучылар калмый диярлек. Балалар саны да кими. Ул вакытта бер сыйныфта балалар саны уннан да ким булмаска тиеш була. Шулай итеп, 1959 елның декабрь аенда татар мәктәбен ябарга мәҗбүр булалар. Бүгенге көндә аны музей итеп төзекләндерү эшләре башланган.

Мәктәп укытучылары, нигездә, Казан, Оренбург, Мәскәү, Истанбул, Берлин шәһәрләрендә белем алган зыялылар була. Мәктәптә, дәресләр укыту белән берлектә, укучыларны әдәби иҗат белән дә кызыксындыралар. Төрле әдәби түгәрәкләр эшли. Бу түгәрәкләрдә катнашучылар «Башмагым», «Сүнгән йолдызлар», «Таһир-Зөһрә» кебек әсәрләрне сәхнәләштерәләр, һәр ел Г.Тукайны искә алу кичәләре үткәрелә торган була.

Голҗада «Талия» мәктәбе дип аталган тагын бер уку йорты була. 1940 елдан соң бу мәктәп белән Зәйнәп ханым Габитова җитәкчелек итә. Шундый ук мәктәпләрдән «Хәйрия» мәктәбе, «Айхан ана» мәктәбе, «Намунә» үзбәк мәктәбе, Шәрык мәктәбе, «Ярдәм» мәктәбе кебек уку йортларында татарлар директор вазифасын башкарганнар. Мәктәп коллективларында да татар укытучылары бик күп була.

1936 елда Голҗа шәһәрендә лабораториясе, китапханәсе һәм эшханәләре булган 16 сыйныфлы Элә милләтләр гимназиясе ачыла. Бу гимназия халыкның матди ярдәме нигезендә барлыкка килә. Татар байларыннан Гыйлаҗетдин Закирҗан, Низам бай да икътисади яктан мәктәпкә зур ярдәм күрсәтәләр. Гимназиядә татар укытучылары да күп була. Алар алгебра, физика, химия, анатомия, зоология, математика, тарих, география кебек фәннәрдән дәресләр бирәләр.

1959 елда күп кенә татарларның башка җирләргә күчүе сәбәпле, татар

балаларының саны кими һәм татар телендә укыту алып бару мөмкинлеге калмый. 1881 елда ачылган Голҗа татар мәктәбе 1959 елга кадәр булган 78 еллык данлы тарихында татарларның гына түгел, шул төбәктә яшәүче башка милләт халыкларының яңа заман мәгарифе үсешенә зур өлеш кертә.

Хәзер исә татарлар, нигездә, кытай телендә белем алалар, үз телләреннән башка, кытай, казак, уйгыр телләрен беләләр. Татар әдәбиятын кытай теленә тәрҗемә итеп, аларга татар әдәбиятын танытырга омтылалар. Мәсәлән, Г.Хәсәнов Габдулла Тукайның «Китап», «Туган тел» һәм башка бик күп шигырьләрен беренче булып кытайчага тәрҗемә итә.

Элә вилаяте кызлар мәктәбенең укытучылары. Утыра: мәктәп мөдире Зәйнәп Габитова, басып торалар: сулдан – Сәгадәт, Мөнҗия, Мөршидә. Сентябрь, 1940 ел



بزنك عەسكەرلەر .
سياقچى - بانگز .
سوعش تلەمى .
بزنك ئيلنبز .

سوعش ناچەلار ،
بزگە دوشمانلار ،
دەر وانت حەزر .
بزنك عەسكەرلەر .

شك - جاك

شك جاكدا: حەنسو، ماڭعول، شبە، مانجو، سولان، قازاق، قرعز، ئويعور، تاتار، تارانچى، دوڭگەن، روس، ئوزبيك، تاجيك، هەم باشقا حالقلار يەشيلەر. حەنسو، ماڭعول، شبە، مانجو، سولان، قازاق، قرعز، ئويعور، تاتار، تارانچى، دوڭگەن، روس، ئوزبيك، تاجيك، هەم باشقا حالق حزمەت ئيبەلەرنك بالالارى هەممەسى دە ئيبدە شلەر.

—

يەشەسن، تورلى
ميللەت حالقلارنك
ئاتولغى!
يوعالسن، واتان ساتوچى حائينلەر!

«Татарча әлифба китабы»ннан бер сәхифә

تاتارچا ئەليفبا كيتابى
ئيلى وەلايەت مەعاريف ئيدارەسينك
روحسەتى بلەن
(باستروچيسى)
ئلى تاتار ئاغارتو ئويوشماسى
ئيلى شڭبالا مطبعەسيدە بسلدى .
1941

Голҗа шәһәрендә «Элә татар агарту оешмасы» тарафыннан 1941 елда нәшер ителгән «Татарча әлифба китабы»ның тышлыгы

Голҗадагы татар мәктәбе. Биредә М.Госманов та белем алган

Хәзерге вакытта Кытайда татар мәктәбе юк, татар телендә газета-журналлар да чыкмый. Кытай татарлары теле диаспора сөйләмендә генә сакланып калган. Телне гаиләдә өйрәнәләр һәм буыннан-буынга саклап яшиләр. Уйгыр, казакълар кебек татарлар кытай телендә белем ала, кытай телендә сөйләшә һәм аралаша. Татарлар уйгыр һәм казакълар белән катнашып яши, шунлыктан алар уйгыр һәм казакъ язуын куллана.

Татар мәдәниятен һәм телен сакларга омтылыш сизелерлек булса да, Кытайдагы татар эмигрантлары, теләсә дә, теләмәсә дә, ассимиляция процессына дучар. Алар даими рәвештә бер (үз, туган, татар) мәдәни һәм тел даирәсеннән башка (чит, бөтенләй ят, кытай) даирәгә күчү халәтендә яшәргә мәҗбүр. Татар телен белүнең дәрәҗәсе (грамматик яктан дөрес сөйләү рәвеше, тел берәмлекләрен сайлау), билгеле бер дәрәҗәдә татар көнкүреше, йолалары һәм әхлакый кыйммәтләрен саклау Кытайдагы татар диаспорасының өлкән буын вәкилләренә хас. Ә мәктәпләрдә, колледжларда һәм университетларда белем алучы яшь буын күбрәк кытай телендә аралаша һәм бик тиз туган телен оныта. Татар телен куллана торган төп урын — көнкүреш — үз этник диаспорасы вәкилләре белән гаиләдә сөйләшү һәм башка рәсми булмаган аралашулар. Татар этник төркеме эчендә, гаиләдә татар телендә аралашалар.

Балалар кытайча сөйләшергә күнегеп китә алмаган әби һәм бабайлары белән генә татарча аралашырга тырыша. Татар теле белән кызыксындыру өчен, болар гына җитми. Ләкин, Кытайдагы татар эмигрантларының балалары шөгыльләнә торган татар шимбә мәктәпләре бу проблеманы хәл итеп бетерә алмый. Әлеге мәктәпләргә яшүсмерләр килеп, ата-аналарының телен өйрәнергә теләк белдерә, һичшиксез, Кытайда яшәүче татарлар өчен татар теле — буыннарның үзара аралашу чарасы. ■

АТА-БАБА ВАСЫЯТЕ

Марат Закир

ГОЛҖА

2011 елда Кытай Халык Республикасында булырга һәм беркадәре (август-сентябрь айларында) Өремче, Голҗа калаларында яшәп алырга туры килде. Биредә мин мөһаҗир татарларның балалары, оныклары белән таныштым, аралаштым, дуслаштым. Заманында Шәркый Төркестан дип йөртелгән, хәзер исә Шенҗаң-Уйгыр автоном районы дип аталучы бу төбәктә милләттәшләребез әллә ни күп яшәми, меңгә дә тулмый алар. Әмма нигездә уйгыр, казакъ, чин һәм дүнгән (ислам динен тотучы кытайлар) өстенлек иткән кала вә салаларда татарларның югалып калмавы күңелне сөендерә. Күзәтеп, аралашып йөри торгач, шундый нәтиҗәгә килдем: биредә яшәүче кардәшләребез өч һөнәргә аеруча өстенлек бирә икән — алар йә табип, йә укытучы, йәисә — эшмәкәр. Берничә тел беләләр: кытайча да, уйгырча да, казакъча да рәхәтләнеп сөйләшәләр, язалар, укыйлар. Татарчага килгәндә

Лот бабай һәм Гомәр Әминов – Голҗа шәһәре муллалары. Июль, 2010 ел. Голҗа

исә… Төрлесе бар. Тукай заманы теленә урыс сүзләрен кыстырып сөйләүчеләр дә очрый. Хәтта уйгыр, казакъ һәм татар телле аерым диалект та пәйда булган. Хәер, монысын тел галимнәренә калдырыйк. Сүзем бирердә тапкан дусларым турында иде ләбаса.

Шулардан берсе — Гыйззәтулла Әнвәр улы Хәсән. Ул 1959 елның 28 августында Кытай Халык Республикасына кертелгән Шенҗаң-Уйгыр автоном районының Элә (Или) өлкәсенә караган Аксу авылында дөньяга килә. Голҗада кытай, уйгыр һәм казакъ телләре буенча югары белем ала, аннары исә Пекинда аспирантурада укый. Җәмгысе 32 ел дәвамында ул Голҗадагы Кадрлар институтында укыта, кытай (чин) теле кафедрасы мөдире була. Кадрлар институты, безнеңчәрәк әйткәндә, ил куркынычсызлыгы хезмәткәрләрен әзерли торган югары уку йорты ул. Һәм шунда татар егете кытайларга кытай теле һәм әдәбиятын укытсын әле! Белүемчә, кытай язуын — иероглифны (бер иероглиф тулы бер җөмләне дә сыйдыра ала!) өйрәнү теләсә кем булдыра ала торган эш түгел. Диалектлары да хәттин ашкан. Гыйззәтулла Хәсән Пекин уртак әдәби телен укыткан. Берничә телне камил белүе өстенә, ул шагыйрь дә әле: Кытайның классик шагыйре Лю-Шинның тезмәләрен казакъчага аударса, Абай шигырьләрен исә кытайчага тәрҗемә кылган. Бактың исә, татар җырларын, Тукайның кайбер әсәрләрен, шул исәптән, «Туган тел»не дә кытайча дөньяга чыгарган икән әле ул.

ТАТАР МИРАСЫ

Голҗада беренче мөһаҗирләр утырткан агачлар бүген дә исән. Ул хакта тәфсилләбрәк шәрехләрмен. Дусларым мине бирердәге татар зиратына да алып барды. Заманында гөрләп эшләгән татар мәктәбе бинасы да саклаган. Миркасыйм Госманов укыган мәктәп!

Хәзер инде 20-30 катлы йортлар арасында ук калган татар зиратында 1830 елда куелган хикмәтле бер кабер ташы бар. Аннан «1800 елда туган, 1830 елда вафат булган» дигән язуны укып була. Әмма да, ни кызганыч, вафат булган кешенең исемен-атын танып булмый. Нәкъ менә шушы язудан чыгып, Казан һәм Уфа ягы татарлары бирегә XIX гасыр башында ук күченә башлаган, дип фаразлана. Моннан 7-8 ел элек, Гыйззәтулла Хәсән, кабер ташын фотога төшереп, Пекиндагы мирасны саклау идарәсенә җибәрә. Голҗада бинаһая зур төзелешләр барган вакыт бу. Татар зираты урнашкан җиргә дә кызыгучылар байтак… Каберлек урынын заманында Фазылҗан атлы татар бае алтын бәрабәренә сатып алган булган. Пекиннан махсус комиссия килеп тикшергәч кенә зиратка тимиләр, хөкүмәт тарафыннан саклауга алалар. Тәүге мөһаҗирләребез утырткан имәннәрне дә Гыйззәтулла һәм башка милләттәшләребез, әнә шулай, Пекинга хатлар яза-яза саклап калалар. Югыйсә, халык «Татар имәннәре» дип атап йөрткән агачларны кисеп, бирердә юл саласы булганнар. Хәер, юлын да салганнар, агачларны да саклап калганнар…

Татар имәннәре…

Россиядә «урыс кышы», «урыс кыры», «урыс каены» дигән сәер вә мәгънәсез гыйбарә бар. Йөзләгән милләт яшәгән илдә ничек инде кышы, кыры, каены һәм башкалары бер генә милләткә мөнәсәбәтле була ала соң?!

Голҗадагы «татар имәннәре» һич тә сәер яңгырамый. Чөнки аны татарлар утырткан, татарлар саклап та калган!*

ӨЧ УГЫЛ

Соңгы вакытларда Гыйззәтулла Хәсән Голҗа-Казан арасында еш йөри башлады. Хикмәте — хәләл җефете

*Ошбу санның 118 нче битендә «Табигый мирас» сәхифәсендә татар имәннәре сурәтләнә.

Гыйззәтулла Хәсән Арча педагогия көллияте директоры Гөлнара Гариповага уйгыр әлифбасын бүләк итә. 2015 ел

Хәлимә ханымның Татарстанда яшәү хокукы бирә торган документында бер хата табылган. Шуңа күрә дә ул Голҗага кайтып китәргә мәҗбүр була.

Гыйззәтулланың өч улы бар. Олысы — Нәгыйулла — Лаеш районының Кече Елга авылы кызы Айгөлгә өйләнеп, бүгенге көндә Казандагы бер кытай компаниясендә эшли. Кече улы Вәлиулла исә КФУның журналистика факультетында укый. Уртанчы уллары Әсхәт — Пекин медицина университеты студенты. Мин күзәткән «өч һөнәр» боларда да чагыла икән бит, әй: берсе — эшмәкәр, берсе — журналист (укытучы), берсе — табип.

БЕЗ БИТ — АРЧА ЯКЛАРЫ!

Гыйззәтулланың әтисе Әнвәр ага, вафаты алдыннан, улына васыять әйтеп калдыра:

— Углым, мөмкинлек-форсат чыкса, зинһар, туган илгә, туган якка кайт! — ди ул. — Бабаң Бәхтияр кайта алмады. Гомере буе туганякны сагынып яшәде. Безнең нәсел тамырлары Казан артыннан, Арча ягыннан, дип әйтә иде ул... Угылларың туган телне белеп үссен!

Ниһаять, моннан дүрт ел элек, ата-баба васыятен үтәп, Гыйззәтулла Хәсән Казанга кайтты. Лаеш районының Кече Елга авылында йорт сатып алды. Казанда да фатиры бар. Төрле телләрне камил белгән кеше өчен башкалабызда лаеклы хезмәт урыны табуы әллә ни авыр түгелдер. Ата-баба васыятенең икенче төп өлешен дә Гыйззәтулла тулысынча үти: өч улы да татарчаны камил белә.

— Өйдә һәрдаим татарча сөйләштек, татар җыры тыңладык, үзебез дә җырладык. Татар китабыннан, гәзит-журналларыннан өзелмәдек, — ди Гыйззәтулла үзе. — Улларыбыз өчен татарлыкны саклаучы төп мәктәп әнә шул булды! — Һәм, шигъри юллар белән, болай дип тә өстәп куя:

Татар телем — туган тел!
Гомерлеккә без бергә!
И, туганнар, тырышыгыз
Туган телне белергә!

PS: Моннан өч ел элек Арчадагы «Әлифба» музеена бер вәгъдә биргән идем: Голҗадагы дусларым аша музейга уйгыр әлифбасы кайтарырмын, дидем. Ниһаять, быелның февраль аенда ниятем тормышка ашты. Ул әлифбаны якташлары Гыйззәтулла Хәсән алып кайтты һәм үз куллары белән бүләк тә итте. ■

«НИНДИ БАТЫР БАЛА!»

Гөлчирә Ханнанова

(Кытайда нәшер ителгән «Ерак Шәрык» журналында Тукай турында бер хатирә)

Россиядә булып узган 1917 елгы Октябрь инкыйлабы һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларыннан соң Ерак Көнчыгыш илләрендә яшәүче төрки-татарларның тормышы да үзгәреш кичерә. Россиядән килгән яңа мөһаҗирләр хисабына сан ягыннан шактый арту белән беррәттән, биредә яшәүче татарларның милли, сәяси, мәдәни яшәешендә дә җанлану күзәтелә. Яшьләр, хатын-кызлар өчен милли оешмалар, балалар өчен яңа мәктәпләр эшли башлый.

1920 нче еллардан башлап Ерак Көнчыгышта, бигрәк тә Кытайда һәм Япониядә татар мөһаҗирләренең вакытлы матбугаты барлыкка килә. Шул басмаларның беренчесе итеп, Харбин шәһәрендә нәшер ителгән «Ерак Шәрык» журналын атарга мөмкин. Ул 1920-1922 елларда Гыйниятулла Әхмәди, Хөсәен Габдүш һәм Рәшит Рәхмәтиләр тырышлыгы белән дөнья күрә. Журнал гарәп хәрефләре белән кулдан язып әзерләнә, ташбасма ысул белән басыла. Журналда икътисади, иҗтимагый-сәяси, дини эчтәлектәге мәкаләләр белән беррәттән әдәби әсәрләргә дә шактый урын бирелгән. 1922 елда журнал эшчәнлеге туктап кала, 1924 елда исә шул ук исем белән газета буларак чыга башлый. Әмма 1925 елда бу газета да нәшер ителүдән туктый[1].

Журналның 1921 елның 22 нче (13 май) санында Хатип Халидинең «Габдулла әфәнде Тукай (вафатына 8 ел тулу мөнәсәбәте белән)» исемле хатирәсе урын алган. Әлеге автор турында мәгълүмат татар матбугатында юк дәрәҗәсендә. Фәкать Төркиядә чыккан «Төрек культуру»[2], «Казан»[3] журналларында Х.Халидинең үлеме уңаеннан язылган мәкаләләрдә генә аның тормыш юлы һәм эшчәнлеге кыскача яктыртыла.

Х.Халиди 1893 елда хәзерге Татарстан Республикасы Апас районы Карамасар авылында дөньяга килә. Яшьли әнисеннән ятим кала. Әтисе Нурмөхәммәт шул ук авылның имамы булу белән бергә бакчачылык, умартачылык һәм мал асрау белән шөгыльләнгән. Хатип, кышларын Казанда укып, җәйләрен әтисенә хуҗалык эшләрендә ярдәм итә.

[1] Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. – 2001. – №7. – Б.161-162.

[2] Ali Akış. Hatip Halidi (1983-1978) // Türk Kültürü. – 1978. – №186 (Nisan). – S.383-384.

[3] Emrullah Agi. Hatip Halidi // Kazan. – 1978. – №21. – S.58-59.





«Ерак Шәрык».
1921 ел. №22

1914 елда, Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, Х.Халиди гаскәргә алына, ләкин кулы яралану сәбәпле, демобилизацияләнә. Казанга кайтып, дәвалану белән бергә, укуын да дәвам итә.

Х.Халиди укуын тәмамлаган вакытта Россиядә 1917 елгы Февраль революциясе күтәрелә. Шул ук елның көзендә Төньяк Маньчжуриядәге Хайлар шәһәренә килә. Бирედә укытучылык эше белән бергә имам вазифасын да башкара. Хайлардагы бер төркем рус мөһаҗирләренең Халидигә каршы алып барган интригалары нәтиҗәсендә, ул Хайлардан Кытайның Тяньцзинь шәһәренә күчеп китәргә мәҗбүр була. 1936-1948 елларда шунда яши, төрки-татар җәмәгате арасында мөгаллим һәм имам вазифасын башкара. 1948 елда Кытайда хөкүмәткә коммунистлар килгәч, андагы татарларның күпчелеге Төркиягә, кайберләре исә Америкага күченә. Х.Халиди дә хатыны Зәйнәп, улы Әдип белән 1948 елның көзендә Истанбулга килеп урнаша һәм унтугыз ел дәвамында милләттәшләре арасында имам һәм укытучы эшен башкара[4].

Х.Халиди 1977 елның 29 декабрендә[5], (кайбер чыганакларда 1978 ел дип билгеләнә)[6] Истанбулда кыска вакытлы авырудан вафат була.

Хатип Халидинең Габдулла Тукай турындагы хатирәсен тәүге тапкыр, гарәп язуыннан гамәлдәге язуга күчереп, укучыга тәкъдим итәбез.

[4] Ali Akış.Hatip Halidi (1983-1978) // Türk Kültürü. – 1978. – №186 (Nisan). – S.383-384.

[5] Emrullah Agi. Hatip Halidi // Kazan. – 1978. – №21. – S.58.

[6] Ali Akış. Hatip Halidi (1983-1978) // Türk Kültürü. – 1978. – №186 – (Nisan). – S.383.

ГАБДУЛЛА ӘФӘНДЕ ТУКАЙ

Хатип Халиди

(вафатына 8 ел тулу мөнәсәбәте белән)

Ни өчен әдипләремездән Габдулла Тукай башка әдипләребезгә караганда артык искә төшерелә? Чөнки Габдулла Тукай бөтен вөҗүде белән[1] халкын сөеп, чын ана телендә тирән мәгънәле, мәктәпләребезгә дәрес итеп кертерлек, мисал вә дәлил итеп күрсәтерлек, халкыбыз арасында булган каралык, гакыл вә дингә хилаф гореф вә гадәтләрне халкының кәеф вә хәтерен калдырмаслык ачык вә матур гыйбарәләр белән тасвир вә тәгъбир итеп, милли вә дини хис белән язылган кыйммәтле шигырьләрен бөек хатирә итеп калдырды. Шуның өстенә вакытсыз, яшьли вафат булуы ныграк искә төшертә.

Бер кеше үзенең бик файдалы вә кыйммәтле нәрсәсен югалтса, ничек кайгыра вә аны вакытында саклый алмавына үкенә, шуның кебек Тукайны югалткан татар милләте дә кайгыра вә аны вакытында саклый вә кадерли алмавына үкенә һәм вафаты көннәрендә матәм тота. Шуның өчен татар милләте үзенең шагыйрен искә төшерә, мәктәп балалары ул көн дәрестән туктап, матәм көне ясыйлар, догалар кылып рухына багышлыйлар. Бәгъзе бер гәзитә вә журналлар шулвакытта чыккан саннарында Тукайның татар шагыйре икәнен, халыкның нечкә хисләрен, моң вә зарларын, телен әдәби итеп мәйданга куюын тәкъдир итеп язалар вә аның хакында булган хатирәләрен зикер итәләр[2].

Мин дә мөхтәрәм затның вафатына сигез ел тулу мөнәсәбәте белән аның хакында булган кечкенә генә хатирәмне язып үтәм.

Тукай садә табигатьле[3], ачык чырайлы, һәрвакыт нәрсә булса да көйләп, яхуд[4] Коръән аятьләре укып йөри иде.

Бервакыт 1908 нче елда «Сабах» көтепханәсендә утыра идем, кечерәк кенә, өстенә гади генә тужурка кигән, яланбаш, бала сымак кеше көтепханә ишеген җелтерәтеп ачып, «Вәш-шәмсе тәҗри ли-мөстәкаррин ләһа…»[5] аятен кычкырып укый-укый, еш-еш атлап, эчкә керде дә минем янымда тора торган «Сабах» көтепханәсе ширкәтенең әгъзасы белән күреште. Ширкәт әгъзасы, аның белән таныш булмавымны белгәч: «Танышыгыз, менә Габдулла әфәнде Тукаев», — дип мине таныштырды. Мин, ул ишектән кергәндә: «Бу нинди батыр бала, ишекне җелтерәтеп ачып керә, җитмәсә тагын Коръән укый-укый керә», — дип уйлаган ба-

[1] Вөҗүде белән – барлыгы белән.
[2] Зикер итәләр – искә төшерәләр.
[3] Садә табигатьле – эчкерсез.
[4] Яхуд – яисә.
[5] Коръән. «Ясин» сүрәсенең 38 нче аятеннән өзек. Мәгънәсе: «Кояш Аллаһ билгеләгән вакытка чаклы үзенең юлында йөреп торадыр...» (Ногмани. Коръән тәфсире // http:// kitap.net.ru/sura/36.php).

ласымагым, шагыйрь Тукай булып чыкты. Шушы Габдулла әфәндене беренче мәртәбә күрүем вә танышуым иде. Минем Казанда беренче ел мөгаллимлек вазифасын үтәп торган вакытым иде. Шуның өчен ул миннән ана теле дәресләре хакында бәгъзе бернәрсәләрне сорашты. Соңра, озак вакыт үтмәде, дәфгатән[6]: «Тизрәк, тизрәк, карандаш биреңез әле», — дип карандаш сорады, вә үзе китаплар төреп йибәрә торган кәгазьдән бер кисәк кәгазь җыртып алды да, әллә нәрсә тиз-тиз генә язып кесәсенә салды һәм: «Күңелемә бер шигырь килде дә, шуны онытылмасын өчен язып куйдым әле», — диде. Соңра җомышын җомышлады да кергән вакыттагы адымнары белән әллә нәрсә көйли-көйли чыгып китте.

Аннан соң номерында берничә мәртәбә булырга тугры килде. Һаман ана теле вә әдәбиятымыз хакында кайгырта, мәктәпләребездә ана теле дәресләренең юлга куелып бетмәвенә эче поша иде. Бервакыт номерында, тәрәзә төбендә әллә никадәр төрле шигырьләр язылган кәгазь кисәкләрен күрдем дә: «Габдулла әфәнде, кыйммәтле шигырьләреңез язылган бу кәгазь кисәкләре югалгалап та бетә торгандыр», — дидем. Ул: «Туган, мин күңелемә килгән берен язган да, шунда вакытлы гына ташлаганмын, теләгән вакытымда мин аларны җыеп бер дәфтәргә яза барамын», — диде.

Шулардан аңлап була, Габдулла әфәнде үзенең шигырьләрен күп вакыт көчләнеп язмаганлыгы, кайда гына булса да аның күңеленә килгән вә аны шул ук вакыт кәгазь кисәкләренә яза барганлыгы. Моны Тукай белән якыннан таныш затларның күбесе шулай сөйлиләр.

Алла тарафыннан татар милләте бәхете өчен бүләк ителгән талантлы шагыйрь, аз вакыт эчендә халкына ничә миллионнар торырлык кыйммәтле хатирәсен калдырып, вакытсыз дөньядан китте.

*Текстны басмага **Гөлчирә Ханнанова** әзерләде.* ■

[6] Дәфгатән – кинәт.

КЕМНӘР СОҢ БЕЗ – ТАТАРЛАР?

Рабит Батулла

БӨЕК ЯСА[1]

Чыңгыз ханның бөек максаты — бөтен дөньяны яулау булган, диләр. Озынрак гомер яшәсә, ихтимал, яулар иде дә. Җитмеш яшендә дә гайрәт иясе була әле ул. Монгол дәүләтендәге, гаскәрендәге Ясага буйсынган мөкәммәл тәртипләр турында дөнья тарихчылары сокланып, шаккатып сөйли. Аның гаскәре, хәрби көчләре җиңелүне белми. Кытай, Русия, Әфганстан, Төркия, Сүрия, Тибет, Кавказ, Урта Азия, Украина, Маҗарстан (Венгрия), Польша, Чехия, хәзерге Иран — бу җирләрнең барысын да Чыңгыз хан яугирләре таптап уза.

Илбашы, билгеле, монголларны барысыннан да өстен күреп, үз халкының дөньяга баш булуын теләгән. Ясада язылган: *«Мәмләкәтемдә яшәгән бер генә адәмнең дә монгол кешесен хезмәтче яки кол итеп тотарга хакы юк!» Биликтә*[2] *язылган: «Боргучы токымда, Онон буенда яки Кәрүләндә туган һәр олан өйрәтмичә дә, тәҗрибәсе булмаса да зиһенле, белемле, зирәк, батыр каһарман булачак; шунда туган һәр кыз бала бизәнмичә дә, алтын-көмешсез дә гүзәл булырга тиеш!»*

Чыңгыз хан монголларны дөньяның иң курку белмәс, иң күркәм, чибәр милләте буларак күрергә теләгән.

Ясада (Җасак) язылган кануннар мантыйкый яктан караганда төзек булса да, Чыңгыз ханның үзе кебек үк каршылыклы. Анда бер-берсенә «дошман» маддәләр дә бар.

8 маддә. Ит ашарга теләүчеләр хайванның аякларын бәйләргә, корсагын ярырга, җаны чыкканчы малның йөрәген учында кысып тотарга тиеш. Шуннан соң гына әлеге итне ашарга ярый. Ләкин кем дә кем хайванны мөселманча суя икән, шул кешенең үзен суярга кирәк.

Бу маддәдә без Чыңгызның мөселманнарга булган нәфрәтен күрәбез. Ләкин Бөек Ясада мондый юллар да бар:

10 маддә. Ул (Чыңгыз хан) әмер итте: Галибәкнең токымы, Әбу Талипның токымы салымнардан, биремнәрдән азат булырга тиеш. Фәкыйрь дәрвишләргә, Әл-Коръән укучыларга, дәвалаучы табибларга, фән кешеләренә, гомерләрен

*Дәвамы. Башы 2-3 саннарда.

[1] Чыңгыз хан тарафыннан игълан ителгән һәм киләчәктә аның торыннары тарафыннан һәрдаим танылган, хупланган кануннан җыелмасы.

[2] Ясак бик күп биликләрдән (бүлекләрдән) тора, бу сүзне «маддә», «статья» дип тәрҗемә итәргә булыр иде.

дога укуга багышлаганнарга, дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичкәннәргә, мәзиннәргә, мәет юучыларга да салым салмаска, алардан бирем алмаска.

ЧЫҢГЫЗ ХАННЫҢ ТӨП УН КАГЫЙДӘСЕ (арада бүгенге җитәкчеләр өчен дә әһәмиятлеләре юк микән?):

1. Тугры кешеләрне бүләклә.

Чыңгыз сабый чакта, кыенлыкта калган заманнарда үзенә ярдәм иткәннәрне берквакытта да онытмады, бүләкләде, аларны югары дәрәҗәләргә күтәрде.

2. Юксыл бул.

Яу-ау вакытларында үзенә аерым шартлар таләп итмәде. Юксыл монголга өстендәге киемен салып бирә иде.

3. Миһербанлылык кыл.

Чыңгызның бер туганы хаинлек эшләде, хан аны үтерергә боерды. Ләкин иң якын киңәшчеләре — Богурчы, Мукхали, үги кардәше Шиги ханга бу уеннан кайтырга киңәш иттеләр. Чыңгыз риза булды һәм туганы өстеннән үлем җазасы алынды.

4. Сәләтле кешләрне эзләп тап һәм аларга таян.

Бер чабан-көтүче гаскәрбашы биеклегенә күтәрелде. Чыңгызны ук белән яралаган бер дошман, әсир төшкәч, ханның уң кулына әверелде. Сәләтле кеше, монгол булмаса да, Чыңгыз янында дәрәҗәләр ала иде.

5. Дошманыңны вөҗдан газабы кичермәстән үтер.

Чыңгыз хыянәтчеләргә, хәтта алар кардәш булсалар да, рәхимсез иде. Хатыны Бөртәне урлаган мәркитләрне ул берәмтекләп, соң кешесенә кадәр үтереп бетерде. Атасын агулаган дип, татарларны да кырып чыкты, юк итте. Тунгут кабиләсе дә, ант бозганы өчен, ахыр адәменә чаклы тар-мар кителелде.

Гарәп тарихчысы Рәшидэддиндә мондый истәлек бар. Берзаман Чыңгыз Богурчы һәм башка аркадашлары белән ат уйната икән. Ялга туктаган арада ул:

Чыңгыз хан туып үскән Онон елгасы буйлары

Үгэдэй

— Ир кешене нәрсә бәхетле итә? — дип сорый.

— Өйрәтелгән шоңкар, лачын, карчыга белән киек аулау! — дип җаваплыйлар аңа.

— Юк! — ди хан.

— Ике тез арасындагы яхшы ат! — диләр.

— Юк, яраннарым, дөрес әйтмәдегез, — ди Чыңгыз. — Ир кешене бәхетле итә торган нәрсә — бу: дошманыңны куып җитеп, аны ияреннән бәреп төшерү, үлҗәсен (сугыш коралларын, киемен) алу, хатыннарының күз яше белән елаганнарын карау, аның биясенә атлану, хатыннарыннан түшәк буларак, кием буларак файдалану, алсу гөл төсендәге имиләрен үбү, имиләре кебек кызыл иреннәрен иму.

Дөрес, Рәшидэддиннең бу язмасын шик астына алучылар да юк түгел: янәсе, ул, Чыңгыз ханны сөймәгәнгә күрә, махсус шулай арттырган. Гәрчә, башкалар Рәшидэддин монголларны артык мактый, диләр.

6. Золымчыларга[3] каршы чык.

7. Үзеңнән түбән утырган җитәкчеләргә ачык бул һәм киңәшләшеп гамәл кыл.

8. Синең арка ягында Тәңре химаясе торганын онытма.

9. Яндашларыңның һәм аркадашларыңның ышанычлы булуын кайгырт.

10. Дин тотуда ирекле булганнарны хөрмәт ит.

Ясада гаиләдәге тәртип турында да язылган:

— ир кеше берничә хатынга өйләнә ала. Беренче хатын баш хатын булырга тиеш;

— өйләнгән ир үзенең хатыннарына ышанырга тиеш;

— ир кеше исерткеч эчәргә тиеш түгел. Исерек ир сукыр кебек яши, ул тормышында берни дә күрми. Сәрхушнең акылы да, вөҗданы да, миһербаны да булмый. Эчә башласа, яхшы кеше яман кешегә әверелә;

— хатыннар ирләрен тыңларга, аларга буйсынырга тиеш. Ир кеше үзен хөрмәт итсә, хатыны да аны хөрмәт итәчәк;

— килен белән каената-каенана берберсенә ихтирамлы булырга тиеш;

— олылар яшь буынны гаиләсенә, үз халкына мәхәббәтле, ватанпәрвәр итеп тәрбияләргә тиеш, олылар яшьләргә үрнәк булырга тиеш;

— балалар ата-аналарының киңәшен тыңларга тиеш;

— ата кеше вафат булса, өлкән угыллар башка чыгарга, ә төп йортка хуҗа булып төпчек углан калырга тиеш;

— байлар мохтаҗларга ярдәм итәргә тиеш.

Бүген дә шушы кануннарны тотып яшәсәк иде!

ҖИҺАНГИРНЫҢ ӘҖӘЛЕ

Кытай җирендә Чан-чунь исемле бер Даос монахының могҗизалар эшләве турында ишетеп, Чыңгыз хан табибны үзенә чакырта. Имеш, Чан-чунь үлемсезлек серен тапкан икән. Милади белән 1219 еллар бу. Озын-авыр юллар узып, Монголстан, Уйгырстан, Голҗа

[3] Золымчы — изүче, гаделсез кеше, зәгыйфьләрне кимсетүче.

тарафларын узып, Мавараэннәһер, Сәмәрканд аша үтеп, Чан-чунь бөек хан янына килеп җитә. Алар якынча 1222 елның сентябреннән 1223 елның апреленә чаклы бергә булалар.

Чыңгызның Даос дәрвишенә әйткән сүзе:

— Артык байлык туплаганнары һәм артык мәгърур булганнары өчен Күкләр Кытайдан ваз кичте. Ә мин котып ягындагы далаларда яшәп, бозык гадәтләргә өйрәнмәдем, пакьлекне яратам, саф әхлакны сөям, байлык вә зиннәтне кире кагам, мин уртача, үземә таман шартларда яшим. Чабаннар ни кисә, шуны киям, алар ни ашаса, мин дә шуны ашыйм...

1223 елның 10 мартында кабан аулаган вакытта Чыңгыз хан атыннан егылып төшә. Имгәнә. Чан-чунь киңәшен тыңлап, өч ай ауга чыкмыйча дәвалана.

Бөек җиһангир, әйтелгәнчә, Чан-чуньны үлемсезлек даруы табып бирергә чакырган иде. Ләкин монах әйтте:

— Үлемсезлек даруы юктыр, бөек хан. Аның каруы, гомер озайта торганын табарга була, — диде.

Кызганыч, Чыңгыз ханның гомерен дарулар гына озайта алмый инде. Сәламәтлеге көннән-көн какшый. Үлеме алдыннан уллары Үгәдәй, Тулуйны һәм оныгы Исүнке-Аканы чакыртып ала ул.

— Балаларым! Мин бик күп җирләрне яулап алдым. Аның бер очыннан икенчесенә барып җитәр өчен бер ел вакыт сарыф итәргә кирәк. Мин, балакайларым, сезнең аяк астындагы җирне ныгыттым... Васыятем шулдыр ки: патшалыкта ләззәт сөрер өчен, рәхәт кичәр өчен, дусларыгызның данын арттырыр өчен, дошманнарны җиңәр өчен, сез бер фикердә булыгыз, бер кеше кебек бердәм-тату яшәгез! Үгәдәй ханны варис итеп калдырыгыз. Үлемемнән соң Ясаны үзгәртү катгыян тыела! Патшалыгымда талашызгыш булмасын өчен шулай кирәк.

Шаһин Гәрәй

Чыңгыз ханның әҗәле турында да уртак фикер юк. Рәшидәддин: «Бөек хан үз үлеме белән үлмәде», — ди. Плано Карпини: «Чыңгызны яшен сугып үтерде», — ди. (Бу сүз күчерелмә мәгънәдә кулланылырга да мөмкин.) Овен Латиморенең «Монгол сәфәрләре» исемле әсәрендә вакыйгаларның мондый агышы да тәкъдим ителә: *«Чыңгыз хан саф килеш сакланган бер кызга өйләнмәк була. Ерак Тунгут өлкәсендәге бер падишаһның кояш чәһрәле гүзәл баласы бар икән. Киңәшчеләре ханга шул сылу турында сөйли. Ханның теләген үтәмәгәннәргә ни буласын бик яхшы аңлаган падишаһ бердәнеберен хан илчеләренә биреп җибәрергә ризалаша. Ләкин хушлашу алдыннан ата кеше кызына бик тә үткер хәнҗәр бирә: бу хәнҗәрне ал, аны киемеңә яшереп сакла, вакыты җиткәч, ни кылырга икәнен аңларсың, ди.*

Хан падишаһның кызы белән ятакка ава. Мөһим вакыт килеп җиткәндә генә яшь килен яшен тизлеге белән Чыңгызның җенси әгъзасын кисеп ташлый. Илбашы шәрран ярып акыра, аның авазына сакчылар йөгереп керә. Ләкин

Иң соңгы мөстәкыйль татар дәүләте – Кырым ханлыгы

хан аларга: «Бу кызны моннан алып чыгыгыз, минем йокым килә», — ди. Үзе түшәккә ята, шундук йокыга да китә, шул йокысыннан уянмый да...»

Мондый яисә моңа охшаш эчтәлекле берничә риваять тә мәгълүм.

Инде янә җитдиләник. Академик Василий Бартольд язганча: *«Бөек Чыңгыз хан никадәр генә зиһенле, алдан күрүчән булмасын, асылда ул, беркатлы сабыйлар кебек, үлемсезлеккә ышанган кеше була. Даос монахы Чан-чунь, чыннан да, үлемсезлекне эзләгәндер. Һәм тапкандыр да. Ләкин Чыңгыз хан үлемсезлекне туры мәгънәдә, физик мәгънәдә генә күз алдына китергән, күрәсең. Даос фәлсәфәсендә бу хакта Дань тәгълиматы бар, ул «фәлсәфә ташы» дип атала. Чан-чунь әнә шул тәгълимат тарафдары. Бу монахлар рухи дөньяда гына хәзинә табарга, тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән аерылып, бар булганына шөкер итеп, фәлсәфи тынычлыкка, фәлсәфи камиллеккә омтылалар. Берничә ай буе барган әңгәмәләрендә Чан-чунь рәхимсез яулап алучы, бихисап күп бай шәһәрләрне харап иткән, миллионлаган халыкларны кырган бөек җиһангирны кан коюдан, илләрне таладан ваз кичтерергә, үлемсезлеккә яхшы гамәлләр аша гына ирешергә мөмкин икәнлеген аңлатырга тырышкандыр, мөгаен».*

Чыңгыз хан үз урынына Үгәдәйне калдыра. Үгәдәй һәряктан килгән, гадел, кодрәтле дәүләт төзергә тели. Аның әйткән сүзләре:

— Безнең хан атабыз — Чыңгыз — күп кыенлыклар аша бөек ватаныбызны корды. Хәзер инде халыкларны таламаска, аларга тынычлык вә муллык бирергә вакыт җитте!

Чыннан да, Үгәдәй тәхеткә утыргач, яу чабулар сирәгәя. Илдә яңа бер вазифа барлыкка килә — таньмачы (тамгачы). Бу шәхес мәмләкәттәге салымнарны җыеләйтү һәм почта эшләрен камилләштерүне җайларга тиеш була. Һәр 30 чакрым саен бер ям (станса) булдырылырга, шунда юлчылар өчен ашау-эчү, ятак, ат алыштыру кебек

мөһим шартлар тудырылырга, һәр ямда 1000 кеше хезмәттә торырга, андагы елкыларны, куйларны көтәргә, аларны савып, сөт-кымыз ясарга зарур табыла. Кызганыч, Үгәдәй корган теләкләрен ахырынача тормышка ашыра алмый, хәмер эчүгә салыша һәм 1241 елның 11 декабрендә бакыйлыкка күчә. Авыр туфрагы җиңел булсын!

ЧЫҢГЫЗ ХАН «МИРАСЫ»

2003 елның мартында «Amerikan Journal of Human Genetics» журналында гадәттән тыш бер мәкалә басылып чыкты. Сөземтәсе мондый: генетиканы өйрәнгән 23 галим катнашында Аурупа һәм Азия киңлекләрендә гомер кичергән 2000ләп ир-атның ДНК үрнәге тикшерелгән икән. Белгечләрне хәйранга калдырганы шул: тикшерелүчеләрнең күп өлеше уртак геннарга ия булып чыга! Әлеге геннар Каспийдан алып Атлантика океанына хәтле җирләрдә яшәгән халыкларның байтагында очрый, ә бу исә — шушы туфракта тормыш иткән 16000000 ир затының, асылда, бер геннан үрчегәнен раслый!

«Y» (игрек) хромосомасы хатыннарда булмый, ул бары тик ир җенесле адәмнәргә генә хас. Шушы хромосомада һәркемнең үз «имзасы» саклана икән. Әнә шул «имза» аша бүгенге кешеләрнең 850 ел элек яшәгән борынгы бабасын хисаплап чыгарганнар. Тикшеренүләрдә катнашкан галимә Татиана Зәрҗал ул затның исемен ачыктан-ачык: «Чыңгыз хан!» — диде.

Җаһн (Джон) Манның «Чыңгыз хан: хәяте, үлеме вә яңадан терелеше» хезмәтенә тукталыйк (13-14 битләр): *«Чыңгыз ханга чаклы көн күргән Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский), мөселман илләрен кырган Хаҗ яулары «каһарманнары», Чыңгыз ханнан соң яшәгән Аксак Тимерләр, Баязит Елдырымнар, Сөләйман Канунилар, Наполеоннар, генералиссимус Сталиннар халыкларны кол итеп, шәһәрләрне юк итеп, артларыннан миллионлаган мәетләр, харәбәләр калдырып, нинди сәгадәткә иреште соң? Урта гасырларда дөньяга баш булган монгол кавеменнән ни калды? Өйрәтелмичә дә каһарман, бизәнмичә дә гүзәл булган монгол токымы кайда? Чиндә (Кытайда) калган монголлар Мао Цзэдун тегермәненә эләгеп, юкка чыгу чигенә килеп җитте, бу якта калган монголлар Совет империясенең артта калган бер вассалы сыйфатында көчкә җан саклап килде. Чиндәгеләрнең күбесе кытайлашты; Аурупага, Русиягә ябырылган монголлар татарлашты, мөселманлашты. Бурят-монголлар белән калмыклар урыслашуга йөз тотты. Хәзер элеккеге бөек Монгол мәмләкәтендә яшәгән күптөрле (монгол булмаган) халыкларның ир-атларында сакланып калган «Y» хромосомасы белән мактансалар гына инде!»*

Кара Дауан язганча, шулай да, бөек җиһангир Чыңгыз ханның максаты башка баскыннарныкыннан шактый аерыла. Искәндәр дә ярты дөньяны буйсындыра, югыйсә. Ләкин үзе үлүгә гаскәр башлыклары аның хакыйкый варисын — углын — куып, тәхет өчен сугыша башлыйлар. Ил таркала.

Наполеон да бөтен мирне яулап алырга тели. Әмма Чыңгыз ханнан аермалы буларак, ул үз гаскәрен иң авыр вакытта ташлап качуны гадәт итә: Мисырда, Русиядә... Нәтиҗәдә, гомерен сөргендә уздыра, улы мирассыз кала, бөек җиһангир Наполеонның мәмләкәте үзе үлгәнче үк җимерелә.

Ленин-Сталин корган Советлар Союзы йөз ел да яши алмады.

Татарлар исә Алтын Урда (Олуг Олыс) таркалганнан соң да дәүләт арты дәүләт төзи: Себер ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Кырым ханлыгы, Касыйм ханлыгы, Казан ханлыгы... Бу илләрнең тәхетендә (барысында да!) Чыңгыз токымы утыра. Дөрес, алар инде татар телле мөселманга әверелә. Үзе үлгәннән соң да бөек ханның мәмләкәте һәм варислары 500

ел яши әле! Чыңгызлылардан саналган соңгы илбашы — Кырым ханы Шаһин Гәрәй XVIII гасырда (1783) тәхеттән төшерелә. Аның максаты да дала халыкларын бергә туплап, уртак бөек дәүләт кору һәм шул дәүләттә тынычлык вә гаделлек урнаштыру була...

Нинди төгәл зиһният[4] белән корылган Чыңгыз иле да җимерелгәч, черек баганада утырган Русия империясенең егыласы көн кебек ачык. Бүген Ленин белән Сталин уянса, үзләре төзегән «коммунизм»ны күреп шаккатыр иде. Халыкларга бәхет алып киләбез дигән булып, бу ике иблис милләтләрне фаҗигагә, гариплеккә этәрде ләбаса! XIX-XX гасырларда яшәгән бөек вә рәхимсез деспотлар, бигрәк тә Сталин, Чыңгыздан шактый нык аерылып тора. Хан үзенә кайчандыр ярдәм иткәннәрне янына алдырган, үстергән, аларга дәрәҗәләр һәм идарә биргән. Сталин исә үзенең иң якын яраннарын үтертүдән тәм тапкан.

Мөхәммәт пәйгамбәр дә бик күп илләрне яулаган гаскәр башлыгы, аның тырышлыгы белән Испания, Африка, Төркия, Иран, Гыйрак, Күвәйт, Кытай, Һиндстан, Пакьстан, Урта Азия, Идел буе ислам динен кабул итә... Ләкин Мөхәммәтнең иманга өндәве белән Чыңгыз ханның басып алулары арасында да аерма бихисап. Пәйгамбәр халыкларны күпләп кырмаган, таламаган, ислам кылыч белән кертелмәгән. Мәҗбүрият аркасында мәҗүсиләр, нәсаралар, яһүдиләр арасында сугыш тулары кабынган икән, ул канкоеш барыбер Чыңгыз хан, Аксак Тимер канкоешыннан күпкә, бик күпкә ким булган. Пәйгамбәребез үлүгә дә аның империясе тиз генә таркалмый. Әле бүген дә бер миллиард ярым мөселман Җир йөзендә яшәп ята. Кылыч — яулап алу коралы булса да, сына, чери, ә идея кодрәте сынмый да, череми дә!

Чыңгыз хан — Маньчжуриядән алып Польшага кадәр, Себердән алып Һиндстанга кадәр бөек мәмләкәт корган шәхес. Аның иле Искәндәрнекеннән — дүрт, Румныкыннан ике тапкыр зуррак була (мәйданы — якынча 28 миллион квадрат чакрым, соңрак — 38 миллион квадрат чакрымга җитә).

Чыңгыз хан — канәчкеч, миһербансыз бер залимме? Әйе. Ләкин аның зобанилыгы исемнәре элгәре телгә алынган адәмнәрнекеннән артык түгел. Италия, Испания, Франция, Һолландия конкистадорлары Американың җирле халыкларына карата Чыңгыз ханнан рәхимлерәк кыланганмыни? Явыз Иван, Пётр Беренче, Русиянең башка императорлары җирле халыкларга карата Чыңгыз ханнан шәфкатьлерәк булганмы?

Бүген күк астында ни хәлләр кылынганын күрсә, Чыңгыз хан да аптырар: «Кайда минем бөек солтанатым? Кайда минем дөньяга баш буласы бөек монгол милләтем?» — дияр иде. Әмма татарча сөйләшүче миллионлаган мөселман торыннарын, кытайча сөйләшүче миллионлаган буддачы-монголларны күргәч, тәмам гаҗиз булыр иде, мөгаен: «Кытайлашыгыз, татарлашыгыз, үзбәкләшегез, казакълашыгыз, дип төзедеммени мин ул мәмләкәтне?» Шулай бит?

Бөек җиһангир Чыңгыз хан Дуңгыз елында (1227) Тәңре хозурына ирешә. Аны Борхан-Халдун тавына җирлиләр, ләкин тауның тәгаен кайсы урынына җирләнгәне сер булып кала. Шаһитлар калмасын өчен, имеш, аны гүргә иңдергәннәрне үтерә барганнар. Монголларның изге китабы — «Яшерен тарих»та ханның дәфен кылынуы хакында берни дә язылмаган.

Чыңгыз хан үзенең Җир йөзенә Тәңресе тарафыннан җибәрелгәненә, Мәңгелек Җәннәтнең барлыгына һәм шул Җәннәткә, һичшиксез, кереренә ихлас инанып яшәгән.

Анысын инде бер Аллаһы Тәгалә үзе хәл итә!

Ахыры бар ■

[4] Зиһният — фикер, идея.

Ш.МӘРҖАНИ МИРАСЫНДА ТАТАРЛАРНЫҢ МИЛЛИ ҺӘМ ДИНИ ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШЕ

Илдус Заһидуллин

Урта Азиядән дини белем эстәп кайтып, 1849 елдан Казан каласының беренче мәчете имамы буларак хезмәт юлын башлаган Ш.Мәрҗани биобиблиографик җанрда иҗат итәргә керешә. Галимнең язма мирасы XVIII-XIX гасырлардагы татар зыялысының бер төркеме булган дин әһелләре биографияләрен, алар кылган гамәлләр аша мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр тарихын, мәдәният сәхифәләрен өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып тора.

Җиләнне киеп йөрү ысулы. Казан татары

Ул заманда татарларның менталитеты дини булганлыгын һәм мәдәни тормыш күбрәк дини кысаларда барганлыгын искәртсәк, Ш.Мәрҗани хезмәтләре безгә татарларның милли һәм дини тормыш күренешләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Галимнең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендәге татар дин әһелләре турындагы төгәл биографик мәгълүматлар, әлбәттә, автор тарафыннан тупланган информациянең бер өлеше генә. Бу хезмәттә, шулай ук, Казан тирәсендәге кайбер татар авылларының кыскача тарихына, Казан шәһәре мәчетләре, шәһәрнең татар ратушасы тарихына, Мәхкәмәи шәргыя-и Ырынбургыяга һәм мөфтиләргә багышланган бүлекләр бар.

Мәрҗанинең бигрәк тә XVII гасыр ахыры-XIX гасыр башында татарларда дини белем системасының яңаруы, мәдрәсәләр, Урта Азиядә укып кайткан беренче шәкертләр турындагы текстлары — бүгенге көнгә килеп җиткән бердәнбер чыганак. Рус чыганакларында чагылыш тапмаган мондый кыйммәтле мәгълүматны Ш.Мәрҗани күп шәхесләр белән аралашу, сораштыру һәм язышу, үзенең әти-бабасының һәм башкаларның истәлекләре аша туплаган, күрәсең.

Текстларда күзгә ташлана торган мөһим үзенчәлек — 1742-1744 елларда хөкүмәт тарафыннан массакүләм мәчетләрне җимерү кампаниясенең татарларда яшәп килгән мәктәп-мәдрәсәләргә, гомумән мәхәлләләрнең дини көнкүрешенә артык йогынты ясамавын билгеләү. Идел-Кама төбәгендә яшәгән мөселман дин әһелләре һәм мәхәлләләр хөкүмәт тарафыннан танылмый, эзәрлекләүгә дучар ителми, дини тормыш һәр авылның эчке эше булып кала бирә. Чөнки ул чорда хакимият мөселманнарның дини тормышын махсус күзәтмәгән.

Тагын бер игътибарны җәлеп итә торган күренеш — 1789 елда Мәхкәмәи шәргыя-и Ырынбургыя оешып, Урта Идел төбәгендә дин әһелләрен рәсми рәвештә таный башлаганчы һәм аннан соң да дини тормыш белән җитәкчелек итүнең, дини белем һәм тәрбия бирүнең бик еш кына аерым нәсел вәкилләре кулында булуы. Ш.Мәрҗани укыйяза белүче, дини ритуаллар башкаручы бу кешеләрне элекке гасырларда хафиз, ягъни Корьәнне яттан белүче дип йөрткәннәрен ассызыклый [1:242-243]. Кырым ханлыгында дини вазифаларның нәселдән нәселгә тапшырылуы мәгълүм. Урта Идел буенда бу традиция Казан ханлыгы заманыннан калган булган, күрәсең. (Шунысы кызык: элек хафиз булып йөргән шәхесләр үзләре һәм аларның уллары 1789 елдан соң указлы мулла булып киткәннәр. Ш.Мәрҗани хезмәтендә чагылыш тапкан бу күренеш архив чыганаклары белән исбатлана [2:89]). Ш.Мәрҗани бер үк вакытта ислам институтларының рәсми танылмау шартларында яңа рухани династияләре барлыкка килүен дә шәрехли.

Ш.Мәрҗани Россия дәверендә татарларның борынгы мәдрәсәләре турында да язып калдырган. Биредә сүз Кариле (1768 ел) [1:238, 285], Бай Оланнар (1757 ел) [1:282], Орнашбаш (XVIII гасыр азагы) [1:283], Ашыт (XVIII гасыр азагы) [1:283, 287], Мәчкәрә (XVIII гасыр азагы) [1:284], Казаклар (1779 ел) [1:285] авылларындагы дини уку йортлары турында бара.

Дин әһелләренең биографияләре кайбер татарларның Казакъ даласы һәм Урта Азия белән икътисади бәйләнешләре, элемтәләре инде XVII гасырда ук күзәтелгән, дигән фикерне ныгыта. Әйтик, Казан өязенең Бөрбаш авылына нигез салучы **Көчекнең углы Туктаргали** (1669 елда үлгән) Оренбург һәм Каргалы тирәләрендә сәүдә белән шөгыльләнгән [1:230].

Ш.Мәрҗанигә билгеле чыганакларга

Татар ахуны. 1804 ел

караганда, XVII гасырда Урта Азиягә, Мәвараэннәһергә, дини белем эстәргә беренче булып, Казан өязе Кәче авылының булачак ахуны **Юныс бине Иванай** киткән. Ул күчереп язган Коръән кулъязмасы 1649 елда тәмамланган [1:231, 233, 234]. XVII гасырның икенче яртысында Мәвараэннәһердә суфи мулла **Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети** (1723 елда үлгән) белем алган, аның 1703 елда күчергән дини китабының кулъязмасы сакланган [1:234-235]. Аның укучысы, Зөя өязе Борындык авылы кешесе, беренче Оренбург диния нәзарәте мөфтие булачак **Мөхәммәтҗан Хөсәеневнең бабасы Мансур** да XVII гасыр азагында Бохарада укыган, туган илгә кайткач зур мәдрәсә тоткан. Аның фарсы телендә үзе күчереп язган «Тәракыйбе-Мансурия» исемле китабы сакланган [1:235-236].

Ш.Мәрҗани XVIII гасырда татар яшүсмерләренең дагыстанлы голәмәләрдән белем алулары турында хәбәрдар була. Ул Дагыстаннан, ватанын калдырып, Оренбург янындагы Каргалыга күченгән һәм бередә мәдрәсә тоткан күренекле дин галиме **Мөхәммәд бине әд-Дагыстани** (1795 елда үлгән) турында яза [1:243].

Урта Азиядән кайтып указлы мулла булганнар, мәхәллә халкын шәригать кануннарын саклауга өндәп, дин кардәшләренең көндәлек тормышына күзәтчелек итәләр, муллалар әзерли торган укыту системасын булдыралар, татарлар арасында дини кыйммәтләрнең йогынтысын арттыралар, йолага нигезләнгән күп кенә гореф-гадәтләргә үзгәрешләр кертәләр.

Казан каласында мөселманнарның көндәлек тормышында кискен үзгәрешләр Кавказ ягында белем алып 1780 елда туган иленә кайткан һәм 1793 елдан беренче мәчет имамы булган күренекле дин әһеле **Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казани** шәхесе белән бәйле. Моңарчы татар бистәләрендә ир-ат һәм хатын-кызлар мәҗлесләрне бер бүлмәдә бергә корсалар, яңа имам бәйрәмнәрне, мәҗлесләрне ир-атлар һәм хатын-кызлар аерым билгеләп үтү тәртибен урнаштыра. *Ибраһим бине Хуҗаши Казанга килгәнче, бистәдәге ир-атларның өстендә кыска чикмән, башларында кара эшләпә, аякларында күн итек булса, имам мондый киенү рәвешен шәригатьчә түгел, дип тыя* һәм бистә урамнары буйлап мәчеткә яки башка берәр мәҗлескә барганда *башка чалма киеп йөрүне мәҗбүри*

итеп куя. Җәмәгать намазына башка чалма урап бару гадәте урнаша. Берничә бай сәүдәгәр, Ибраһим бине Хуҗаши белән килешмичә, Мәскәүгә барып заказ биреп, элекке формадагы ак төсле эшләпә ясатып кайталар. Шулай итеп Казан шәһәрендә һәм авылларда татарлар арасында ак эшләпә кию модасы, гадәте барлыкка килә.

Бистә татарларының җәйге киемнәре дә тамырдан үзгәреш кичерә, алар Ибраһим бине Хуҗашиның «мөселманча» киенеп йөрүне таләп итүе буенча [2:52] *чикмән урынына җилән киеп йөри башлый.* Ш.Мәрҗани тегүчедән беренче булып җилән тектереп кигән бистә татары исемен дә атый. Җилән бистә хатын-кызлары арасында зур кызыксыну уята. *Күн итекләрне Урта Азия башмаклары һәм читекләре алыштыра.* Алай гына да түгел, Казанның татар бистәләре тиз арада яңа «мөселман» аяк киемнәрен тегү үзәгенә әверелә. Казан читеккәвешләре зур партияләр белән Урта Азия базарына, эре ярминкәләр аша мөселманнар яшәгән төрле төбәкләргә тарала [3:XLIX]. Бүген ул читеккәвешләр татар милли аяк киеме буларак кабул ителә.

Ибраһим бине Хуҗашиның җирле гореф-гадәтләргә ислам дине рухы бирү ягыннан керткән *тагын бер яңалыгы — яшьләрнең никахлашу мәҗлесенә җыелгач намаз уку һәм киявгә намазлык бүләк итү. Киленнәр исә булачак ирнең йортына төшкәндә комган белән бару тәртибен үзләштерә* [1:267]. Шулай итеп, Урта Азиядә яки Кавказда укып кайткан татар шәкертләре тырышлыгы белән халыкның гореф-гадәтләре ислам рухы белән сугарыла, төгәлрәк әйтсәк, ислам йолалары белән милли гореф-гадәтләрнең синтезы формалаша.

Имамнарның авыл халкы тормышы өстеннән күзәтчелеге, балалар укытуы һәм тәрбияләве кайбер мәҗүси йолаларның юкка чыгуына да китерә. Шундыйларның берсе Нәүрүзне — төркичә яңа елны — бәйрәм итү. Ш.Мәрҗани XVIII гасыр-XIX йөз башында Казан өязе Мәмсә авылы мулласы **Муса бине Габдерәшид әт-Түнтәринең** Нәүрүзне матди мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү йоласына әвереелдергәнен теркәп куйган, ягъни ул вакытта төрки бәйрәм инде үзенең асылын югалтып, мулла файдасына ашлык җыю чарасына әверелгән була. Март аенда бу көнне мулла үзе, Нәүрүз мөбәрәк булсын дип, авылдагы йортларны урый, аның артыннан 40-50 авыл агае, ат чаналарына җигелеп, болай дип җырлап барганнар:

Нәүрүз әйтәбез, килдек,
Котлыг җәмаленәзне күрдек,
Нәүрүз мөбарәк бад.
Батман бирсәң — күп булыр,
Подаука бирсәң, аз булыр,
Шади бад, шади бад.

Мулла Нәүрүз бәйрәме белән котлап кергән һәр йортның хуҗасы чанага капчык-капчык ашлык чыгарып салган. Мондый йола Казан арты төбәгенең башка авылларында да күзәтелгән [1:260]. Соңрак Нәүрүзне бәйрәм итү гадәте Идел-Кама төбәге авылларында тәмам юкка чыккан.

Мәрҗани тексты буенча татарларның дини һәм милли тормышын өйрәнү өлкәсендә галимнәрне әле тагын яңа ачышлар көтә.

Әдәбият:

1. Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи ахвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 415 б.
2.Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII-XIX вв. Уфа: изд-во «Гилем», 1996. — 194 с.
3. Морозов И.Л. Экономика татарской пореформенной деревни и массовое движение татарского крестьянства в Татарии 50-70 гг. XIX в. // Материалы по истории Татарии второй половины XIX века. Часть первая. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1936. С.I-LXXI. ■

«ШИҺАБЕТДИНЕМЕЗ БЕР ИДЕ...»

Ленар Гобәйдуллин

1915 елны татар халкы зур бәйрәмне – тарихчы, илаһият галиме, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең (16.01.1818-30.04.1889) һиҗри ел исәбе буенча тууының (1233-1333) 100 еллыгын билгеләп үтә.

9 (22) нчы гыйнвар, җомга көн Казан һәм татарлар күпләп яшәгән башка шәһәрләрдә «Мәрҗани көне», «Мәүлид әл-Мәрҗани» үткәрелгән. Казанда әлеге көнне хөрмәтләп уздырыр өчен махсус һәйят тәшкил ителә, программа төзелә. Иртән «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталарының Ш.Мәрҗани рәсеме, тәрҗемәи хәле, аның турында истәлекләр басылган саны таратыла. *«Бу эш газета ала торган өй эчләренә генә түгел, мөселманнар тора торган урамнарга да хосусый бер төс, бәйрәм төсе биреп өлгерде. Иртәдән үк инде халыкның олысы-кечесе, баефәкыйре – һәммәсе Шиһабетдин әл-Мәрҗани хакында беркадәр мәгълүмат алып өлгерделәр»*, – дип язылган истәлекләрнең берсендә. Шулай итеп, татар вакытлы матбугаты ярдәме белән Казан шәһәренең мөселманнар яшәгән һәрбер почмагында Мәрҗани турында хатирәләр яңартыла, аның турында сөйләнелә, яд кылына. «Кояш» һәм «Йолдыз»ның «Мәрҗани газетасы» исеме белән танылып өлгергән юбилей саны, гадәттәгедән күбрәк тираж белән басылуны карамастан, көн уртасына инде бер нөсхәсе калмый, сатылып бетә. Шунысын да искәртик, 1915 елның гыйнвар аенда дөнья күргән татар журналларының да үзәгендә – Мәрҗани темасы. Мәсәлән, «Аң» журналында Г.Ибраһимовның «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре (китаплары)», Ш.Шәрәфнең «Шиһабетдин әл-Мәрҗани» исемле саллы мәкаләләре басылып чыга, Оренбургтагы «Шура» журналының да тәүге сәхифәсе Ризаэддин Фәхреддиннең «Мәрҗани» исемле мәкаләсе белән ачыла.

«Мәрҗани көне»ндә Казан мәчетләре гает көнен хәтерләткән. Олуг мәгърифәтче рухына Коръән укылган, алдынгы карашлы имамнар мөнбәрдән мәрхүм турында сөйләп, аның кылган изге гамәлләрен искә алган. Рус мәхәлләләренә якын булган мәчетләргә рус мәктәбендә укучы мөселман егетләре күпләп килгән. Шулай ук мәктәп-мәдрәсәләрдә дә Ш.Мәрҗанине искә алганнар. Мөгаллимнәр аның тормыш юлы, эшчәнлеге турында шәкертләргә мәгълүмат биргән.

Шунысы кызганыч, «Ил» газетасы хәбәр итүенчә, «Мәрҗани» мәчетенә җыелып дога кылу мәрасиме булмаган. Моңа мәчет имамы, мәрхүмнең кияве Сафа хәзрәт: «Полициядән рөхсәтсез мин булдыра алмыйм», – дип каршы төшкән. Мөгаен, бу чикләү хакимият тарафыннан мөселманнарның Мәрҗани шәхесенә нисбәтле бер урынга күпләп туплануыннан саклану өчен махсус эшләнгәндер.

Бу көнне иртәдән кичкә кадәр халык Мәрҗани каберен зиярәт кылган. *«Килүчеләр арасында сыйныф төрлелеге гаҗәеп бер дәрәҗәдә иде: ап-ак сакаллы, зур чалмалы бер хәзрәт белән бергә студент формасындагы фуражкалы егетләр, хәтта котелоклы әфәнделәр бу кабер янына киләләр, Коръән укыйлар, дога кыла-*



«Мәрҗани» китабы. 1915 ел*

лар иде», — дип язылган чыганакта. Зиратка килүчеләрдән зыялы казакъ егетләре, кавказлылар һәм башка милләт вәкилләре дә булу Мәрҗанинең гомумтөрки һәм ислам дөньясында мәшһүр шәхес булганлыгының бер дәлиле. Көндезге сәгать икедә зиратка руханилар җыелган.

Кичен исә шәһәрнең бөтен алдынгы сыйныфы, имамнар, матбугат әһеле, зыялылар Шиһабетдин Мәрҗанинең улы Борһан хәзрәт Мәрҗани йортына Коръән мәҗлесенә җыелган. Зыялылар биредә галимнең әсәрләре, тәрҗемәи хәле турында сөйләшкән. Мәрхүмнең якыннарыннан берсе Мәрҗанинең васыяте үтәлмәгәнен — «Вафийәтел-әсляф» китабының басылып чыкмаганлыгын искә төшерә һәм мәҗлескә килгән зыялылар бу китапны бастырып чыгарырга карар кыла. «Мәрҗани» җыентыгында Галимҗан Баруди: *«Шул китапны бастыру өчен җитәрлек батырлык һәм тырышлык һаман да Казан тирәсендә булмады. Моннан соң ни булыр?»*, — дип яза. Әмма, ни кызганыч, алты томнан гыйбарәт, төрле галимнәрнең тәрҗемәи хәлләре турындагы бу кулъязма китап басылып чыкмый һәм, соңгы еллардагы кыска гына тәрҗемәләрне искә алмаганда, үз укучысын тапмый. Шул сәбәпле бүгенгә кадәр Ш.Мәрҗанинең васыяте үтәлмәгән, дияргә була.

Мәрҗанине искә алу соңрак та дәвам итә. Мәсәлән, мәүлид бәйрәме көнне 14 (27) гыйнварда Фатих Әмирханның этисе — 9 нчы мәхәллә (Иске Таш мәчете) имамы Зариф Әмирхани үз мәчетендә Мәрҗани рухына Коръән укылачагын белдерә. Ә тарихчы Әхмәтзәки Вәлиди 23 гыйнварда (5 фев.) Казан университетында Мәрҗани хакында доклад укый. Мәрҗанине искә алырга Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте әгъзалары һәм университетта укучы яшьләр килә.

Мәрҗани тууының 100 еллыгы Уфада да олылап үткәрелә. Җомга көнне мәчеттә дога мәҗлесе уздырганнар, Коръән укыганнар, Җиһангир хәзрәт тарафыннан нотык сөйләнгән. «Тормыш» газетасының мөхәррире, яшь галим Закир Кадыйри Мәрҗанинең Бохарадан Казанга кайтканчыга кадәрге, Хәсәнгата Габәши Казанга кайтканнан соңгы биографиясе, эш гамәлләре белән халыкны таныштырган, *«аңа каршы булган наданлык хәрәкәтләренең бәгъзе мөһим нокталәрен хикәят иткән»*. 10 (23)гыйнварда хәйрия җәмгыяте тарафыннан 4 нче мәчеттә ясалган мәүлид һәм дога мәҗлесендә дә Мәрҗани хәзрәтләренең әсәрләре, аның фикер-карашлары, мәсләге хакында мәгълүмат бирелгән.

«Вакыт» газетасы моңа охшашлы чараны Оренбургта үткәрүнең «фәүкылгадә әхвәл (гадәттән тыш хәл) сәбәпле» кичектерелүе турында хәбәр итә (1913. — №1673, 1679). Газетаның алдагы саннарында да «Мәрҗани көне»нең үткәрелүе турында хәбәрләр юк.

*Тышлыкта Исмәгыйль Гаспринскийдан цитата китерелгән: «Шиһабетдинемез бер иде; кадер вә кыйммәтене белмәк аның өчен дәгел, безләр өчен ифтихардыр (горурлыктыр)».

Күрүебезчә, узган гасыр башындагы «Мәрҗани көне», хәзерге вакыттагы кебек тар даирә катнашында гына оештырыла торган конференция, түгәрәк өстәл рәвешендә түгел, ә рәсми булмаган бәйрәм рәвешендә ай дәвамында диярлек узган һәм әлеге тантанада төрле катлам кешеләре катнашып, үзләренә рухи азык алган. Әйтергә кирәк, бу вакыйга — Мәрҗани шәхесе һәм аның иҗатына булган тәүге массакүләм кызыксыну. Вакытлы матбугат мөхәррирләре, тәрәккыйпәрвәр имамнар бу чараны оештыруда әйдәп баручы ролен башкарган.

یا کاغنه باصلوب چغوب صاتلا باشلادی:

مرجانی

مجموعه‌سی. بو اثر بیوک عالملرمزدن شهاب الدین المرجانی حضرتلرینڭ طوغانینه یوز یل طولو مناسبتیله نشر اولنوب، آنڭ ترجمهٔ حالی وخلقینه ایتکان علمی خدمتلری حقنده حاضرگی مشهور قلم اهللرینڭ اشتراکی بلان بیك کوب مقاله‌لر درج ایدلمشدر.

اثرده مرجانی حضرتلرینڭ شاقتای‌غنه مکتوبلری، اوچ قول یازماسی کرتلگان. مونڭ باشقه مرجانی حضرتلرینڭ طوغان یورطی، مسجد ومدرسه‌لرینڭ رسملری درج ایتلمشدر. اثر ٦٤٠ صحیفه‌ده، زور قولده، یاخشی کاغدده گوزل طبع اولنمشدر. کتابنڭ بهاسی ٣ صوم، پوچته ایله یبارلرگه ٢ صوم ٥٠ تین. نالوژ ایتوب صورانقانده آلدن ٧٥ تین زاداتکه یبارلسون. صاتار اوچون کوبلاب آلوچیلرغه عرفی اسکیدکه.

مراجعت اوچون آدریس: Казань, издательству „Гасръ“ № 2.

«Вакыт» газетасында «Мәрҗани» китабына реклама. 1915 ел

***

Мәрҗанинең 100 еллыгы уңаеннан, гыйнвар аенда Ризаэддин Фәхреддиннең «Рихләтел-Мәрҗани» исемле китабы дөнья күрә. Китап Ш.Мәрҗани хәзрәтләренең Төркия һәм Гарәбстанга сәяхәте вакытындагы хатирә дәфтәренә нигезләнеп язылган. Әсәрдә Мәрҗанинең фән һәм һөнәргә, Европа мәгарифенә булган мөнәсәбәте тәфсилле бәян ителә.

Апрель аенда дөнья күргән татар газета-журналларының барысында да диярлек Казандагы «Мәгариф» матбагасында сәүдәгәр Салих Гобәйдуллин наширлегендә «Мәрҗани» исемле китап басылып чыгуы һәм сатылуы турында реклама бар. «Вакыт» газетасындагы рекламада түбәндәгеләр языла: *«Мәрҗани» мәҗмугасы. Бу әсәр бөек галимнәремездән Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең туганына йөз ел тулу мөнәсәбәте илә нәшер*

«Мәрҗани» җыентыгын төзүчеләр редколлегиясе. Утырганнар (сулдан уңга): Кәшшафетдин Тәрҗемани, Салих Гобәйдуллин, Шәһәр Шәрәф, Габдерахман Гомәри. Басканнар: Габдулла Гыйсмәти, Газиз Гобәйдуллин, Таһир Ильяси. Казан. 1915

Салих Гобәйдуллин (1862-1935)

Газиз Гобәйдуллин (1887-1938)

улынып, аның тәрҗемәи хәле вә халкына иткән гыйльми хезмәтләре хакында хәзерге мәшһүр каләм әһелләренең иштираке (катнашы) белән бик күп мәкаләләр дәрҗ ителмештер. Әсәрдә Мәрҗани хәзрәтләренең шактый гына мәктүпләре, өч кульъязмасы кертелгән. Моннан башка Мәрҗани хәзрәтләренең торган йорты, мәсҗед вә мәдрәсәләренең рәсемнәре дәрҗ ителмештер. Әсәр 640 сәхифәдә, зур кулда, яхшы кәгазьдә гүзәл табгы улынмыштыр».

«Мәрҗани» китабын төзү турында дус-ишләр арасында гына туган фикерне 1913 елда Казан университеты студенты, тарихчы Газиз Гобәйдуллин этисе Салих әфәндегә җиткерә. Казан шәһәренең мәшһүр байларынан булган Салих Гобәйдуллин әлеге китапны нәшер итәчәгенә вәгъдә бирә һәм бер төркем зыялылар җыентыкны төзү белән шөгыльләнә башлый. Шәһәр Шәрәф, имам-хатыйп Кәшшафетдин Тәрҗемани, Габдулла Гыйсьмәти, Газиз Гобәйдуллиннардан торган редколлегия оеша. Аларга Мәрҗанинең Әстерханда яшүче шәкерте, «Идел» газетасының мөхәррире Габдрахман Гомәри дә зур ярдәм күрсәтә. Хезмәтне язар өчен Мәрҗанине якыннан белгән, аннан сабак алган башка авторларны да җәлеп итәләр. Татар галимнәре тарафыннан ике ел вакыт эчендә Мәрҗанинең бөтен дини, тарихи әсәрләре өйрәнелә, биографиясенә нисбәтле бай мәгълүмат җыела.

Татар вакытлы матбугатында әлеге китап басылып чыгу уңаеннан бәяләмәләр басылган. Шуларның берничәсенә генә тукталабыз. «Шура» журналындагы бәяләмәнең авторы Р.Фәхреддин: *«Мәрҗани хәзрәтләренең тәрҗемәи хәле язылган бу әсәр бер гыйлем чишмәседер»*, — дип яза. Галимнең ислам дөньясындагы бөеклеген дәлилләп: *«Русия мөселманнары арасында, башка мәмләкәтләрдә дә Шиһабетдин вә Зыяэтдиннәр, Шәмсетдин вә Таҗетдиннәр хисапсыз дәрәҗәдә күп икәнлеге мәгълүм. Ләкин ислам динен бидгатьләрдән сафларга, кәлям әһелләре уйдырмаларыннан аерырга, гомумән ислам динен сәләф гасырында булган рәвешенә кайтарырга тырышучы вә бу юлда җәфа вә мәшәкатьләр тартучы Шиһабетдиннәремез күп түгелдер»*, — ди. Дәвам итеп заман, шул чорның иҗтимагый шартлары аңа тулысынча ачылырга мөмкинлек бирмәгәнлегенә сыкрана: *«... безнең Шиһабетдинемезнең гомере дә гый-*

лем базарындагы дәрәҗәләре түбән адәмнәр берлә дәгъвалашып вә шуларны кире кагып үтте. Бик зур адымнар атларлык әзерлеген юк җирләргә сарыф кылырга мәҗбүр булды. Юкса Шиһабетдинемезгә тагын да файдалырак, гомумирәк хезмәтләр күрсәтергә мөмкин булыр иде, ләкин моның гаебе Мәрҗанидә түгел, бәлки заман һәм мәгыйшәть иткән урыннар вә гомумән мохит өстендәдер».

Фатих Әмирхан исә «Кояш» газетасындагы «Мәрҗани хатирәсенә мәҗмуга» исемле мәкаләсендә китапка тәнкыйди карап, андагы уңай һәм кимчелекле якларны барлаганнан соң: *«Матбугатыбызда мисле сәбакать итмәгән (беренчелектә тиңе булмаган) мондый мәҗмуганың тәртип вә нәшер ителүе әдәбиятыбызга бик кадерле байлык бирәдер. Мәҗмуганы дикъкать белән укып чыгу Мәрҗани хәзрәт тугрысында бөтен бер аң, бөтен бер тәхәйел (күзаллау) бирә аладыр»*, — дип яза.

1915 елда дөнья күргән әлеге китап хәзерге заман тарихчылары өчен дә Мәрҗанине, аеруча аның биографиясен өйрәнер өчен иң зур, ә бәлки бердәнбер тулы чыганак булып тора. 1998 елда «Рухият» нәшриятында әлеге китаптан Шәһәр Шәрәфнең күләмле әсәре, 2001 елда «Иман» нәшриятында «Мәрҗани» җыентыгының иске татар телендә ике кисәктән торган сүзгә-сүз күчерелмәсе, ә 2010 елда «Җыен» нәшрияты тарафыннан хезмәт тулысынча хәзерге татар әдәби теленә күчерелеп басылып чыкты.

***

Әйткәнебезчә, 1915 елның гыйнвар санында дөнья күргән татар газета-журналларының бер яки ике саны Ш.Мәрҗанигә багышланган. Сезнең игътибарыгызга «Кояш» газетасында басылган истәлекләрнең берсен тәкъдим итәбез. Ул мәгърифәтченең шәкерте яки хезмәттәше, дин эшлеклесе тарафыннан да түгел, ә гап-гади кыз кардәше — энесе Садретдин әл-Мәрҗанинең кызы Зәйнәп тарафыннан язылган. Шунысын да искәртик, «Матбагаи Кәримия»не оештыручыларның берсе, «китапчы» Мөхәммәтҗан Кәриминең хатыны Зәйнәп Кәримия белән «Кояш» газетасы мөхәррире һәм нашире Зәкәрия Садретдин — бертуганнар.

Шул чор зыялылары истәлекләреннән аермалары буларак, кыз кардәше тәкъдим иткән әлеге язма безгә Мәрҗани «кухня»сын, аның көнкүрешен, гаиләдәге кардәшләренә, туганнарына булган мөнәсәбәтен ача.

Замандашлары истәлекләренә карганда яхшы атлар җигәргә, затлы туннар кияргә, купшы киенергә яраткан, үз-үзен маһабәт һәм бай йөрткән Ш.Мәрҗанинең икмәк валчыгы, ашамлык калдыклары, йомычка һәм тукыма кисәкләренә булган сакчыл мөнәсәбәте гаять кызыклы һәм гыйбрәтле. Бу кыска гына мәкалә олуг галимнең шәхесе турында шактый сораулар тудыра. Мәраҗани вакчыл кеше булганмы? Әллә милекне исраф кылудан тыелып, гөнаһтан сакланганмы? Хатын булачак кыз кардәшләренә милек кадерен белү, пөхтәлек үрнәген күрсәткәнме? Әллә булган малга сакчыл, икътисадлы караш, һәр тиеннең кадерен белү аның өчен байлыкка, мал-мөлкәткә ирешүнең бер чарасы булганмы? Бәлки тормыш-көнкүреше уртача, тыйнак булып, гыйлем дәрәҗәсе гыйлемнең әһелендә күренә дип, купшы булып кына күренергә тырышканмы? Ни генә булмасын, язмадан аңлашылганча, Ш.Мәрҗани үзенең шәхси үрнәге һәм гамәлләре белән кыз кардәшләрен мал, милек кадерен белергә, булганын тигезләп бүлергә, үзең турында да уйларга, кардәшлек һәм туганлык җепләрен сакларга өнди.

Икенче мәкалә исә «Мәрҗани» җыентыгыннан алынды. Буа имамы Габдулла мелла Гобәйдулла углы язган әлеге мәкаләдә Мәрҗанинең Россия империясендә генә түгел, ә дөнья күләмендә мәшһүр шәхес икәнлеге янә бер мәртәбә дәлилләнә. ■

МӘРҖАНИНЕҢ ЙОРТ ТОРМЫШЫНДАГЫ КАЙБЕР ГАДӘТЛӘРЕ

Зәйнәп Кәримия

Вакыт-вакыт Мәрҗанинең йортында булганымнан, аның кайбер гамәлләрен бәян итеп китмәкче булам. Сүзгә керешкәнче шуны да әйтергә кирәк, күргән-ишеткән һәм белгән нәрсәләрнең кыйммәте вакытында тәкъдир ителми, аңа әһәмият бирелми, шул сәбәптән хәтердә калмый, калса да бик аз, ярым-йорты, бер шәүлә күк кенә кала. Минем дә аның белән аралашудан калган хатирәләрем бик аз булуы белән бергә, алар әһәмиятсез дә. Моңа карамастан, гыйлем һәм гыйлем әһеленең кадерен белә торган газиз милләтем тарафыннан, Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте илә ясалган юбилейга бөек агам Мәрҗани мәрхүм турындагы хатирәләремне язып тәкъдим итмәкче булам.

Без Мәрҗанинең ир һәм кыз туганнарының төрле авыллардан берничә кызлары идек. Үз вакыты белән Мәрҗани безнең аталарыбызга кунак булып килә иде. Бу вакыт һәркайсыбызның яшенә туры килгән күңелле һәм кызык сүзләр белән эндәшә, әхвәл сораша, безнең яшебезгә яраклы сүз һәм хикәяләр сөйләп көлдерә иде. Киткән вакытта, шулай ук, үзебезчә әйтеп, кунакка чакырып китә иде.

Йортында булганда Мәрҗани илә бер мәҗлестә була идек. Бу мәҗлесләрнең һәркайсында төрле мәзәк хәлләр сөйләп мәҗлесне хушландыра һәм безне көлдерә иде.

Әстерхан күк җимешләре күп җирләрдән укырга килгән шәкертләре көз көннәрендә Мәраҗанигә бик күптөрле җимешне күчтәнәч итеп китерәләр. Ул боларны гаиләсе эчендәге һәркемгә үзе бүлә һәм шуның эченнән үзенә дә өлеш аерып алып куя иде. Шулай ук шәһәр халкы һәм янына тирә-яктан үзенә мөнәсәбәтле адәмнәреннән килгән кияү бүләге һәм Мәкәрҗә бүләге күк фруктыларны да бүлә, үзенә дә өлеш чыгарып комодына бикләп куя иде. Мондый нәрсәләрдән үзенә өлеш чыгармауны бер дә күтәрми иде. Кызларын

Ш.Мәрҗанинең Казандагы йорты

Ш.Мәрҗани оныклары. Сулдан уңга: Рокыя, Фатыйма, Гайшә. Казан, 1906 ел

тапшыргач, туганы Садретдин хәзрәт хатынына да: «Әсма миңа кияү бүләге куйсын, үземә аерым куеп җибәрсен», — дигән. Үзе кардәшләренә барганда яки кардәшләренең балалары үзенә килгәндә бу бүләкләрне әлеге балаларга бирә иде.

Без йортында булганда, кичләрен ул үзенең китапханәсендә уку-язу илә шөгыльләнә, ә без йортның хатын-кызларга махсус бүлмәсендә җөй тегү, тирәк чыгару (чигү чигү) кебек эшләр белән мәшгуль була идек. Бервакыт, уку-язуыннан бүленеп, китапханәдән чыгып, кыштыр-кыштыр безнең бүлмәгә таба килгәне ишетелә башлый. Без аның килүенә җыенып җитәр-җитми, безнең бүлмәгә килеп керә иде. Кулында әлеге фруктылар була һәм аны безгә бүлеп биреп шатландыра. Шул мөнәсәбәт белән тагын берникадәр без аңлардый кыйсса һәм мәзәк хәлләр сөйләп көлдерә иде.

Аш мәҗлесе тәмам булганнан соң, калган икмәк һәм күмәч сыныкларын җыеп алып бер тастымалга төрә, мискәдәге калган шурпаның капкачын ябып, барын да үзе илә мәҗлестән алып китә һәм аларны китапханәсендәге китап шкафының бер җиренә җыеп куя иде. Кич, китап карап арыгач, әлеге шурпа һәм икмәкләрне куйган урыннан алып, суык көенчә үзенең уку-язу өстәленә җәя һәм үзеннән арткан булса, безнең бүлмәгә алып чыгып: «Мә, Галия, син тәмамла», — дип кызы Галия абыстайга бирә иде.

Калган икмәк, күмәч катылары күк кавын, карбыз, алма кабыгы, боларның орлыклары кебек нәрсәләрнең барын да җыеп куя. Көтү кайткач, боларны үз кулы илә сыерга биреп ашата, орлыклары илә тавык, чебеш һәм күркәләрне сыйлый иде.

Исрафтан, әйбернең әрәм булуыннан бик саклана, бу хосуста игътибары шулкадәр иде ки, урам һәм ишегалды күк урыннарда тапталып җиргә сеңеп беткән йомычка күк нәрсәләрне дә пәкесенең очы илә казып алып, ашханәнең тәрәзәсеннән: «Казан астына ягарсыз, әрәм итмәгез!» — дип эчтәгеләргә китереп бирә иде.

Йортында булганда күзенә күренгән ситсы кисәкләренең бик вагына кадәр җыеп, үзенең китапханәсендәге шкафына бикләп куя. Ташкичүгә туганы мулла Садретдин хәзрәткә кайткандабарганда бу кыйпылчыкларның берсен дә калдырмый үзе белән алып барып: «Мә, абзыкай (туганы мулла Садретдин) моны Әсмага (аның хатыны) бир, авыл карчыкларына бирсен, изү ясап тагарлар», — дип бирә иде.

Бервакыт бер савыт балга тычкан

төшеп, шунда үлгән. Моның өчен йорттагыларның бары да аптыраштa калды: ташласаң, әрәм, файдалансаң, җирәнгеч. Бөек агам мәсьәләне бик ансат бетерде: «Әй ахмаклар, аның нәрсәсе җирәнгеч? Сез файдаланмасагыз, мин үзем кулланырмын. Аның пычрак урыны фәкать тычкан төшкән урын гына бит», — диде. Һәм тычкан төшкән урынны пәке илә тирә-ягыннан җунып алды да, анысын түбә тимере астына куйды: «Бераздан бал кортлары алып бетерерләр, бер дә әрәм булмас», — диде. Һәм, ул дигәнчә, бераздан кортлар сарылды, алып та бетерделәр.

Безгә, аның туган кардәшләренең кыз балаларына, тәкъдирнең кушуы буенча Казанда төпләнергә туры килде. Без һәркайсыбыз төрле йортларга урнашып, үз алдыбызга гомер итә башлагач та, Мәрҗани мәрхүм вакыты белән хәлебезне үзе килеп белә, вакыты булмаганда кеше җибәреп белештерә иде. Вакыт-вакыт Казанда булган бөтен кыз карендәшләрен йортына җыя һәм мәҗлестә үзе рәислек итеп, төрле мәзәкләр, вакыйгалар сөйләп безне хушландыра. Атларын җиктереп: «Урамнарны әйләнеп, тамаша итеп кайтыгыз!» — дип йөрергә чыга иде. Вакыты белән һич уйламаганда: «Кунарга килдем, урын бирәсезме?» — дип, Казандагы кыз кардәшләренә килеп кунгалый иде. Кызларның бере — бер, икенчесе икенче ашны яхшы пешерә һәм дә Мәрҗани: «Фәлән ашны бик теләдем дә, сиңа килдем», — дип тә килгәләп куя иде.

Үзе кардәшлек хакын камил кайгырта, моның өстенлекләрен сүз уңае туры килгәндә безгә аңлата тора һәм үз арабызда кардәшлекне бик олыларга куша иде.

Аллаһының рәхмәтендә булсын!

Текстны басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

ОЛУГ ГАЛИМЕБЕЗ ШӘЕХ ӘЛ-МӘРҖАНИ ХӘЗРӘТЛӘРЕ ХАКЫНДА ХАТИРӘЛӘРЕМ

Габдулла бине Гобәйдулла


كتاب
ناظورة الحق في فرضية
العشاء وان لم يغب
الشفق
تاريخ هجريه نك
بك ايكيوز سكسن بشنجى سنه سينك يوم دوشنبه ده جماد الاولى نك
اون سكزنده قزان سوداكرى شاه احمد بن حسام الدين
بن صالحك خراجتيله بلدهٔ قزانده مطبع
خزانه ده اول كره طبع اولندى
نفعنا الله به وجميع اخواننا
المسلمين علما وعملا
وجعله ذخرا للدار
الآخرة
آمين
الناظورة
آلة رصدية ترصد بها
الاجرام الفلكية وتطالع بوساطتها
الامور الخفية التي لا تبدو في ساذج النظر
لكونها على غاية من البعد او الصغر
(منه سلمه الله
تعالى)

Мәрҗанинең «Нәзурәтел-хак» китабы. Казан, 1870 ел

Мәрҗани хәзрәтләренең мәдрәсәсе безнең яшь вакытыбызда шәкертләрнең күплеге, уку тәртипләренең яхшылыгы җәһәтеннән беренче урынны тотканнардан иде. Әткәбез хәзрәтләре дә укыган бу мәдрәсәгә барып уку яшь вакытымда минем өчен зур бер хөрмәт кебек тоела иде. Ниһаять, Мәрҗанинең вафатыннан ике ел алда, (1887 елда) мәдрәсәгә килдем.

Бу вакытта остаз Мәрҗани хәзрәтләре үзе картайганлыктан, мәдрәсәнең идарә эшләре вә дәресләре

хәлфәләр карамагында иде. Үзе исә, махсус сәгатьләрендә дәресханәгә кереп, армый-талмый, бик кызыгу белән дәрес укыта иде. Без, яшь шәкертләр, дәресханә ишеге янына барып, аның сөйләгән сүзләрен тыңлый идек. Ул мантыйк дәресләреннән соң әдәби сүзләр, хикмәтле хикәяләр, фарсы вә гарәби шигырьләр укыр, кайчакта латыйфәләр [кыска кызыклы хикәяләр] сөйләр, кайвакыт аять вә хәдисләр укыр, төрле тикшеренүләр сөйләр, тәфсилле мәгълүмат бирер иде.

Бервакыт бу сүзләрне сөйләгән иде: *«Үз милләтебезнең яшәргә тырышуы, үз эшен үзе эшли алуы, тормыш мәйданында изелеп калмавы өчен Аурупаның гыйлем вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнәгатенә зур ихтыяҗыбыз бар. Аурупаның мәктәпләрендә уку безнең өчен файдалы, һөнәр вә мәгърифәт кайда булса, шунда барып белем алырга кирәк. Гыйлем белән мәгарифнең хас ватаннары, хас телләре юк. Пәйгамбәребездән (с.г.в.) «Хикмәт — мөэминнең югалган нәрсәсе, аны кайда тапса, шуннан алыр», хәдисе риваять ителгән».*

Бу вакыттан соң Мәрҗани хәзрәтләренең төрле әсәрләрен күреп, файда алдык. Безнең аңлавыбызга күрә, Мәрҗани хәзрәтләренең әсәрләрен укучылар бу фикергә киләләр: ул гадәттән тыш аңлы булып, һәрнәрсәгә тәнкыйть күзе белән карый алган. Хөрмәтле шәригатьне Китап вә Сөннәт өйрәткән рәвештә аңлап, дине исламны гаять тә олуг күрүчән булган. Халык арасына Сөннәте-шәрифә урынына таралган мәгънәсез бидгать, төрле хорафатларны аерым-аерым бәян кылган. Бөтен Ислам галәменең моңа йөз тотуын аңлап, бетү сәбәпләрен эзләгән. Үз кавемебезнең бер милләт булып яшәве, юкка чыгудан котылуы өчен беренче дәрәҗәдә тиешле нәрсә милләт тарихы икәнен аңлап, бу эшне тормышка ашырган, милли тарихыбызга нигез куйган.

Үз вакытында Мәрҗани хәзрәтләренең бу олуг хезмәтләрен билгеләүчеләр юк хөкемендә аз иделәр. Байтаклары аны шигый, мөгътәзили дип, хәтта кайберәүләр динсез, кяфер дип йөриләр иде. Ләкин аның китаплары бастырылып, ерак җирләргә кадәр таралганлыгыннан, Ислам мәмләкәтләрендә аның хезмәтләрен билгеләүчеләр, үзен ихтирам итүчеләр байтак иде. Аның китапларын укучылар зур тикшерүче вә тугры фикерле бөек галим икәнлегенә канәгать итәләр иде.

Мисырның мәшһүр олуг галимнәреннән Мәхмүт Фәләки хәзрәтләре кулына «Нәзурәтел-хак» китабы ирешеп укыганда: *«Русия мәмләкәтендә җитешеп, бу кадәрле гыйлем вә фикер хасил итүе гаҗәп»*, — дип сөйләгән. Соңыннан хаҗ сәфәрендә Мәрҗани белән күрешеп, гыйлеме киң, гарәп теле күркәм, үз- үзен тотуы һәм хәрәкәтләре тыйнак һәм килбәтле икәнен күргәч, тагы гаҗәпләнүе вә мәхәббәте артып: *«Чынлап та, бу затның «Нәзурә» язучысы булырлыгы бар икән»*, — дип сөйләгән. Бу сүзләрне Коръән укытучы Камаледдин әш-Шәкәви хәзрәтләре риваять итә иде.

Үзебез дә Ислам дәүләтләренә сәяхәтебез вакытында Мәрҗанине билгеләүче байтак затларга очрадык. Истанбулда вакытыбызда Русиядән күчеп килгән мәшһүр мөдәррисләрдән — шәех Халис хәзрәтләре: *«Мәрҗани барча фәннәрне үзендә туплаучы булды, мәмләкәтебездән шундый галимнәрнең күренүе белән горурланам»*, — дип сөйләде.

Бәйрутның иҗтимагый галимнәреннән Габделкадир әфәнде хәзрәтләре, Мәрҗанинең күп әсәрләрен укыганын, аның зур галимнәрдән икәнен бәян иткәненнән соң: *«Мәрҗани хәзрәтләре татарларга бик күп хезмәт итте. Русия мөселманнарының бер милләт икәнен вә бер милләт булып яшәргә тиеш икәнлекләрен аңлатты. Аларның тәрәккыятләренә юл ачты. Күп һәлакәтләрдән коткарды»*, — дип сүзен тәмам итте.

Текстны басмага
***Гөлчәчәк Латыйпова** әзерләде.* ■

«УСАЛ ЭТ ТӨСЛЕ ТИК ЧӘЙНӘШ...»

Заһир Шәйхелисламов

Г.ТУКАЙНЫҢ МОҢА КАДӘР КҮПТОМЛЫКЛАРЫНА КЕРМӘГӘН ПУБЛИЦИСТИК ӘСӘРЛӘРЕ



«Уклар» сатирик журналы. Сентябрь, 1906 ел

Габдулла Тукай әсәрләренең академик тулы басмасын булдыру турында сүз күптәннән алып барылса да, моңа кадәр фәнни, шактый дәрҗәдә сайланып җыелган әсәрләренең күптомлыклары гына дөнья күрде. Мәдәни мирасны саклау «Мирас-Наследие» республика максатчан комплекслы программасы кысаларында татар халык шагыйре Г.Тукай әсәрләренең алты томлы академик басмасын әзерләү эше Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстологларына тапшырылды. Шигърияттән тәшкил итәчәк 1-2 нче томнарны төзүгә әзерлек эше 2009 елның октябреннән башланып китте һәм ул томнар 2011 елда басылып та чыкты. Академик басманы әзерләгәндә Тукайның кулъязмалары сакланмау сәбәпле (берничә хаты, берничә фрагментар язмаларын исәпләмәгәндә) һәм элекке күптомлыклар совет чорында хакимият басымы астында нәшер ителгәнгә күрә, безгә шагыйрь үзе язышкан, чыгаруда катнашкан барлык газета-журналларны, җыентыкларны, башка күптөрле чыганакларны яңабаштан өйрәнеп чыгарга туры килде. Нәтиҗәдә, элекке басмалардагы мәгълүм сәбәпләр аркасында кыскартылган, төшереп калдырылган урыннарны тутырып язарга, ялгыш укылган яки язылган, дөрес тәрҗемә ителмәгән, дөрес аңлатылмаган фактик хаталарны төзәтергә мөмкинлек туды. Искәрмә һәм аңлатмаларны язганда да мөмкин кадәр тулырак, яңача язарга, объектив булырга тырышылды. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Тукай – шагыйрь генә түгел, бәлки ялкынлы публицист, үткен, әче телле сатирик, проза өлкәсендә дә уңышлы эшләгән әдип икән. Томнарны әзерләү

барышында шагыйрьнең төрле матбугат битләрендә чәчелеп яткан, игътибардан читтә калган, яки билгеле булып та совет чоры идеологиясенә туры килеп бетмәгән, моңарчы басылмаган әсәрләре булуы ачыкланды. Әйтик, аның 1906 елда үзе исән чагында нәшер ителгән газета-журналларда гына да төрле псевдонимнар астында моңа кадәр басылмаган 76 әсәре табылды. Тик монда безне хаталану куркынычы сагалап тора. Чөнки ул чорда Тукай белән бер үк темаларга, бер стильдә диярлек язган, бер үк псевдонимнарны кулланган замандаш әдипләр дә бар. Шуңа күрә 76 әсәрнең 3 нче томга 19ы гына кертелде. Болар — Тукайның моңа кадәр әдәбият галимнәре арасында билгеле булган, шик уятмаган, фәнни кулланылышта йөргән «Чапансыз», «Шүрәле», «Мәхүб прахуды кантуршигы», «Җен», «Тәртә башы», «Мылтык», «Сөңге», «Сөемсез» имзалары белән язган әсәрләре. Шушы принципны саклаган хәлдә, шагыйрьнең, 1907-1913 еллар аралыгында язылып, хәзер табылган 80ләп мәкаләсенең 4 нче томга 20се урнаштырылды. Шундыйлардан тагы 5 нче томга ике, 6 нчы томга өч материал кертелде. **Укучылар игътибарына Тукайның моңа кадәр күптомлыкларына кертелмәгән берничә публицистик әсәрен тәкъдим итәбез.**

……………………………………

Габдулла Тукай

ҖИҢЕЛ КӘСЕП ХАКЫНДА НАДАН МУЛЛАЛАР КИҢӘШЕ[1]

– Бу халык өстенә генә карап тору бик кыен шул. Бер дә сәдакалар төшми башлады.

— Ийү елдан-елга эш начарлана бара. Бер җиңел кәсеп хакында чара эзләргә кирәк иде.

— Җиңел бер чара барын бар, тик иң әүвәл ишанлык гуаһнамәсе[2] алырга кирәк буладыр.

— Нинди чара? Нинди чара?

— Менә башка кияргә кирәк 100 аршын чалма, өстдә булырга кирәк киң вә озынлыкның чигенә йеткән сары чапан вә шуның өстенә ишан хәзрәт дигән исемең дә булса, менә кадрең бик артадыр, дәхи үзең шомаларга да остарак булып байларны мөрид итә алсаң, халыкның кулы өстендә генә йөрисең, ни кылсаң, шуны кәрамәт[3] дип торалар.

— Ул бит ишан булуның шарты күп тамыг[4] кергәч, ишан буламы соң? Ишан булгач, кешегә бу черек дөньядан бизеп вә үзенең дә ишан атагын белдермәенчә, аулак урынларда гына гыйбадәт итеп ятудыр?

— И-и-и, дурак! Төшенмисең икән минем бит ишанлык дийүдән максудым — кәсеп! Болай син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?!. Ул син әйткән шикелле ишан булсаң. Бу вакытта ачка гына үләргә…

— Без надан ич. Ишанлык гуаһнамәсен ничек ала алабыз?

— Зинһар, бер дә курыкма! Биш-ун тәңкә акчаң гына булсын тик.

КАЗАНДА ХАТЫНЛАР МӘСЛИХӘТЕ[5]

«Уклар» журналының 2 нче нумерында ирләр хәлендән, 3 нче нумерында шәкертләр хәлендән яздыгымызны күреп, хатын карендәшләремездән бәгъзе алучыларымыз шикаять кылып, хатынлар хәлен дә язмакыбызны үтенеп язалар. Без бу үтенечне кабул күреп, «Уклар»ның бу дүртенче нумерында хатынлар хәлендән дә язмакымызны мәгъкуль күреп, менә ошбу «Тәртә башы» исемле язучымызның Казандан язган хәбәрләрене баш мәкалә идеп басамыз.

---

[1] Әсәр «Уклар» журналының 1906 елгы 4 нче (сентябрь) санында «Мылтык» имзасы белән бирелә (Б.53).
[2] Гуаһнамәсе — таныклыгы.
[3] Кәрамәт — могҗиза.
[4] Тамыг — һаман кешедән өмет итү, ачкүзлелек.
[5] Әсәр «Уклар» журналының 1906 елгы 4 нче (сентябрь) санында «Тәртә башы» имзасы белән бирелә (Б.51).

«Казанда хатынлар мәслихәте»

Казанда ошбу арада хатынлар мәҗлесе булып шушы эшләр сөйләнгән:

1) Хатынларга үзләренә особый бер җәмгыять ясалып, ул җәмгыятьтә Бохарада укып кайткан хатынлар почётный член булсыннар.

2) Мәҗлеснең председателе Ахмакҗан бабайның кече хатыны Җабир мулла булсын.

3) Җәмгыятькә 25тән артык хатынлар членлыкка кабул ителмәсен.

4) Җәмгыятьнең иң әүвәл карый торган мәсьәләсе — кызларга укыту булмасын, чөнки кызлар укып образование хасил итсәләр, надан карт муллаларга хатынлыкга барудан баш тартырлар.

5) Хатынларга һичбер хокук бирелмәскә, чөнки хатынларга хокук бирелсә, ирләренең һәртөрле гакылга сыймаган нәрсәләрне кушуларына итагать[6] итмәзләр. Һәм кызларга ихтыяр хокук бирелсә, үзләре теләгән егетләргә бара башларлар.

6) Качуны бетерү булмасын. Чапан илә капланып йөрү ялган хәдисләр илә исбат иделсүн. Чөнки теләгән кешеләр илә бакчаларда танышып, мунчаларга барырга яки ресторанларга барып секретный кабинетларга һәм гайре йерләргә чапансыз булсак бара алмабыз. Барсак да кешеләрдән оялып андый урынларга бара алмабыз, шул сәбәпле Ахмакҗан абзыйга әйтеп һәм иманлы колларга, Җабир муллаларга әйтергә кирәк «Бәянел батыйль»га[7] яздырсыннар, зинһар өчен бетертә күрмәсеннәр. Чапан бетсә кызыклы эшләрдән, рәхәтләрдән мәхрүм калырмыз һәм бердән дахутымыз югалыр.

МАКАРИЯДАГЫ ҖЫЕЛЫШ[8]

Бу җыелышка уңлардан ничә вәкил, суңлардан ничә вәкил идеке мәгълүм дәгел исә дә, хатынлардан ничә вәкил идеке мәгълүм улынды. «Фәзаилешшөһүр»дән имтихан виргән Сәйдәш Ахмакҗани хатынлар тарафындан вәкил булып барган, диләр. «Таң» гәзитендә хатынлар «Бездән вәкил булмады», — дип язганлар иде. Бу сүз хатадыр, чөнки Ахмакҗан бабай аларның вәкиле иде. Хатынларны яклап «капчык илә капланып йөрсенләр», дип, Мәкәрҗәдә һаман пытырдап йөрде.

«Мөхәммәдия» көе[9]

Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш,
Усал эт төсле тик чәйнәш; —
Безем корган нигезләр
Бер дә селкенмәй дә чайкалмай.

САМАР[10]

Самар ахуны хотбә укыганда мәхәллә халкын: «Сез бурлаклар, талчукчылар вә хайваннар», — дип бик ачы сүзләр илә сүгәдер. Җомран кеби, ике хатыны янындан чыкмый, мәҗлесләрдә файдалы мәгълүмат сөйләми, тужурка, пальто кигән кешеләрне кяфер дип сүгә. Ишанга мөрид булырга чакыра. Үзе дә ишанлык дәгъвасын кылмакчы була, корсагын симертә, яшь хатыны берлә Чаковский мунчасында бик озак җата. Тугры әйткәч, фатыйха берлән куркыта, процент берлә карзга[11] акча бирә, иттифакка каршы килә, байларны бик ярата, фәкыйрьләрне мәкруһ[12] күрә, мәетне полиса[13] язуындан башка куй-

---

[6] Итагать — буйсыну, сүз тыңлау.
[7] «Бәянел батыйль»га — «Бәянелхак» газетасына.
[8] Әсәр «Уклар» журналының 1906 елгы 5 нче (октябрь) санында «Тәртә башы» имзасы белән бирелә (Б.51).
[9] Хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсендә каршы фикердә булган Ә.Сәйдәшевнең Мәкәрҗәдә «Бәянелхак» газетасын чыгару өчен байлардан ни рәвешле акча теләнеп йөрүе турында «Фикер»нең 1906 ел 18 август (31 нче) санында (4 нче бит) хәбәр бар.
[10] Әсәр «Уклар» журналының 1906 елгы 4 нче (сентябрь) санында «Тәртә башы» имзасы белән бирелә (Б.54-55).
[11] Карзга — бурычка.
[12] Мәкруһ — ямьсез, сөйкемсез.

мый, фәкыйрьләр җиназасына бармый. Фәкыйрь кеше, ишеге төбенә барса, звонок биреп бер сәгать көтеп тора, кыш көне булса, туңып бетә. Бер сәгатьтән чолганып чыга, «Ахык-ахык» дип какыра-какыра чыккач: «Син кем буласын?» — ди. Мәхәллә халкының берсенең дә исемен белми, «әйтәсе сүзеңне тизрәк әйт», дип каушата, абыстайның сумсасы суынуындан курка, ахрысы. Мәет булса, абдыратып бетерә: «Ничек вафат булды, син кайдагы, ниндәй кеше, мәкруһ[14] түгелме, политсәгә бардыңмы?» — фәләнме-төгәнме дип гакылларны шашдыра. Егет илә кыз риза булса, никях укымый, мәсҗедкә бер генерал-губернатор шикелле, халык җыелып беткәч керә, хосусән җомга көнендә халыкны таптап керә. Җомга көн «абыстайларга барамыз», дип татар хатын-кызлары өенә баралар. Шуларны тәрәзә фәрдәсе артындан карап җата.

ТАЯК САТУЧЫЛАРГА ИГЪЛАН[15]

Кустанай хәзрәтенә 10 данә таяк зарур, таяклар күңелгә охшаса, бәһасене сатулашмаячак, буе 2 аршын ярым, хасиятле артыш агачыннан эшләнгән, башы тимерле булсын. Таякларның берсе берлән хәзрәт «Уклар» берлән мөхарәбә итәчәк[16], икенчесе берлән мәҗлесдә бәгъзе надан солдатлар яңгылыш берәр мәсьәлә сораса: «Минем кеби олугъ хәзрәтдән мондый мәсьәләләр сорамагыз һәм болай булса, мине мәҗлескә чакырмагыз, үзеңез дә килмәңез!» — дип солдатларның башларын ватачак. Өченчесе берлән мәдрәсә балалары шаярса, башларын сугып ярачак, чөнки чыбыркы, чыбык кеби кораллар чыдамсыз буладыр. Дүртенчесе берлән раст вакыйганың 10 өлешдән бер өлешен генә язган өчен гәзитә мөхбирләрен тотып ватачак. Бишенчесе берлән мәсҗеддә Коръән укыган өчен Имами мулланы кыйнаячак. Алтынчысы берлән Имами мулланы мәҗлесләрдән куачак. Дүрт таяк запас торачак. Хәзрәт Бохараи шәрифдә, гыйлем тәхсил итеп[17], кәттә галим булгач, гаскәрлек хедмәтендә булып, офицерлык дәрәҗәсен алган, сугыш гыйлемендә бик маһир, ни булса да сакланырга кирәк. Гәзитә дә хәзрәтне онытмасыннар, дүрт таяк запас икәнен онытмасыннар. Таякларны налужный платюж илә тизрәк йебәрсенләр.

Адрес: Тургайский убласть, гурыд Кустанай.

УЙЛАМАГАН ҖИРДӘ ОРГАН[18]

«Таң йолдызы»нда бер Оренбург кешесе Фатыйх Кәримовдән зарланып: «Күтемә тибеп чыгарды», — дип яза да шуның артындан ук «Әх Дунай, вай Дунай» дигән озын бер такмак да гыйлавә[19] итә. Буны укыгач, минем болай дип әйтәсем килде: «Син, Оренбурглы әфәнде, минемчә, Фатыйхны гаепләмәскә тиеш иде. Чөнки Фатыйх синең күтеңдә, андый типкәч тә, «Әх Дунай, вай Дунай» көен уйный торган органның пружинасы барлыгын белсә, ихтимал, типмәгән дә булыр иде.

Текстларны һәм искәрмәләрне басмага ***Заһир Шәйхелисламов*** *әзерләде.* ■

[13] Полиса — полиция.
[14] Мәкруһ түгелме? — Дин тарафыннан читкә кагылган, ягъни динен алыштырган түгелме?
[15] Әсәр «Уклар» журналының 1906 елгы 4 нче (сентябрь) санында «Чурт» имзасы белән бирелә (Б.51).
[16] Мөхарәбә итәчәк — сугышачак.
[17] Гыйлем тәхсил итеп — белем алып.
[18] Әсәр «Уклар» журналының 1906 елгы 2 нче (июль) санында «Шүрәле» имзасы белән бирелә (Б.22). Орган — музыка уен коралы күздә тотыла.
[19] Гыйлавә итә — өстәп куя.

ТӨРКИ ДӨНЬЯ ҺӘМ ДӨНЬЯГА КАРАШ

Рафаэль Мөхәмәтдинов,
Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясының Координацион советы әгъзасы, тарих фәннәре кандидаты

Соңгы елларда Россиянең сәяси һәм рухи тормышында «рус дөньясы» дигән төшенчәнең киң таралуы күзәтелә. Минемчә, рус халкының, рус теленең һәм мәдәниятенең ролен, әһәмиятен күтәрү юлы белән дәүләтне ныгыту һәм идарәдә унитарлык тенденцияләрен көчәйтү күренеше бара. «Рус дөньясы» төшенчәсе идеология төсмерен ала.

Идеологларның күпчелеге «рус дөньясы»на Россия русларыннан тыш барлык рус булмаган җирле халыкларны, Украина, Белоруссия, Төньяк Казакъстанда яшәүче русларны һәм рус телен туган, рус мәдәниятен якын итеп күргән БДБдагы төрле милләт кешеләрен кертәләр.

Ауразия киңлекләрендә «төрки дөнья» барлыгын да онытырга ярамый. Төрки дөнья рус дөньясына караганда күпкә борынгырак. Эчке икътисади-мәдәни бәйләнышлар төрки дөньяны даими ныгытып һәм укмаштырып тора. Һичшиксез, Россиядәге төрки халыклар үз телләре һәм мәдәниятләре җәһәтеннән рус дөньясына түгел, ә төрки дөньяга карый.

Соңгы 20 ел эчендә Төркия һәм Азәрбайҗанда күп кенә төрки дәүләтләр һәм халыклар дуслыгы корылтайлары үткәрелде. Төрки халыкларның мәдәниятен үстерүче ТЮРКСОЙ дәүләтара оешмасы да гаять актив эшли. Төрки дәүләтләрнең парламентара ассамблеясы даими рәвештә Бакуда җыелып тора. Аның хәтта үз байрагы да бар. 1991 елдан халыкара иҗтимагый оешма — Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясы (БТХА) эшли. Бу оешманың үткән берничә ел эчендә өч программасы кабул ителде. Узган елның май аенда исә Казакъстанда VI нчы корылтае узды.

Төрки дөньяда күптән инде «Евровидение» рәвешендәге «Тюрковизйон» дигән җыр бәйгесе үткәрелә. Соңгы бәйге исә узган елның ноябрь аенда Казанда узды. Сентябрь аенда башкалабызда Төрки яшьләр фестивале узуын да, еш кына төрки-мөселман театрлары фестивале үткәрелүен дә онытмыйк.

Төрки дөньяны берләштерә торган әлеге мәдәни багланышлар нигезендә киләчәктә идеология дә барлыкка килергә мөмкин. Аның тууы өчен төркиләрдә тагын да киңрәк һәм тирәнрәк нигез — «дөньяга уртак караш» булырга тиеш. Алга таба сүз нәкъ менә шушы уртак нигез, төрки халыкларның дөньяга карашы турында барачак.

Дөньяга караш шактый колачлы төшенчә. Безнеңчә, бу төшенчә чынбарлыкны гомуми рәвештә аңлаткан карашлар системасын, чынбарлыктагы кешенең урынын, кешенең чынбарлыкка һәм җәмгыятькә булган мөнәсәбәтен, аның инануларын, идеалларын, рухи байлыгын үз эченә ала.

Дөньяга караш идеологиягә дә нигез була ала. Җәмгыятьтә дөньяга караш бар икән, ул, аерым шәхесләрнең генә түгел, ә билгеле бер социаль төркемнең, халыкның яки милләтнең өлгергән булуын күрсәтә. Төрки халыкларны берләштерүче караш саф дини тәгълимат була алмый, чөнки төрки дөньяда тәңречелек, ислам, христиан, будда, яһүдилек һәм мәҗүсилек кебек төрле диннәр булган һәм бар. Моннан тыш халыкның күп өлеше дөньяви тормыш мохитендә яши. Бер генә төрки дәүләттә дә билгеле бер дин дәүләт дине итеп игълан ителмәгән. Безне, төркиләрне, берләштерүче дөньяга карашлар системасы дөнья диннәре туганчы ук барлыкка килгән һәм алар тамырлары белән табигатькә, кешенең дөнья турындагы борынгы чын төрки күзаллауларына барып тоташа.

Әлбәттә, бу борынгы күзаллауларда да бөек Кодрәтнең, ягъни Илаһның үз урыны булган. Аның турындагы мәгълүматны төрки халыклар Ибраһим, Гайсә, Мөхәммәт кебек пәйгамбәрләрдән түгел, ә табигатьне Илаһ белән бербөтенлектә күзәтү нәтиҗәсендә алган.

Мондый дөньяга караш асылы белән дингә түгел, ә ***табигать фәлсәфәсенә (натурфилософиягә)*** якын. Югарыда әйтелгәннәрне күздә тотсак, төркиләрнең дөньяга карашы ***дөньяви*** һәм ***милли*** характерда булуы ачыклана. Бер яктан, ул безнең борынгы тамырларыбызга, ә икенче яктан, бүгенге фән һәм фәлсәфә нигезенә таянырга тиеш.

I. ТӨРКИЛӘРНЕҢ БОРЫНГЫЛЫГЫ

Төркиләр үзаңында: *«Без дөньяда иң борынгы халыклардан булабыз!»* — дигән горур фикер бар. Безгә калса, моны дөньяга карашның чишмә башы, дип әйтергә мөмкин. Борынгылыкны төрки сүзләрнең ***шумер*** (Азия), ***этруск*** (Аурупа), ***индеец*** (Америка) һәм ***һинд-аурупа*** телләрендә дә булуы исбатлый. Дөньяның төрле телләренә борынгы төрки телдән сүзләр генә түгел, хәтта кайбер грамматик шәкелләр дә үтеп кергән.

II. ТӨРКИ КОСМОГОНИЯ. МАТДӘНЕҢ ҺӘМ ДӨНЬЯНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Төрки мифология дөньяның барлыкка килүен түбәндәгечә аңлата. Иң әүвәлге матдә ***су*** белән ***һава***ның катнашмасыннан торган. Аннары бу хаостан ***су (җир)*** һәм ***күк (һава, кояш)*** формалашкан. Шулай итеп дөнья барлыкка килгән.

Әлеге караш яңа яратылган дөньяның йомырка рәвешендә булганлыгын тасвирлаучы мифологиягә дә туры килә. Ихтимал, йомырканың сарысы ***кояш*** һәм ***күк***не, ә йомырканың агы исә ***океан суларын*** чагылдырган. Бу беренчел матдәгә (***«күк-һава»*** белән ***су катнашмасына***) төркиләр ***«җир-су»*** яисә ***«тиңгез/тиңгер» (диңгез)***, ә шумерлар исә ***«абсу»*** дигәннәр.

Димәк, бабаларыбыз дөньяны гомоген (бертөрле) матдәдән, ягъни судан торган универсаль элементтан барлыкка килгән, дип уйлаганнар. ***Су*** исә, аларның фикеренчә, үз-үзеннән барлыкка килгән. Хаосның ***су*** һәм ***һава***дан

формалашкан булуы безне аптыраштa калдырырга тиеш түгел. Эш шунда ки, төрки халыклар ***һава***ны шул ук ***су***ның ***пары*** итеп күз алдына китергән. Моны ***«суларга»*** дигән татар фигыле дә күрсәтә.

Дөньяның гомоген бер матдәдән (судан) формалашуы турындагы төрки карашны астрофизикадагы соңгы ачышлар да раслый. Галимнәрнең фикеренчә, бөтен галәм иң әүвәл бердәнбер атомнан гына торган. Соңыннан әлеге атомның шартлавы ***(«Бөек шартлау»)*** аркасында газлар, аннары йолдызлар һәм галактикалар хасил булган.

Шулай итеп, бабаларыбызның дөнья һәм матдәнең барлыкка килүенә караган фикерләре бик мантыйклы һәм бүгенге көндә дә заманча яңгырый. Шунысы кызык, беренче грек философларыннан Фалес бөтен әйбернең нигезендә, аларны тәшкил иткән беренчел матдә су булган, дип уйлаган. Белгәнебезчә, Фалес Мисырга барып, анда шумер галимнәреннән күп нәрсәләрне өйрәнгән, шактый мәгълүматны үзләштергән. Шумерлар исә борынгы төрки бабаларыбыз катнашында барлыкка килгән яки аларның көчле мәдәни тәэсире нәтиҗәсендә формалашкан бер кавем.

Әлеге багланышлар нәтиҗәсе тел һәм фәлсәфә чыганакларында да күзәтелә. Мәсьәлән, төрки ***«суг/сув»*** (су) сүзенең ***«бат» («батмак»)***, ***«пар»*** һәм ***«боз»*** кебек мәгънәдәш сүзләре бар. Аларның кайсы борынгырак икәнен белеп булмый. Татар әкиятләрендә ***зур су*** киңлекләренә ***«ат»*** дип әйтелә. Бу исә ***«батмак»*** фигыле белән бәйле булуы мөмкин.

«Ат» сүзенең этимологиясе исә ***«су»*** төшенчәсе итеп кулланылган ***«ат, атл, атыл»*** прототөрки һәм индеец сүзләренең тамырларына барып тоташа. Мәсьәлән, кечуа телендә ***«атл»*** су мәгънәсен белдерә. Ацтек телләренең берсе булган нахуатль телендә ***«атл» (су, океан)*** кәлимәсе бар. Татарстан җирендә ***Атмас, Аты*** елгалары, ***Атмаклы*** һәм ***Атлас*** күлләре бар. Идел елгасының иң борынгы исеме дә ***«Атыл»*** иде. Татар телендә ***«Атыл/Идел»*** сүзе «зур елга» мәгънәсенә ия. Шуңа күрә, мәшһүр ***«Атилла»*** исемен ***«Атыллы/Иделле»*** сүзе белән бәйләргә мөмкин.

Ләкин иң кызык гидроним, ***«ат»*** тамырын үз эченә алган ***«күл-ат»*** дигән парлы сүз. Бу сүзне без «Зур кешеләр» дигән бик борынгы татар риваятендә күрә алабыз. Анда: *«Элекке заманда кешеләр... бик зур гәүдәле, көчле-куәтле булганнар.* ***Күл-атларны*** *кечкенә чокыр-чакырларны атлап чыккан кебек кенә атлап узганнар»*, — дигән сүзләр бар [1].

Мондый парлы төрки сүзләрдәге ике тамырның мәгънәләре, гадәттә, бер-берсенә бик якын була, шуңа күрә ***«күл-ат»*** парлы кәлимәсенең икенче өлеше ***«зур су»*** яисә ***«зур елга»*** мәгънәсен белдерә торган бер гидроним булырга мөмкин. Монда без, төрки телендәге ***«атыл»*** вә индеец телендәге ***«атл»*** тамырлары ***«зур су»*** яисә ***«океан»*** төшенчәләрен чагылдырганын күрәбез. Шулай итеп ***«Атыл» (Идел)*** һәм ***«Атлантика»***, ***«Атлантида»*** кәлимәләре дә мәйданга килгәндер.

Шул ук чыганактан ***«бар» (барлык)*** һәм ***«ма» (юклык)*** морфемалары да килеп чыккан. Мәсьәлән, ***«бастырмак» — «бастырма»***, ***«язмак» — «язма»***. Төрки телләрдәге бу ***«ма/ме»*** кисәкчәсе рус теленең «письмо» (хат), резьба» (кисү, кисеп ясалган рәсем) кебек сүзләренә дә күчкән. Төрки ***«ма»*** кисәкчәсе исә шумерларның Тәңре тарафыннан бирелгән һәм ***«төшенчә»*** мәгънәсен чагылдырган фәлсәфи һәм дини ***«ме»*** сүзе белән бәйле булырга бик мөмкин. Мәсәлән, ***«патша хакимияте» МЕ***се, ягъни ***«патша хакимияте»*** төшенчәсен белдергән сүз, ***«таҗ»*** *МЕ*се, ***«гыйбәдәтханә»*** *МЕ*се һәм башка *МЕ*ләр телдә кулланышта булган. Тулысынча шумер телендә 108 *«МЕ»* барлыгы ачыкланган [2].

Борынгы Мисырда «илаһи хакыйкать» яисә «галәмнең төзелеше» төшенчәләрен чагылдырган ***«Ма (ат)»*** сүзе (***«ат»*** — ул кеше җенесенең грамматик билгесе генә) «фиргавен хакимияте» илаһи доктринасының нигез ташы булып санала. Фиргавен исә илне хаостан саклап торучы бер сакчы булып саналган [3]. Төрки телләрдәге ***«ма»*** сүзенең бик күп мәгънәләре бар: ***«(б)ат» (су), «мә!» («ал!»)***, «Бер ***намә, язма, язмады*** (***«ма»*** — инкяр итү кушымчасы) / ***яздымы?»*** (***«мы»*** — сорау кисәкчәсе).

Сунын «булулык» (бытие) нигезе булуын күрсәтүче ***«ма/ва»*** сүзенең функцияләрен без һинд-аурупа телләрендә дә күрә алабыз. Мәсьәлән, немецчәдә: ***Wasser (су)***, ***etwas*** (бернәрсә), ***was*** (нәрсә). Шундый ук хәлне без семит телләрендә дә күзәтә алабыз. Мәсьәлән, гарәпчәдә: ***ма (су)***, ***ма (бернәрсә)***, ***ма (фигыльләрдә тискәрелек кушымчасы: гарәп. «ма катаба» = тат. «язмады»)***.

III. ТӨРКИ ДИАЛЕКТИКА

Югарыда күрсәткәнебезчә, төрки халыкларның ***«күк, һава, кояш, Тәңре»*** төшенчәләре ***«су»***га бик тыгыз бәйле. ***«Бал»***, ***«бай»*** дигән кояш исемнәре дә шул ук чыганактан килеп чыккан. Моны ***«(кояш) балыкты, баеды, батты»*** фигыльләре дә күрсәтә. Күргәнебезчә, монда ***«ба (ма)»*** тамыры берьюлы кояшның бар булуын да, юклыгын да белдерә. Төрки телләрдә ***«су (тук, суг, сув)»*** төшенчәсенә бәйле булган ***«тук»*** сүзеннән ***«йок» (төрекчә «юк»)*** һәм ***«чок» (төрекчә «күп, мул»)*** кебек бер-берсенә капма-каршы булган төшенчәләр барлыкка килгән. Бу мисал, безнең бабаларыбыз — борынгы төркиләрнең һәр әйбер яки вакыйгага үз эчендә каршылыклылыгын, һәр әйбердә бер-берсенә каршы килгән ике тенденция бар икәнен аңлауларын күрсәтә. Мәсәлән, кояш чама белән җылытса, игеннәр мул булачак (***«ма»*** — бернәрсәнең бар булуы, ***«чок»*** — бернәрсәнең күплеге, мул булуы). Әгәр кояшлы көннәр бик аз булса яисә кояш чамасыз нык кыздырса, игеннәр юкка чыгачак (***«ма»*** — тискәрелек, инкяр, ***«йок»*** — бернәрсәнең булмавы). Бабаларыбыз, күп күренешләрнең эчендә шушы ике тарафның бер-берсе белән көрәшүен һәм шул көрәшнең һәр әйбер-күренешнең бар булуына, үсешенә төп нигез булып торганын аңлаган.

Мисал өчен, ***«хакимият»*** төшенчәсен алыйк. Аның эчендә ике башлангыч ята: бөтенләй юкка чыгардай көчсез хакимият һәм золымга тиң чамасыз «көчле» хакимият. Нормаль хакимият фәкать бу ике башлангычның үзара йогынты ясашуы нәтиҗәсендә генә яши ала. Татар мәкалендә: ***«Юаш булсаң, басарлар, усал булсаң, асарлар, ә уртада булсаң, ил башы итәрләр»***, — дип әйтелә. Әлеге мәкаль бабаларыбыз яшәеш диалектикасын һәм һәрнәрсәнең эчке каршылыгы булуын яхшы аңлаган икәнен күрсәтә.

Бу яңа чорда Гегель диалектикасы буларак бөтен дөньяга мәгълүм була. Гегельнең фикеренчә: ***«Һәрнәрсәнең эчендә капма-каршылык ята; каршылык һәртөрле хәрәкәтнең һәм яшәешнең тамыры; һәрнәрсәнең эчендә каршылык булганга күрә генә, ул ниндидер хәрәкәт кичерә, импульска һәм эшчәнлеккә ия була»*** [4].

IV. БАРЛЫКНЫ ТАНЫП БЕЛҮДӘ «ДАГ/ТАУ» ИСЕМЛЕ КОЯШ ТАВЫНЫҢ РОЛЕ

Су хаосын ***күккә (кояшка)*** һәм ***суга (җиргә)*** аерылганнан соң, төркиләрдә ***тау*** яки ялгыз торган бер ***агач*** күкне җир белән бәйләүче элементка әйләнеп китә. Төркиләрдә тауларга аерым хөрмәт күрсәтелә. Аларга ***Хан-Тәңре, Казбек, Эльбрус*** кебек исемнәр бирелгән. Тауларга изге бернәрсәгә кебек караганнар. ***«Тау/даг»*** — изге сүз.

Иң әүвәле бу сүз аваз ияртеме була. Мөгаен, ул ***тукран***ның агачны чокыганда ***«тук-тук»*** авазына ияреп ясалгандыр. Соңыннан бу сүз кошның үзен дә ***(тукран)*** белдерә башлаган. Кайбер индеец телләрендә тукранны ***«тукан»*** дип атыйлар. Бабаларыбыз кояшка исем эзләгәндә, охшатып фикерләү (ассоциатив фикерләү) ярдәмендә, кояшның күктә һәм биеклектә очкан кошлар белән, ә безнең очракта ***«тук-тук»*** дип тавыш чыгарган тукран белән ниндидер бәйләнешен тапкан һәм кояшны ***«тук»*** дип атый башлаган.

Шулай ук ***«Тау/даг»***ның ***«так/тау»*** дигән кояш һәм йолдызлар символы — ***«үрдәк»*** сүзеннән дә барлыкка килүе ихтимал. Аның тамырын без һинд-аурупа телләрендә дә күрә алабыз. Мәсьәлән, инглизчә ***«duck» (үрдәк)***, русча ***«утка» (үрдәк)***. Төрки халыкларның мифологиясендә кояшны гәүдәләндергән алтын яки ак үрдәк образы булуы юкка түгелдер. Шулай итеп, кояшны гәүдәләндергән конус шәкелендәге (формасындагы) тауга да ***«так/даг/тау»*** исеме бирелгән иде.

Төрки халыкларның шул ук исемдә тәңресе дә булган. Шунысы кызык, этрускларның да ***Таг*** исемле бер тәңресе булган, ә антик греклар үз юлбашчыларына ***«таг»*** дигәннәр. Үзәк Америка индеецлары исә иң бөек юлбашчыларын ***«Кон тики»*** дип атаганнар. Тәрҗемәсе — ***«Кояш (Кон) улы (тики)»***.

Борынгы греклардагы ***«Теос» (илаһ)***, римлылардагы ***«Деус» (илаһ)*** һәм фарсылардагы ***«Дев/Див»***нең ***(илаһ)*** дә төрки ***«тау»*** кәлимәсе белән бәйле булуы ихтимал. Шунысы да игътибарга лаек: майя телендәге ***«Тео»*** сүзе дә ***«илаһ»*** төшенчәсен белдерә. Төрки халыклар түрәләрен тау башларына күмгән, шунда ук корбан чалган, бәйрәмнәр үткәргән һәм дини җырлар җырлаган. Шушы рухи мохит эчендә ***«таг/тау»*** тамырыннан ***«туй, тук, суярга, такмак, сукмак»*** сүзләре мәйданга килгән. (***Такмак*** — Тәңрегә җырланган мәдхия. ***Сукмак*** — бу сүз ***«Тук»*** тәңресен һәм күкне танып белү өчен бер юлны белдергән, ә бу юлның гәүдәләнеше тау булган).

Соңрак төркиләр далаларда, таулардан ерак булган үзәннәрдә яши башлагач, алар күмү һәм дини йолаларны үтәү өчен кечкенә ясалма таулар — курганнар төзи башлаган. ***Тау (курган)*** — Тәңре белән аралашу, күкне, галәм кануннарын, булулыкны (бытиены) өйрәнү чарасы.

Кытайлардагы ***«дао»*** дигән фәлсәфи төшенчәнең тамырлары да төрки ***«тау»*** төшенчәсенә барып тоташкандыр, мөгаен. Кытайча ***«дао» «юл»*** дип тәрҗемә ителә. ***«Дао»*** — булулык (яшәеш) барышының һәм үсешенең һичкемгә һәм бернәрсәгә дә буйсынмаган мөстәкыйль кануны. Ул канун теләсә нинди заман һәм аралык (пространство) эчендә гамәлдә була. ***«Дао»***ны танып белү табигать кануннарын аңлау һәм аңа ярашып яши белү дигән сүз.

Аннары бу фәлсәфәне японнар үзләштерә һәм аңа японча ***«синто»*** (тәңреләр юлы) дигән исем бирәләр. ***«Син»*** — японча «тәңре», ә ***«то»*** — ***«дао» (юл)*** дигән кытай сүзенең японча әйтелеше.

Дәвамы бар

Әдәбият:

1. Татар халык иҗаты: риваятьләр һәм легендалар / Томны төзүче һәм искәрмәләр язучы Сәлим Гыйләҗетдинов. — Казан. Татар. кит. нәшр., 1987.
2. Гудава Тенгиз. До и после Библии. Гл.II, Шумер/МЕ, www.netslova/sumer/gl 2. html-27.03.2014)
3. Рол Дэвид. Генезис цивилизации. — М.: Изд-ство ЭКСМО, 2003.
4. Гегель. Г. Соч. В 14 тт., Т.5. — М-Л., 1937. ■

ҖИҢҮ АЛЫП КИЛГӘН ТАТАР ГЕНЕРАЛЫ

Александр Филиппов

Армия генералы А.И.Антонов

1945 ел. 4-11 февраль. Кырым (Ялта) конференциясендә фронтлардагы хәл турындагы докладны Генераль штаб начальнигы урынбасары, армия генералы А.И.Антонов ясый. СССР, АКШ һәм Бөекбританиянең хәрби штаблары стратегик авиациянең үзара ярдәм итешүе турында килешә. Координация эшләрен башкаруны Кызыл Армиянең Генераль штабына йөклиләр. Антонов сөйләшүләр барышында искиткеч зур дипломатик әдәплелек күрсәтә. Сталин аның эшеннән канәгать кала.

Югары Башкомандующий әмере белән, А.И.Антонов 17 июль-2 августта узачак Берлин янындагы Потсдам конференциясендә катнашучылар исемлегенә дә кертелә.

1945 енең 17 февраленнән, Советлар Союзы Маршалы А.М.Василевский 3-нче Белоруссия фронты командующие булгач, Алексей Иннокентьевич рәсми төстә Генераль штаб начальнигы булып кала. Ул бу постта 1946 елның 25 мартына, Василевский кайткач, яңадан аның урынбасары вазифасында 1948 елның 6 ноябренә кадәр эшли. Шулай итеп, ул Генераль штабта алты елдан артык эшли. Маршал булырга исә аның татар нәселеннән булуы гына комачаулый.

Аннары А.И.Антоновка Кавказ арты хәрби округында хезмәт итәргә боералар. Башта бер ел ул Советлар Союзы Маршалы Ф.И.Толбухин командирлык иткән гаскәрләрдә аның беренче урынбасары, аннан соң дүрт ел буе — 1954 елга кадәр — үзе командующий була.

Сугыш тәмамлануга ун ел вакыт уза. Онытыла башлаган армия генералын Н.С.Хрущёв искә төшерә. А.И.Антонов — Варшава Договоры илләренең Берләшкән Кораллы Көчләре штабы начальнигы, шул ук вакытта Советлар Союзы Армиясенең Генераль штабы начальнигы урынбасары итеп тә билгеләнә. Бу урында ул үзенең соңгы сулышына — 1962 елның 18 июненә кадәр эшли.

Илебез алдындагы хезмәтләре «Җиңү» ордены, өч тапкыр Ленин ордены, дүрт тапкыр Кызыл Йолдыз ордены, ике тапкыр I дәрәҗә Суворов ордены, Кутузов һәм I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән үлчәнә. Шулай ук ул чит илләрнең орден һәм медальләренә дә лаек дип табылган. Ул СССР Верховный Советының II-VI чакырылыш депутаты да булып тора.

Армия генералы А.И.Антонов Мәскәүдә Кремль дивары буенда җирләнгән.

М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академия бинасында, Гродно шәһәрендә ул туган йортта мемориаль такталар куелган. Мәскәүдә, туган шәһәрендә аның исемендә урамнар бар. Санкт-Петербург Югары хәрби-топография училищесы һәм Гродногадагы 11 нче урта мәктәп аның исемен йөртә.

***

Армия генералы Алексей Иннокентьевич Антонов, Генераль штабның Оператив идарәсе начальнигы, соңрак Генераль штаб начальнигы буларак, каршы тору (оборона), һөҗүм итү, стратегик һөҗүм итү операцияләренең планын эшли һәм уңышлы рәвештә тормышка ашыруда катнаша. Ул операцияләрнең

Ахыры. Башы 3 нче санда.

һәркайсы совет солдатларының тулы җиңүенә китерә, немец-фашистларның җиңелүе белән тәмамлана.

Ростов каршы тору (оборона) операциясе (1941 елның 5-16 ноябре). Командиры генерал-полковник Я.Т.Черевичеко булган Көньяк фронт гаскәрләре операциясе. Ростов юнәлешендә немец-фашист гаскәрләре һөҗүмен кире кайтару максатыннан ясалган операция.

Кырым каршы тору операциясе (1941 елның 18 октябре-16 ноябре). Командиры генерал-полковник Ф.И.Кузнецов булган 51 нче һәм командиры генерал-майор И.Е.Петров булган Приморье гаскәрләренең Кара диңгез флотына (командиры вице-адмирал Г.И.Левченко) үзара ярдәм итү максатыннан оештырылган операция.

Кировоград һөҗүм итү операциясе (1944 елның 5-16 гыйнвары). Командиры армия генералы И.С.Конев булган 2 нче Украина фронты гаскәрләре операциясе. Немец-фашист гаскәрләренең Кировоград берләшмәсен тар-мар итү Көньяк Буг елгасына чыгу максатын алга куеп оештырылган була.

Корсунь-Шевченко һөҗүм итү операциясе (1944 елның 24 гыйнвары-17 феврале). Командиры армия генералы Н.Ф.Ватутин булган 1 нче Украина һәм командиры армия генералы И.С.Конев булган 2 нче Украина фронты гаскәрләре тарафыннан каршы якның Корсунь-Шевченко оешмасын тар-мар итү максатыннан оештырылган операция.

Ровно-Луцк һөҗүм итү операциясе (1944 елның 27 гыйнвары-11 феврале). Командиры армия генералы Н.Ф.Ватутин булган 1 нче Украина фронтының уң як канаты гаскәрләре операциясе. Максаты — немец-фашистларның 4 нче танк армиясенең уң флангысын тар-мар итеп, Луцк, Ровно, Шепетовка районнарын яулап алу һәм Төньяк флангтан яңа удар өчен уңайлы оборона сызыгы булдыру һәм «Көньяк» армиясенә юл ачу.

Никополь-Кривой Рог һөҗүм итү операциясе (1944 елның 30 гыйнвары-29 феврале). Командирлары армия генераллары Р.Я.Малиновский һәм Ф.И.Толбухин булган 3 нче һәм 4 нче Украина фронтлары өчен операция. Максаты — дошманнарның Никополь-Кривой Рог төркемен тар-мар итү, аның Днепрдагы Никополь плацдармын юк итү, Никополь һәм Кривой Рогны азат итү.

Рогачёв-Жлобин һөҗүм итү операциясе (1944 елның 21-26 феврале). Командиры армия генералы К.К.Рокоссовский булган 1 нче Белоруссия фронтының уң як канаты гаскәрләре операциясе. Максаты — дошманның Рогачёв, Жлобин районнарындагы төркемнәрен тар-мар итү һәм Бобруйск юнәлешендә һөҗүм итү өчен уңайлы шартлар тудыру.

Проскуров-Черновицк һөҗүм итү операциясе (1944 елның 4 марты-17 апреле). Командиры Советлар Союзы маршалы Г.К.Жуков булган 1 нче Украина фронты гаскәрләре операциясе. Максаты — дошманнарның төп көчләре булган «Көньяк» армиясенә каршы тора алырлык 2 нче Украина фронты гаскәрләре белән бердәм хәрәкәт итү өчен үткәрелә.

Уман-Ботошан һөҗүм итү операциясе (1944 елның 5 марты-17 апреле). Командиры Советлар Союзы маршалы И.С.Конев булган 2 нче Украина фронты гаскәрләре операциясе. Украинаның көньяк-көнбатыш өлкәләрен азат итү максаты белән үткәрелә.

Брезнеговат-Снегирёв һөҗүм итү операциясе (1944 елның 6-18 марты). Знче Украина фронты гаскәрләре өчен Украинаның көньяктагы Уңъяк Украина (атлы-механикалаштырылган төркем командиры генерал-лейтенант И.А.Плиев, армия генералы Р.Я.Малиновский) өчен операция; 1943-1944 елларда Уң як Украина совет гаскәрләренең стратегик һөҗүменең бер өлеше.

Одесса һөҗүм итү операциясе (1944 елның 26 марты-14 апреле). 3

А.И.Антонов (икенче рәттә уңнан – өченче) СССР, АКШ һәм Бөекбритания хөкүмәте башлыклары белән Ялта конференциясендә. 1945 ел

нче Украина фронты гаскәрләре (атлы-механикалаштырылган төркем командиры генерал-лейтенант И.А.Плиев, армия генералы Р.Я.Малиновский) Кара диңгез флоты (командиры вице-адмирал, 10 апрельдән адмирал Ф.С.Октябрьский) көчләре ярдәме белән операция, 1943-1944 елларда Уң як Украина совет гаскәрләренең стратегик һөҗүменең бер өлеше.

Кырым һөҗүм итү операциясе (1944 елның 8 апреле-12 мае). 4 нче Украина фронты гаскәрләре (армия генералы Ф.И.Толбухин) һәм Аерым Приморье армиясе (координаторлары Советлар Союзы маршаллары К.Е.Ворошилов һәм А.М.Василевский) операциясе. Максаты — Кара диңгез флоты (адмирал Ф.С.Октябрьский) һәм Азов хәрби флотилиясе (контр-адмирал С.Г.Горшков) ярдәмендә Кырымнан дошманны куу өчен үзара ярдәмләшүгә ирешү.

Белоруссия һөҗүм итү операциясе — яшерен исеме «Багратион» (1944 елның 23 июне-29 августы). Хәйләгә корылган иң зур стратегик һөҗүм итү операцияләренең берсе. Аның максаты — фашистларның «Үзәк» армиясен тар-мар итү һәм Белоруссияне азат итү. Дошманны тар-мар итү өчен 1 нче Балтыйк буе (армия генералы И.Х.Баграмян), 3 нче Белоруссия (армия генералы И.Д.Черняховский), 2 нче Белоруссия (армия генералы Г.Ф.Захаров), 1 нче Белоруссия (армия генералы, июнь азагыннан Советлар Союзы маршалы К.К.Рокоссовский) фронтлары, яңа оешкан 1 нче Польша гаскәрләре армиясе (генерал-лейтенант З.Берлинг) һәм Днепр хәрби флотилиясе (контр-адмирал В.В.Григорьев), еракка очу авиациясе (авиация маршалы А.Е.Голованов) җәлеп ителде. Фронтлар хәрәкәтен тормышка ашыру Ставка вәкилләре Советлар Союзы маршаллары Г.К.Жуков һәм А.М.Василевскийга йөкләнә. Генштаб һәм фронтлар планы буенча операциягә әзерлек чорында маскировка буенча

зур чаралар үткәрелә. Мәсәлән, 3 нче Украина фронты юнәлешендә һөҗүм итү өчен охшатып ясалган сугыш кирәк-яраклары пәйда була, ә шул ук вакытта Белоруссиядә дошманга каршы тора алырлык гаскәрләр туплана.

Львов-Сандомир стратегик һөҗүм итү операциясе (1944 елның 13 июле-29 августы). 1 нче Украина фронты (Советлар Союзы маршалы И.С.Конев) гаскәрләре өчен эшләнгән операция. Максаты — дошманның «Төньяк Украина» армиясе төркемнәрен тар-мар итү һәм Украинаның көнбатыш өлкәләрен, Польшаның көньяк-көнчыгыш районнарын азат итү.

Псков-Остров һөҗүм итү операциясе (1944 елның 17-31июле). 3 нче Балтыйк буе фронты (армия генералы И.И.Масленников) гаскәрләре өчен эшләнгән операция. Максаты — дошманның Псков-Остров төркемен тар-мар итү, Псков һәм Остров шәһәрләрен азат итү.

Нарва һөҗүм итү операциясе (1944 елның 24-30 июле). Ленинград фронты (Советлар Союзы маршалы Л.А.Говоров) гаскәрләренең Балтыйк флотына (адмирал В.Ф.Трибуц) ярдәме өчен эшләнгән операция. Максаты — дошманның Нарва төркемен юк итү һәм Нарва шәһәрен азат итү.

Яссы-Кишинёв стратегик һөҗүм итү операциясе (1944 елның 20-29 августы). 2 нче (армия генералы Р.Я.Малиновский) һәм 3 нче (армия генералы Ф.И.Толбухин) Украина фронтларының Кара диңгез флоты (адмирал Ф.С.Октябрьский) һәм Дунай хәрби флотилиясенә (контр-адмирал С.Г.Горшков) үзара ярдәмләшү операциясе. Максаты — дошманның «Көньяк Украина» армиясе төркемнәрен тар-мар итү, Молдавия ССРны азат итүне тәгәлләү һәм Румынияне фашист Германиясеннән йолып алу. Фронт хәрәкәтләрен Ставка вәкиле, Советлар Союзы маршалы С.К.Тимошенко билгели.

Көнчыгыш-Карпат стратегик һөҗүм итү операциясе (1944 елның 8-28 сентябре). 1 нче (Советлар Союзы маршалы И.С.Конев) һәм 4 нче (генерал-полковник, 26 октябрьдән армия генералы И.Е.Петров) Украина фронтлары өчен эшләнгән операция. Максаты — немец-фашистларның Көнчыгыш Карпат гаскәрләрен туздыру һәм Словакиянең милли хәрәкәтенә ярдәм итү.

Балтыйк буе стратегик һөҗүм итү операциясе (1944 елның 14 сентябре-24 ноябре). Ленинград (Советлар Союзы маршалы Л.А.Говоров), 3 нче (армия генералы И.И.Масленников), 2 нче (армия генералы А.И.Ерёменко) һәм 1 нче (армия генералы И.Х.Баграмян) Балтыйк буе, 3 нче Белоруссия (армия генералы И.Д.Черняховский) фронтлары гаскәрләре һәм Балтыйк флоты (адмирал В.Ф.Трибуц) көчләре өчен төзелгән операция. Максаты — Балтыйк буендагы немец-фашистларын тар-мар итү һәм Балтыйк буе республикаларын азат итү. Фронтлар хәрәкәтен координацияләү Советлар Союзы маршалы А.М.Василевскийга йөкләнә.

Белград һөҗүм итү операциясе (1944 елның 28 сентябре-20 октябре). 3 нче Украина фронты (Советлар Союзы маршалы Ф.И.Толбухин), Югославия Халык азатлыгы армиясе (маршал И.Броз Тито) һәм Болгария Ватан фронты (Т.Живков җитәкчелегендәге оператив бюро) гаскәрләре операциясе.

Дебрецен һөҗүм итү операциясе (1944 елның 6-28 октябре). 2 нче Украина фронты (Советлар Союзы маршалы Р.Я.Малиновский) гаскәрләре өчен Венгрия һәм Румыния территорияләрендә үткәрелгән операция.

Висла-Одер стратегик һөҗүм итү операциясе (1945 елның 12 гыйнвары-3 феврале). 1 нче Белоруссия (Советлар Союзы маршалы Г.К.Жуков) һәм 1нче Украина (Советлар Союзы маршалы И.С.Конев) фронтлары гаскәрләре ярдәмендә 2 нче Белоруссия фронтының сул як канаты гаскәрләре (Совелар Союзы маршалы К.К.Рокоссовский) һәм 4 нче Украина (армия генералы

Мавзолей трибунасында: В.Н.Меркулов, А.И.Антонов, Г.К.Жуков, Д.Эйзенхауэр, И.В.Сталин, У.А.Гарриман, М.И.Калинин һ.б. Август, 1945 ел. М.Калашников фотосы

И.Е.Петров) фронтының уң як канаты өчен әзерләнгән операция. Максаты — немец-фашистларының «А» (26 гыйнвардан «Үзәк») армиясе төркемнәрен тар-мар итү, Польшаны Гитлер оккупантларыннан азат итүне төгәлләү һәм Берлинга хәлиткеч удар өчен уңайлы шартлар тудыру.

Көнчыгыш-Пруссия стратегик һөҗүм итү операциясе (1945 елның 13 гыйнвары-25 апреле). 2 нче (Советлар Союзы маршалы К.К.Рокоссовский), 3 нче Белоруссия (армия генералы И.Д.Черняховский, 20 февральдән Советлар Союзы маршалы А.М.Василевский) һәм Балтыйк буе (армия генералы И.Х.Баграмян) фронтларының бер өлеше Балтыйк флоты (адмирал В.Ф.Трибуц) ярдәме белән үткәрелгән операция. Максаты — Көнчыгыш Пруссиядә һәм Польшаның төньяк өлешендә урнашкан дошман төркемнәрен тар-мар итү.

Көнчыгыш-Померания стратегик һөҗүм итү операциясе (1945 елның 10 феврале-4 апреле). 2 нче (Советлар Союзы маршалы К.К.Рокоссовский) һәм 1 нче Белоруссия (Советлар Союзы маршалы Г.К.Жуков) фронтларының Балтыйк (адмирал В.Ф.Трибуц) флоты көчләренә ярдәм итү өчен төзелгән операция. Нәтиҗәдә 1945 елның Висла-Одер операциясе вакытында Совет гаскәрләре Одер елгасына чыкты һәм елганың көнбатышында аларның ныгытмаларын алды. Шул ук вакытта дошманның «Висла» армиясе төркемнәре Көнчыгыш Померанияне тотып торалар һәм 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләренең уң як канатына удар ясарга әзерләнә. 8 февральдә Баш Командование Ставкасы килеп туган хәлне исәпкә алып, 2 нче Белоруссия фронтын Көнчыгыш Пруссия операциясеннән азат итте һәм мәсьәләне Көнчыгыш Померания төркемен тар-мар итәргә, Көнчыгыш Померанияне яулап алырга һәм Данцигтан (Гданьскидан) алып Померания бухтасына кадәр Балтыйк буе яр буйларын дошманнардан бушату бурычын куя.

Вена стратегик һөҗүм итү операциясе (1945 елның 16 марты-15 апреле). 3 нче (Советлар Союзы маршалы Ф.И.Толбухин) һәм 2 нче (Советлар Союзы маршалы Р.Я.Малиновский) Украина фронтлары өчен ясалган операция. Максаты — Венгриянең көнбатышында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итүне төгәлләү һәм Австрияне-Венаны азат итү.

Прага стратегик һөҗүм итү операциясе (1945 елның 6-11 мае). 1 нче (Советлар Союзы маршалы И.С.Конев), 4 нче (армия генералы А.И.Ерёменко) һәм 2 нче (Советлар Союзы маршалы Р.Я.Малиновский) Украина фронтлары гаскәрләре өчен төзелгән операция. Максаты — Чехословакия һәм аның башкаласы Праганы азат итүне төгәлләү.

Берлин соңгы стратегик операция

Беларусь Республикасының Гродно шәһәрендә Антонов исемендәге 11 нче мәктәп музее. Армия генералы А.И.Антонов бюсты

(1945 елның 16 апреле-8 мае). Совет гаскәрләренең Берлин юнәлешендәге немец-фашист гаскәрләре төркемен тар-мар итү, Берлинны яулап алу һәм Эльба елгасына чыгып союздаш гаскәрләр белән кушылу. 1945 елның язында фашист Германиясе территориясенә Советлар Союзы, АКШ, Англия һәм Франция кораллы көчләренең сугышчан хәрәкәтләре башлана. Бу вакытта Совет Армиясе Берлиннан 60 километр, ә Америка-Англия гаскәрләренең алгы сызыгы Эльбада — Германия башкаласыннан 100-120 км ераклыкта тора иде.

Берлин операциясен тормышка ашыру һәм нәтиҗәләре буенча өч этапка бүленә:

Беренче этап. Дошманның Одер-Нейсе оборона чикләрен өзү (16-19 апрель), 1 нче Белоруссия (Советлар Союзы маршалы Г.К.Жуков) һәм 1 нче Украина (Советлар Союзы маршалы И.С.Конев) фронтлары гаскәрләре 16 апрельдә һөҗүмгә күчә.

Икенче этап. Дошман гаскәрләрен чолгап алу һәм бүлгәләү (19-25 апрель). 1 нче Белоруссия фронты һөҗүм итүне дәвам итә, 20 апрельдә 3нче Удар армиянең 79 нчы укчы корпусының еракка ата торган артиллериясе Берлинга беренчеләрдән булып ут ача.

Өченче этап. Чолганышка алынган төркемнәрне тар-мар итү, Берлинны алу (26 апрель-8 май). Башка операцияләрдән үзгә буларак, Берлин операциясенә гомуми җитәкчелекне координацияләүне Югары Баш командование үз өстенә ала.

Армия генералы А.И.Антонов 1946 елның мартыннан — яңадан Генштаб начальнигының беренче урынбасары. 1948-1954 елларда — Кавказ арты хәрби округының гаскәрләре командирының беренче урынбасары, аннары командиры. 1954 елның апреленнән — Генштаб начальнигының беренче урынбасары, ә 1955 елның мартыннан — бер үк вакытта (беренче тапкыр) Берләшкән Кораллы Көчләр Оешмасының Варшава килешүе штабы начальнигы. ■

ФРОНТОВИК АРТИСТЛАР

Рәдиф Сәгъди

Язмамны 1963 елдан алып 1985 елга кадәр Күчмә театрда (хәзерге Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) баш режиссёр булып эшләгән фронтовик Равил ага Тумашев сүзләре белән башлап китсәм, дөрес булыр: «1941 елның 21 июне – Казанның 15 нче мәктәбен тәмамлаган көн иде, чыгарылыш кичәсе, төне буе сыйныфташлар белән «если завтра начнется война» диеп, борынгы шәһәр урамнарын яңгыратып җырлап йөрдек. Иртән Гитлер Германиясенең сугыш башлаганын игълан иттеләр»...

«Фельдмаршал Кутузов» спектакленнән бер күренеш. 1941 ел

Театрның байтак хезмәткәре үзләре теләп фронтка китә. Шулар арасында — драматурглар М.Әблиев, Г.Кутуй, Р.Ишморат, Ә.Фәйзи, С.Баттал, актёрлар һәм театр эшчеләре — М.Надрюков, Г.Газизов, Ф.Камал, Г.Йосыпов, Х.Кәтиев, Й.Сәгыйтов, К.Гыйльманов, Шакир Усманов, Б.Шакирова, С.Шәкүров, Б.Йосыпов һәм башкалар бар. Яшь артистлар Г.Газизов, Ә.Йосыпов, Х.Кәтиев, Ф.Камал яу кырыннан кайтмый. Тылда исә Ш.Шамильский, Н.Араповларның гомере өзелә.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан гына театр җәмәгатьчелеге Мәскәүдә үтәчәк милли сәнгать декадасына әзерләнеп йөри. Иҗат әһелләре коточкыч фаҗигадән тетрәнеп кала. Күпме көч, хезмәт куеп, сәхнәгә чыгарылган спектакльләр — Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ы, Нәкый Исәнбәтнең «Идегәй» һәм «Хуҗа Насретдин»ы үзәккә баралмыйча кала, олы иҗат бәйрәме өзелә.

Театрлар, Республика хөкүмәтенең 975 нче күрсәтмәсе буенча, 1941 елның 31 июленнән хезмәт хакы 50%ка калдырыла. Шуңа да карамастан, сәхнә халкы иманын алыштырмый, үзе сайлаган язмыштан ваз кичми, киресенчә, «Фронт өчен, җиңү өчен!» дип, җиң сызганып иҗат итә. Рәшидә Җиһаншина, Ибраһим Гафуров, Рәшидә Тәминдарова, Рокыя Ибраһимова, Ширияздан Сарымсаков, Сөләйман Вәлиев-Сульва, Кәшифә Тумашевалар концерт бригадалары белән алгы фронт сызыкларына барып җитә. Госпитальләрдә кизү тору, авыл хуҗалыгына булышу кебек «кул уңае» эшләр фронт файдасына планнан тыш концерт-спектакльләр кую белән бергә бара. 1941-1945 елларда гына да Академия театры коллективы 23 премьера күрсәтә! Классика җәүһәрләре — «Король Лир», «Яшенле яңгыр», «Печән өстендәге эт», «Хуҗа Насретдин» һәм сугыш темаларына багыш-

ланган «Мәрьям», «Миңлекамал» сыман спектакльләр халыкка рухи куәт бирүче иҗат казанышына әверелә.

Сугыш баруга карамастан, театрның кеше күңеленә турыдан-туры юл салучы сәнгать икәнлеген аңлап, 1944 елны Мәскәүнең А.В.Луначарский исемендәге театр сәнгате институтына (ГИТИС), анда яңа ачылган татар студиясенә укырга яшь шәкертләр җибәрелә (араларында Празат Исәнбәт, Рәфкать Бикчәнтәев, Гәүһәр Камалова, Шаһсәнәм Әсфәндиярова, Асия Хәйруллина, Рауза Әхмәровалар бар). Һәлакәтле чор тантана итсә дә, ил җитәкчелеге, беренче карашка гаҗәп тоелган, әмма асылда бик тә дөрес гамәлләр башкара. Мәсәлән, 1944 елда Әлмәттә күчмә колхоз-совхоз театры төзелә. Аның беренче директоры һәм режиссёры итеп Ә.Галиев билгеләнә, сугыш алдыннан гына татар театр техникумын тәмамлаган бу шәхес профессиональ артистлардан (Г.Хәбибов, С.Хәбибова, К.Еникеев, Т.Җаббарова, Х.Җәләлов, Х.Рамазанов) труппа җыеп, фронтовик язучы Риза Ишморатның «Кайту» драмасын сәхнәгә күтәрә. Аңа хәтле, 1942 елда ук, әлеге пьесаны Буа театрында С.Вәлиев-Сульва һәм Мамадыш колхоз-совхоз театрында Г.Йосыпов халык хөкеменә чыгарган була инде. Әсәрдә сугышка киткән ирен — колхоз рәисен алыштырган Мөршидәнең тормышы аша шул елларның фаҗигасе гәүдәләндерелә. Каһарман хатын ачлык-мохтаҗлык, яла, һәртөрле мәкер алдында сынмый, сыгылмый. Фронттан гарипләнеп кайткан ирен каршы алу күренешләре әсәргә лирика өсти, күңелне тетрәндерә. Халыкның елый-елый, өзгәләнеп караган тамашасына әйләнә бу спектакль.

Татар дәүләт академия театры (хәзер – Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) бинасы. 1930 нчы еллар

1944 елның 27 апрелендә Хөсәен Уразиков Академия театрында Мирсәй Әмирнең «Миңнекамал»ын халыкка тәкъдим итә. Шул заман тәнкыйтьчеләре спектакльне «Академия театры коллективының, татар драматургиясенең зур уңышы», дип билгеләп үтә.

Сугыш һәр гаиләгә төрле дәрәҗәдә кайгы китерә. Кемнеңдер этисе, абыйсы, энесе йә хатын-кыз туганы сугыш корбаны була. Шулай да, канлы афәт узгач, җәмәгатьчелекнең хәл-халәтен ныгытыр өчен иҗатчылар янә җиң сызганып эшкә алына, якты киләчәккә өмет уята...

***

1941 елның көзендә Урыс Зур драма театры (хәзерге В.И.Качалов исемендәге Казан дәүләт академия Зур драма театры) үзенең 150 еллык юбилеен үткәрергә ниятли. Әмма ният — ният кенә булып кала. Кырымда чагында сугыш йодрыгы аларның да ишеген шакый, 21 июньдә Ялтада «Патша Фёдор Иванович» әсәре белән гастрольләрен ачып җибәргән генә булалар әле... Күтәренке күңел, чәчәк букетлары аша вәхшәтле яңалыкның зәһәр елмаюын сизмиләр. Күңелсез хәбәр килеп ирешкәннән соң да, 22 һәм 25 июньнәргә билгеләнгән спектакльләр өзелми, урыс театры коллективын бары билгесезлек,

121 нче укчы дивизия ветераннары очрашуы. Сулдан икенче Зәкия Туишева, өченче булып Бикә Шакирова басып тора. Мәскәү, Кызыл майдан. 1991 ел

«Ни булыр икән?» дигән шөбһәле сорау гына телгәләп ала. Яңа борчуларга чумган җирле җитәкчеләрнең дә Казан сәнгатькәрләрендә гаме калмый. Мобилизация башлана, чакыру пунктлары шыгрым тула. Режиссёр А.Н.Кондратьева дәфтәрендә: «Актёрлар Муровский, Круглов, Люлюкин, Мангушев, Попов һәм сәхнә эшчеләре Игнатьев белән Волостновлар да фронтка китәргә язылды», — дигән искәрмә барлыкка килә. Труппаны Казанга кайтарырга да мөмкинлек кими, театр җитәкчелегенә кискен адымнар ясарга туры килә, чөнки немец самолётлары Кырымга хәтле очып җитә башлый. Поездлар тулы, билетың кулыңда булса да, төрткәләшмичә генә утырырмын димә! Йөк вагоннары турында хыялланырга да ярамый! Нәтиҗәдә, декорацияне, башка мөлкәтне Ялтада калдырып, «кече ватанга» буш кул белән кайтырга туры килә.

22 июльдә генә театр Казанда җыелып бетә ала. 8 августта исә «Минем улым» спектаклен кабатларга тотыналар. Төп эшкә керешкәнче, иртәнге якта төрле күнегүләр (химикатларга, һава һөҗүменә каршы һ.б.) үткәрелә. 24 августта әсәр сәхнәгә чыгарыла. 6 сентябрьдә «Украина далаларында» дөнья күрә. 22 октябрьдә өченче пьеса — «Фельдмаршал Кутузов» куела. 1812 елгы Ватан сугышын сурәтләгән әлеге спектакльнең режиссёрлары — Е.Гаккелем һәм Б.Ниренбурглар була. Патриотизмы ташып торган тамашада төп рольләрне әйдәп баручы артистлар башкара: Ф.Григорьев (Кутузов), И.Загорский (Даевский), П.Ососков (Давыдов), А.Гусев (Александр), О.Кохонский (Наполеон).

1942 елның июнендә урыс театрына да фронт өчен концерт бригадасы оештыруны йөклиләр. Бригадага (җитәкчесе — А.Гусев) О.Ананченко, А.Прудникова, Н.Зорин, Ф.Борисенко һәм Н.Спиридоновлар керә. Кайда гына булмый алар — Карелия фронты, Поляр түгәрәге аръягы... Хәтта Мурманскига кадәр барып җитәләр! Сәнгать әһелләре дә, барча халык кебек, афәткә каршы баса, сугыш чорында гаҗәеп фидакярлек күрсәтә. Төрле милләт вәкилләре авыр вакытта ярдәмләшеп, кулга-кул тотынышып, бергә-бергә яши. Нәтиҗәдә, гайрәтле дошманны җиңүгә ирешә.

***

Ниһаять, түземсезләнеп көткән 9 май килеп җитә. Бу көннәрдә шатлык илә кайгы яшьләре елга булып ага...

Бар мөлкәтен чаналарга төяп, карбуранда, язгы ташуларда биштәр асып, пычрак ерып, көзге зәһәр җилләрдә өшеп, ачлы-туклы килеш авылдан — авылга, шәһәрдән — шәһәргә йөргән,

Сугыш ветераннары (сулдан уңга): драматург С.Шәкүров, артистлар М.Надрюков, Б.Шакирова, Һ.Солтанов һәм театр хезмәткәре М.Нәбиуллин. 1989 ел

фронтларга барып җитеп, алгы сызыкта солдат-офицерларга концертлар куйган артистларыбыз алдында кем генә баш имәс икән? Алар иң фаҗигале көннәрдә өшегәннәргә — җылылык, ачларга — өмет, рухлары сыну алдында торганнарга — ныклык өләшкән!

Җиңүдән соң Күчмә театрга да сугыштан исән калган иҗатчыларның бер төркеме кайтып төшә: З.Хәлиуллина, З.Туишева, Т.Кичүбаев, М.Хәмзин, Ф.Юнысов, А.Әбдерәшитов, Г.Нигъмәтуллин... Шунысы кызыклы — гаризаларына алар: «Фронттан кайттым. Яңадан эшкә керешергә рөхсәт итегез», — дип яза; әйтерсең лә, дүрт ел буе ут эчендә булмаганнар да! Әйтерсең лә, чираттагы ялларыннан яисә командировкадан кайтып килешләре!

Күпмедер вакыттан соң берничә фронтовик Әлмәт театрына күчеп китә. Алар арасында бүгенге көндә 95 яшен билгеләп үтүче З.Туишева да була. Легендар шәхесебез, фронтовик, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Г.К.Хөсәенов 1979 елда бөек драматургыбыз Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасын куеп, үзен дә, авторны да, төп рольне башкарган кабатланмас актриса Д.Кузаеваны да Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек итә. 1970 елдан алып 1983 елга хәтле ул биредәге иҗат эшен профессиональ югарылыкка күтәрә, бу чор, Гали Кәрим улы җитәкчелек иткән чор — Әлмәт театрының алтын чоры саналырлык! Бүген дә Гали аганың мәктәбендә чарланган театрда Россия Федерациясенең иң көчле сәнгать йортлары белән ярышырлык, иң четерекле пьесаларны да җиңеп чыгарлык артистлар эшли. Бары тик бөек профессор, театраль философ, 1943 елда Ватан сугышыннан тән яралары алып кайткан Гали агабыз гына юк...

Күчмә театрга исә 1963 елның 1 гыйнварында баш режиссёр булып Равил Тумашев килә. Бу урында ул үзенең әнисе, искиткеч талантлы, Кәшифә апа Тумашеваны алыштыра. Ул яшь драматургларны тәрбияли. Алар арасында А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Р.Хәмид һәм, әлбәттә, Т.Миңнуллин да бар. Туфан ага үзенең драматургка әверелүен нәкъ менә Равил ага белән бәйли иде дә. Үз авызыннан ике-өч тапкыр: «Мине язган әсәрләремне сүтеп җыярга, анализларга театраль теоретик Равил ага Тумашев өйрәтте», — дигән сүзләрне ишетергә туры килде. Күчмә театр тарихында үзенең саллы эзен калдырган, 1946 елда гына орден-медальләр тагып исән-сау кайткан Сәет ага Шәкүровны замандашларым хәтерлидер әле. Ул да, кайтуга, актёрлык эшен дәвам итә. 1946-1956 елларда Мамадыш, Әлмәт, Минзәлә колхоз-совхоз театрларында,

Республика Күчмә театрларында эшли, 1956-1959 елларда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйный. Аннары ун ел буе Камал театрының баш администраторы, 1979 елдан Күчмә театрның директоры вазифасын башкара. Сәет ага пьесалар да яза иде. Аның «Тормыш бусагасында» исемле беренче әсәре Минзәлә театрында зур уңыш белән бара, Г.Камал театрында патриотик рухта язылган «Туган туфрак», «Тол хатыннар, тол кызлар» пьесалары уйнала. Күчмә театрда язучының «Саф күңелгә тап төшми» (1986) әсәре куелды. Сугыш чорына багышланган, авыл тормышын сурәтләгән бу әсәр озак еллар дәвамында сәхнә тотты, халкыбызның яраткан спектакленә әверелде. Режиссёры — Празат Исәнбәт, төп рольдә (Мулланур) — мин фәкыйрегез иде. Башка персонажларны да гаҗәеп талантлы, киң кырлы иҗатчылар — Р.Мифтахов, С.Исмәгыйлева, Ә.Галиуллин, Х.Шәкүрова, Н.Шәйхетдинов, И.Хәсәнов, М.Җаббаровлар башкарды.

Академия театрында фронтовик артистлардан М.Надрюков иҗат итә. Н.Гогольнең «Ревизор»ында — Осип, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында — Җиһангир, Б.Горбатовның «Бер төн»ендә — Богатырёв кебек бик күп образлар тудыра ул. 1947 елның сентябреннән Камал театрында икенче бер фронтовик артистыбыз Һидият Солтанов үзенең сәхнә тормышын башлап җибәрә. Илле еллык иҗат чорында ул бик күп баш рольләрне тамашачыга күрсәтте, шулар арасында М.Фәйзинең «Галиябану»ында — Исмәгыйль, М.Әблиевның «Шәмсекамәр»ендә — Рашат, Т.Миңнуллинның «Канкай улы Бәхтияр»ендә — Потёмкин кебек геройларны гына да әйтеп китү җитә. Ватан сугышыннан исән кайткан тагын бер шәхесебез — Д.Ильясовны өлкәнрәк буын татар тамашачылары М.Фәйзинең «Галиябану»ында — Хәлил, Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә — Искәндәр, «Диләфрүзгә дүрт кияү»ендә — Галим, Х.Вахитның «Талак, талак»ында — Шәйхулла рольләре аша хәтерлиләрдер. Шулай ук, Г.Фәтхуллин да соңгы көннәренә кадәр Академия театрында эшләде. Ул кечкенә генә рольләрне дә истә калырлык итеп башкара белә иде. Шулай ук Ф.Шәрәфиев, Б.Әшрәпов, Б.Шакировалар да ут эченнән исән-сау кайтып, бар көчләрен, сәламәтлекләрен халыкка хезмәткә багышлый.

Кызганыч ки, фронтовик артистларыбыздан бүген нибары ике генә кеше исән: берсе — Зәкия Туишева, Әлмәттә; икенчесе — Равил Тумашев, Казанда, улы тәрбиясендә; ул әле бүген дә татар театр сәхнәсе өчен бөтендөнья классикасын тәрҗемә итә, шуларны куйдырырга хыялланып яши. Сугыштагы батырлыклары өчен «За боевые заслуги» медале, «Кызыл йолдыз» ордены белән бүләкләнгән Равил аганың сугышчан рухы һаман сүнмәгән!

Алгы сызыкка барып җитеп, концертлар куеп, сугышчыларга бер генә сәгатькә булса да фаҗигане онытып торырга ярдәм иткән Р.Җиһаншина, И.Гафуров, А.Мәсәүетова, Р.Тәминдарова, Ш.Сарымсаков, К.Тумашева, С.Вәлиев-Сульваларның хезмәте әйтеп бетергесез. «Безне Төньяк-көнбатыш фронтына, Ленинград ягына җибәрделәр, — дип хәтерен яңарта иде Рәшидә апа Җиһаншина. — Юл кыр госпитальләре һәм аерым частьлар аша үтә. Көненә 2-3 концерт куябыз. Якында гына — сызгырып килгән снаряд, шартлау тавышлары...»

Бүгенге көндә ул тавышлар сугышта башын салганнарның истәлегенә һәм исән кайтканнарның фидакяр хезмәтенә салют, мәдхия булып кына яңгырасын иде!

Әдәбият:

Музы не молчали... /
Kazan-Казань. — 2010.
Татар театрына 100 ел. 2 томда. ТКН. — 2009. ■

ЖУКОВ ШОФЁРЫ

Морад Дусай

МӘРЬЯМ

Гомере буе биниһая зур кайгылар, кыенлыклар кичереп тә, күңелендә һәрдаим игелек нуры саклаган кешеләр бар. Мәрьям апа Хәбибуллина — әнә шундыйлардан.

Ул Лаеш районының Татар Агайбашы авылында туып үсә. Әнисе, утыз биш яшендә, дүрт баласын ятим калдырып, гүр иясе була. Әтисе Хәбибулла яманаты чыккан Суслонгер «тәмуг»ларын кичеп, 1943 елда яу кырында һәлак була. Мәрьямнең сеңлесен һәм ике энесен — Гайшәне, Әсфәндиярны, Нурлыханны — балалар йортына тапшыралар... Кызый авыру әбисе белән генә кала.

— Әсфәндиярны атка утырттылар да, хастаханәгә дигән булып, алып китә башладылар. Икенче энем Нурлыхан да арбага менеп утырды. Ат капка төбеннән кузгалып, хәйран ара киткәч кенә башыма җитте — туганнарымны балалар йортына озатулары икән... Гайшәне бераз соңрак алып киттеләр. Ике яшьлек сеңлемне кочагымнан тартып алганда, кычкырып еладым, аякларыннан үптем. Атаң белән анаң булмагач, кош балалары сыман тараласың икән ул... — дип, искә ала хәзер Мәрьям апа ул чорны.

...1943 елның маенда бер энесе балалар йортыннан качып кайта. Өчәү бергә яши генә башлыйлар — әбиләре үлеп китә. Тумыштан ук чая, тере һәм үҗәт (тормыш та өйрәткәндер) Мәрьям исә бирешми, белешә торгач, Әсфәндиярны да, Гайшәне дә эзләп таба, тәрбияләп үстерә.

АБДУЛЛА

Абдулла Хәбибуллин — Мәрьям апаның ире. Алар сугыштан соң өйләнешәләр.

Абдулла Дөбъяз районының (хәзер Биектау районына керә) Зур Кавал авылында 1924 елда дөньяга килә. 1942 елда 18 яшендә сугышка китә. Молдавияне, Румынияне, Югославияне, Венгрияне һәм Австрияне фашистлардан азат итүдә катнаша. Беренче контузиясен ул 1943 елның кышында Румыниядәге Корсунь-Шевченко шәһәре янында барган канкойгыч хәтәр бәрелешләр вакытында ала. Ике айга якын күчмә кыр госпиталендә дәвалана. 1944 елның көзендә Будапештны (Венгрия) азат иткәндә икенче мәртәбә контузия ала. Янә кыр госпитале... Шул ук елны Дунай елгасын кичкәндә немецлар понтон күперне шартлата. Абдулланың машинасы суга чума. Ефрейтор егетнең

Абдулла һәм Мәрьям Хәбибуллиннар. 1952 ел

Сугышчан полкның шофёрлары. 1944 ел

Уңнан беренче – Абдулла. Сугыш еллары

«Кызыл Йолдыз» һәм III дәрәҗә Дан ордены, документлары белән бергә, суга баткан машинада кала.

Австрия җирендә барган канкойгыч бәрелешләрдә Абдулла Хәбибуллин тагын ике тапкыр контузия ала, авыр яралана. Үлгән, дип, туганнар каберлегенә салгач, кабер казыган бер солдат аның кыймылдап куюын күреп ала. Шул рәвешле ул исән кала.

1945-1947 елларда Абдулла Хәбибуллин 20 нче укчы гвардия корпусы командиры генерал-лейтенант Михаил Запорожченконың шәхси шофёры булып хезмәт итә.

1945 елны беренче Җиңү парады алдыннан Абдулланы Мәскәүгә командировкага юллыйлар. Ул бер атна дәвамында маршал Георгий Жуковны машинада йөртә.

***

Абдулла һәм Мәрьям Хәбибуллиннар бер ул, ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Вәләкин Абдулла агага сугышта алган яралары (башына пуля тигән була) тынгы бирми, ул коточкыч баш авыртуларыннан унөч ел буе интегә. Мәрьям апа шул елларда аны сабыр гына тәрбияли. Әмма дә коточкыч сугыш дәһшәтләрен кичкән иренең сәламәтлеге көннән-көн югала бара, ул, нибары 56 яшен тутырып, акылыннан язып вафат була. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ УЗГЫРМЫШ БЕЛӘН МӨНАЗАРАСЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте бу сүзен:
– Ишеттем сүзеңне, тыңла син үзең.

Миһербанлык синең сүздән аңкыйдыр,
Кардәшлек билгесе, рухи якынлык.

Кардәш гамен кардәш кенә җиймәсә[1],
Синең хәлең чит-ят кешегә нәрсә?

Сәбәбе булмаса, сездән аерылып
Нигә торыр идем бу җиргә килеп.

Мин уйладым, күрдем – динем җитешсез.
Яхшырагы, дидем, – яшим кешесез.

Ялгыз гына торып, гыйбадәт кылсам
Иде, – дидем, монда килдем шунлыктан.

Бу дөнья эшенә бирелмеш кеше
Кямил башкаралмый ахирәт эшен.

Дөнья хәстәреннән йолынмый гына
Яралткан Тәңрегә кылынмый дога.

Һавалану муенын сындырсаң каты
Гыйбадәт вә тагать була бик татлы.

Ни ди, ишет, әнә уйланмыш кеше:
«Һавалану белән бармас дин эше».

Һавалану, нәфес — дин дошманыдыр,
Тәкъва колны шушы ике économicsдырыр.

Нәфескә юл бирсәң, тоткын буласың,
Тән хаҗәтенә килми кол буласым.

Хирыска юл куйма – акыл илә кый,
Тәнең баш күтәрсә – белем илә тый!

Мин шунлыктан авыл-шәһәрне ташлап,
Бу җиргә сыендым. Һәрьягым – ташлар.

Кешеләрдән читтә торып бик әйбәт,
Беркемне рәнҗетмим, сөйләмим гайбәт.

Кыендыр ич ялгыз, диярсең, кардәш.
Ходайны яд итү – миңа фикердәш.

Якын кардәшләрдән мин ерак булдым –
Борчымас аларны ачым вә тугым.

Халык күңле нечкә – яулавы кыен
Күңелен сындырсаң, Аллага сыгын.

Халыкка юк икән миннән зур файда,
Шулай ук, ил-көнгә юк ич зыян да.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Гамен җийү — берәүнең хәленә керү, кайгысын уртаклашу.

Халык күңле нечкә – яулавы кыен
Күңелен сындырсаң, Аллага сыгын.

Файда вә зыян һәм начар вә яман
Торадыр тәкъдирдән, ягъни Алладан.

Күр, гарештән түбән кара җиргәчә
Ходайга хаҗәтле һәркем, һәрнәрсә.

Кеше арасында ни бар, и, мәшһүр,
Зыян яки файда сиңа бик мәгълүм.

Тагать-гыйбадәттән ни файда, дисең.
Рухи азатлыкка гыйбадәт – ишек.

Кол ни өчен, дисәң, кол дип аталган?
Дога кыла көн-төн ул бер Аллага.

Бу ялгызлыгымнан миңа зыян юк:
Тәнемнән бу җирдә таптым азатлык.

Ни ди, ишет, ошбу бәйтне әйтүче:
Тышын күрмә сүзнең, багып күр эчен.

Кешеләргә катнаш, дип әйттең, кардәш,
Катнашырга лаек бары дус, кандаш.

Миңа килгәнеңнән бирле, күр, бүген
Күпме гыйбадәтне калдырдым бүлеп.

Бу озак гәпләшү соңында минем
Күпме вакыт әрәм, көчләмә инде.

«Кеше арасына» керсәм мин тагын,
Гыйбадәткә вакыт каян соң табыйм?

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте шул сүзен:
Мин ишеттем, тыңла, бормыйча йөзең.

Бу әйткән сүзләрең нәкъ шулай булса,
Хакыйкать күзеннән аларга юк сан.

Куәтлә кешене тере чагында,
Күтәр син күңелен аның аз гына.

Бу ялгызлыгымнан миңа зыян юк:
Тәнемнән бу җирдә таптым азатлык.

Куәтлә кешене тере чагында,
Кутәр син күңелен аның аз гына.

Яшәвең билгесе нидән гыйбарәт?
Хәерле бер эшне аткару кирәк!

Хатын алсын егет, үссен угыл-кыз.
Күрексез бәндә ир, булса угылсыз.

Ни дип әйткән изге күңелле затлар?
Нәсел киселмәсен – хатын ал мотлак.

Үлгәндә үкенеп әйтер баласыз:
Туганнарым, угыл-кызсыз калмагыз.

Әгәр ки берәүнең угылы калса,
Син аны, үлсә дә, тере дип ата.

Угылсызның корыр нәсел агачы,
Урыны буш калыр, җуелыр аты.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: – Бу сүз хак,
Ләкин бүтән бер шәй башкачарак.

Ярый ла угыл-кыз булса бик ипле,
Әле син бик матур әйткән шикелле.

Әгәр балаң кара җиргә каратса?
Үзең үлгәч истән чыгарып атса?

Исемеңне сатса, нигезсез каргап,
Мактанырга сылтау бирсә ятларга?

Андый бала сиңа дошман-яу гына,
Дошмансыз яшәвең, шиксез, җайлырак.

Яудан нинди якты нур килер дисең?
Яу аты ясыңнан хәбәр[2] дип бел син.

Ул белемле белкә сүзе файдасыз:
Төтене бетмәс ут була угыл-кыз.

Монда бап икенче бер белкә сүзе
(Аның уе ачык – әйткән дөресен):

«Уйлап сызланасың угыл-кызларны –
Бу хәлеңне белгән угыл-кыз бармы?

Юньсезеңне терәп, үзең авасың,
Интегәсең, күзли ул үз файдасын.

Өйләнгән – гүяки кимәгә кергән,
Диңгезгә чыккан һәм җилкәсен киргән.

Ә балалар тугач, җилкәнең сынар,
Йөрерсең диңгездә йомычка сыңар.

Угыл-кыз атасын саный ахмакка,
«Әти, әни» дими хәтта, кайчакта.

Бу төр балаларда күренми вафа,
Кыланышы явыз, коллыгы җәфа.

Угыл-кыз атасы көчкә тын ала –
Филгә төягәндәй йөк төйи бала».

Адаш-кордаш кирәк, дисең, һәм дуслар.
Яхшы, ләкин авыр алар күп булса.

Дустың күңле сынса, дошманлык туар,
Дошманлык бар җирдә мең бәла чыгар.

Ничек дөрес әйткән башлы бер белкә:
«Кеше күңлен күрү кыен – ул нечкә».

Кеше күңле, – диләр, – мисле пыяла:
Бик сак кыланмасаң, төшә, уала[3].

Күңел-йомшак нәрсә һәм менә шуңар
Эссегә тиз эрер, бозга тиз туңар.

Дустың күңле сынса, дошманлык туар,
Дошманлык бар җирдә мең бәла чыгар.

Яшәвеңнең тәмен җуя ул дошман,
Тыныч яшәүгә чик куя ул дошман.

Дошман ничек кенә кечек булмасын,
Батыр дустым, аны зур, дип уйла син.
Ни ди, ишет әнә, дошманлы кеше
(Сугышны күп күргән, олгайган яше):

[2] Күрәсең, бу борынгы бер мәкаль; яс (татар сөйләшләрендә дә бар) «мәет күмү, матәм, җеназа».
[3] Бу мәкаль татарда хәзер дә кулланыла.

«Чүп ул безгә дошман», дип ахмакланма,
«Нигә куркыйм», дип үк алдан мактанма.

Гафиллектә ятма дошман булган да.
Дошманга дошман бул, дус бул дусларга.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавап бирде – килде Үгделмеш телгә,
Әйтте: – Ишет, уйлан һәм ал күңелгә.

Түрәтте Тәңре бу дөньяны белеп,
Ашауны-эчүне хәләлдән кылып.

Аралашканнарың булса яхшы, иш,
Алар белән эшләп була яхшы эш.

Кеше юньле булса кушыл син аңа,
Аңар ярдәм итсәң, файда бар сиңа.

Ялгызын яшәгән бәндә – кыргый[4] ул,
Аңардан һичкемгә файда булмый ул.

Кешегә катнашмас кемсә – ул үлек:
Үлек булма, кардәш, шул миннән үгет.

Күбәйсә кешенең юлдаш-кулдашы,
Тарала яхшаты һәм бара эше.

Бу дөнья эчендә теләген таба,
Ахирәт өчен дә терәген таба.

Фида кылса үзен кайгы булганда,
Бергә сөенешер шатлык килгәндә.

Ирдәмеңне илгә сөйләр ул, ләкин
Ноксаныңны бер дә сөйләмәс, ләм-мим.

Яу чыкканда гына батыр беленә,
Уянып, кылычын таккач биленә.

Яу юкта уянмас батырның җаны,
Шулай ук илара җәелмәс даны.

Ләкин ирдәмлеге күбәеп китсә,
Шулай ук күбәя хас дошман кемсә.

Күбәйсә кешенең юлдаш-кулдашы,
Тарала яхшаты һәм бара эше.

Кемнең фазыйләте, кыйммәте артса,
Көнләүчеләрдәй, дошман җыела артта.

Кеше яхшы булса, калмас дошмансыз,
Явызның явы юк, чөнки ул җансыз.

Каю иргә каршы җыелса төркем,
Димәк, бүтәннәрдән ул кеше өстен.

Үзара көрәштә ир даны артыр,
Дошманы юк, димәк, ул ир тик ятыр.

Ни ди ишет, әнә ирдәмле бер ир:
«Теләгенә тырыш ирләр ирешер.

Ничек бер ир-егет дошман мең иргә?
Чөнки тегеләр ич сөйлиләр бергә.
Бүре әйләнеп тә карамый эткә,
Мең эт тотынса да арттан өрергә».

«Кешене ялгызын эзләмәм», дисең,
«Корыга сөйләнмәс, – дидең, – бер сүзем».

Кеше сөйләр инде кеше турында:
Кеше арасында яшәп торыла.

Чын ир-егет була, сак булса телдә,
Сүзгә катнашса тик утырып түрдә.

Каты сүзгә каршы йомшак сөйләсә,
Ачы сүзләр өчен шикәр түләсә.

Кешене күтәртми, үзе күтәрсә,
Җәберчегә килеп ярдәм итәлсә.

Ачуын бастырып, җуйса үчен дә.
Эчендәге булсын, – диләр, – тышында».

Ни ди, ишет, әнә кеше изгесе,
Изгелеге белән дан алган кеше:

«Яман сүз әйтмә һичкемгә, тыйнак бул,
Яман сүз ярасы сыкратыр күп ел.

[4] Оригиналда — кыпчак!

**Чын ир-егет була, сак булса телдә,
Сүзгә катнашса тик утырып түрдә.**

Сине берәү сүксә, син аны макта,
Ул тәмугта булыр, ә син – оҗмахта!»

Җәфа кылучыга вафа кыла тор.
Ир түгел, имгәкләр җәфа кыладыр.

Чөерсә дә синнән йөзен якыннар,
Син аларга елыш, һаман якын бар.

Кичер син кешене, явызлык кылса,
Үчегеп маташма. Дин шулай куша.

Язык кылса кол-көң, кичер языгын.
Гафучәнлек булыр күңел азыгы.

Усал дигән исем алган кешеләр
Азак борчылуда үлем көтерләр.

Ялгыз яшәп, читтә торсын, ди, йортың,
Изгелекме бу, и, изге холыклым?

Рәхәт-нигъмәт, хөрмәт йөзен күрмәдең,
Көмеш, алтын, гәүһәр сиңа кермәде.

Сәрай, кирмән, җир-су, атларың да юк,
Угыл-кыз шатлыгы, хәстәре дә юк.

Кешеләр үзәрә хөкем йөртергә,
Кулың-ихтыярың җитми беркемгә.

Кая табып, җыеп килгән мөлкәтең?
Һәркем атый «җүләр заһит, тилбә», дип.

Күбен ташлап, азын теләсә ирләр,
«Заһитлык кәмәрен баглаган», диләр.

Күпләр ирексездән «заһит» булалар,
Чөнки бүтән чара тапмыйлар алар.

Чын ир заһит була кирәк булганда –
Иле-халкы өчен көрәш юлында.

Аш-суын өләшә ярлы-толларга,
Ходайга ихластан укып догалар.

Ул күңел багламас байлык килсә дә,
Кашын төймәс «байлык китә», дисәләр.

Теләге үтәлгәч, кулын ала ул,
Нәфесенә хуҗа булып кала ул.

Бер мәкаль куәтли минем бу сүзне
(Ишет һәм эшкә тот, и, холкы төзем):

«Ирәннәрнең ире шундый булыр ки
Һичкайчан югалтмас ихтыяр-иркен.

Шундыйлардан иң шәп егет шул булыр:
Мең теләге булсын – тыела белер».

УЙГЫРМЫШНЫҢ СОРАВЫ

Җаваплап Уйгырмыш әйтте: – Дөресен
Генә әйт, аййөзем, син ни телисең?

**Чын ир заһит була кирәк булганда –
Иле-халкы өчен көрәш юлында.**

Мин сорый башласам, сүземне кисеп,
Җавабын бирәсең гүяки этеп.

Ачыклап әйт миңа – эш нидән тора?
Сорамакчы булсаң, туп-туры сора.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Үгделмеш әйтте: – Эш менә нәрсәдә,
Сүземнең төбендә бар бер мәсьәлә.

Бу Көнтуды синең хакта ишеткән.
– Миңа кирәк, китер, – диде, – ничек тә.

Сине күрергә ул бик тә телидер.
Илче итеп менә мине күндерде.

Авырга килсә дә барырга кирәк,
Күңелен илбикнең табырга кирәк.

Бу илбик-хуҗабыз бер изге солтан,
Сөйгән халкы өчен бирә тән вә җан.

Дәвамы бар ■



КИРПЕЧ ЯСАУЧЫ
ШАПУР ҺӘМ ХУҖА МОЗАФФАР ХИКӘЯТЕ

Аннан әмир боерды, төшерделәр, ике аягын бәйләп, җәза мәйданына илттеләр. Әмир шулай фәрман бирде: ике кулыннан дарга асып куйсыннар, бүтән аска төшермәсеннәр, череп төшкәнче торсын, халыкка гыйбрәт булыр, башкача аның кебек эшкә батырчылык итмәсләр.

Кыскасы, Шапурны базар эчендә дарга астылар. Халык тирәсенә җыелды, шау-шу күтәрделәр:

– Болай эшләүдән ни файда? Бу бит таныклык бирмәде, гаебен танымады. Гел юк өчен адәмне үтерүнең ни мәгънәсе бар? Боның кебек газаплау шәригать кануныңа да, диван кануныңа да сыймый. Әгәр дә бу эш хәлифәгә ишетелсә, шелтәсенә вә ачуына дучар булырбыз, – диделәр, Шапурның бавын кистеләр.

Шапур җиргә төште, бер сәгать һушсыз ятты. Аннан торды, абына-сөртенә өенә кайтты. Мозаффар кызы җаны урынына күргән сөеклесен бу хәлдә күргәч, елады.

– Минем өчен күпме газаплар чиктең, мин сине үземнән җибәрмәм. Атам һәм кардәшләрем мине сөяләр, бәлки дәгъваларын бетереп, онытырлар, гафу итәрләр, бәлки шулай җае белән генә бетсә, әлхәмдүлилләһи, яхшы булыр иде. Әмма, шулай да, тагын бер сылтау табу, шуның турында уйлау кирәктер, – диде.

Шапур гадәтенчә мунчага барды, аннан өйгә кайтты, бераз ял итәргә, ятып торырга булды. Әмма кинәт казый килде, тагын күп нәсыйхәтләр итте, әмма файда булмады. Ахырда Шапур әйтте:

– Әй, казыйларның падишаһы! Сүзне хөрмәт белән сөйләү тиештер, шәригатькә

Ахыры. Башы 3 нче санда.

сыймаган нәрсәләр сөйләүнең ни мәгънәсе бардыр? Син мине кияү булырга тиң түгел, дип сөйлисең, сиңа минем хәлем кайдан мәгълүм булды, атам вә анамны кайда күрдең вә бу хәлләрне кайда ишеттең? Алар бит асыл зат булуда мең Мозаффарга торалар, син бу сүзләрне хыял итеп, уйлап чыгарып кына сөйлисең, казыйлык шулай булырмы фарсы илендә?! Атам данлыклы, мәшһүр Хуҗа Габдулладыр, анам казый Рокнеддин кызы Нәсыйхәдер, абзам Хуҗа Мәсгуд Кәзирунидер, аның изге эшләре, язган китапларының даны көнчыгыштан көнбатышкача таралгандыр. Әмма язмыш бардыр, мине Хиҗазга бару нияте биләп алды, бик күп мал-мөлкәт белән юлга чыктым, юлда куркыныч бер вакыйгага очрап, малымны юлбасарлар алды, үземне җәрәхәтләп киттеләр. Шушы шәһәрдән ары китә алмадым, колымны атама хәбәр итү өчен күндердем. Менә хәзер мин атамнан мал-мөлкәт килгәнне көтәм, ә син «динарларны ал, юлга кер», дип аптыратасың.

Казый бу сүзләрне ишетте, бераз йомшарды. Шундагы җәмәгатькә:

– Башка сүз юк, әмма ышаныч өчен тагын бер эш кылу кирәк, – диде. Аннан Шапурга әйтте:

– Син әйтәсең: «Атама кеше күндердем, аннан кәрван килер», – дип. Кайчан килер, ничә көнгә кадәр көтәргә мөмкин, дөресен әйт, – диде. Шапур әйтте:

– Егерме көнгә кадәр килер.

Казый әйтте:

– Әгәр килә икән, бик яхшы, әгәр килми икән, вәгъдә бир: хатынны талак кыласың!

Шапур бу эшкә ризалык бирде, гадел шаһитлар каршында килешенүне дәфтәргә яздылар.

Шапур торды, өенә кайтты, хәлне сөйгәненә белдерде. Кыз әйтте:

– Һич куркыныч түгел, әле озак вакыт бар икән.

Бәс, Шапур кыз өендә һичкая чыкмыйча, аулакта ятты. Кыз һәр көн яхшы ризыклар әзерләр иде, бөтен кирәк-яракны китертер иде.

Болар торган өйнең тәрәзәсе Диҗлә[1] елгасы ягына ачылыр иде. Шапур шул тәрәзә төбенә утырып, рәбаб чалыр иде һәм һәр пыяла эчкән саен моңлы бер җыр җырлар иде. Үкенечкә каршы, белер иде: һәр сөйләгән нәрсәсе — ялган, хәйлә һәм вакытны сузарга сылтау иде. Чөнки Кәзирунда ни атасы, ни анасы, ни дус, ни дошман бар иде, кирпеч ясый торган калыптан башка нәрсәсе юк иде.

Әйтер иде:

– Күз йомып ачканчы ул егерме көн үтәр, казый хатынга талак бирдерсә, Шапурны мәҗлес капкасыннан эт кебек куарлар, – дияр иде.

Шул рәвешчә унҗиде көн үтте. Унсигезенче кичтә гадәтенчә тәрәзә төбенә утырып, шәрабын эчеп, рәбабын чалып, аерылышу турында моңлы җырлар көйләр иде.

Алланың тәкъдире белән шулай булды: бер кичтә мөэминнәрнең әмире Һарун әр-Рәшид үзенең вәзирләре Яхъя Бәрмәки һәм Гобәдә белән сөйләшеп утыралар иде. Хәлифә әйтте:

– Шуны ишеттем: халык кичләрен көймәдә йөреп тамаша итә икән. Миндә дә шундый теләк уянды, яшерен рәвештә, һичкем танымаслык итеп йөрергә чыгам. Бу кичә бик якты, тамаша кылып йөрергә мөмкинлек бар, – диде.

– Фәрман сездән! – дип өчесе дә тордылар, килеш-килбәтләрен, киемнәрен үзгәртеп, башкага алыштырып, бер көймәгә менеп йөрделәр, елгага карап торган йортларны, тәрәзәләрне карап йөрделәр.

Шулай туры килде ки – бер тәрәзәгә килеп җиттеләр – Шапур тәрәзәсе икән.

[1] Диҗлә — Багдад уртасыннан ага торган зур елга (Тигр).

Хәленә көенеп җырлаган авазын ишеттеләр. Туктадылар, белделәр: чалынган саз рәбаб икән, җырланган көй фиракънамә[2] икән.

Бераздан ул аваз тынып калды, кычкырып, зарланып елаган тавыш ишетелде. Гаҗәпләнделәр:

– Бу нинди гаҗәп хәл икән? – диделәр. – Бу хәлдән хәбәрсез булу тиеш түгел, нинди юл белән булса да моның серен ачу кирәк, – дип көймәчегә әйттеләр:

– Көймәне ярга чыгар, әнә шул тәрәзә төбенә бәйлә, шунда тор, беркадәр вакыттан монда килербез, – диделәр.

Сарайның капкасына килделәр, боҗрасын ордылар. Шапур йөгереп аска төште, бусагадан тавыш бирде, «кем ул?» диде. «Кунакбыз», диделәр. Капканы ачты, кунакларны эчкә алды, шәм янына китерде: өч егет, чибәрләр, олылыклары, затлылыклары маңгайларыннан нур булып бөркелә, йөзләрендә дәүләт нуры бар. Шапур кунакларга кадер-хөрмәт күрсәтте, сыйларга тырышты. Алар моның күңеле өчен бераз капкаладылар. Аннан Шапур бер пыяла эчте, кунакларга сузды. Каршы килми алдылар, эчтеләр.

Аннан рәбабны кулына алды, кылларын рәтләде, фиракънамәдән ике бәйт[3] җырлады. Җылый башлады, күз яшьләрен түгеп, беразга тынып калды.

Гобадә нәдим[4] сорады:

– Әй дус, ни өчен елыйсың?

Шапур әйтте:

– Кыйссам озындыр, сөйләсәм, күңелсезләнерсез, арырсыз, артык файда булмас, – диде. Өчесе бердән әйттеләр:

– Арымабыз, бик файдалы булыр, – диделәр. Шулвакыт Шапур тәмле тел белән тәмам хикәяне сөйләде, ахырда әйтте:

– Казый каршында ялган һәм буш сүз сөйләнелде, әмма вакыт үтте, нибары ике көн калды, шуннан соң җефетемә талак биреп, аерылып китәргә мәҗбүр булам, – диде, елады, шулай итеп әңгәмәдәшләренең йөрәкләренә ут салды. Шул мәлне пәрдә артыннан бер хатынның үксегән авазы ишетелде. Сорадылар:

– Ул елаган кемдер? – диделәр. Шапур әйтте:

– Хатыным, Мозаффар кызы, миннән аерылмаска тырышуы минекеннән артыграктыр, диде. Кызны яннарына чакырдылар:

– Моның хатыны булып калырга ризамысың? – диделәр. Кыз әйтте:

– Аның өчен җанымны бирермен! – диде.

Әйттеләр:

– Күңелегезне Тәңрегә баглагыз, Алла теләсә, эшегез сез теләгәнчә тәмам булыр, – диделәр, тордылар, киттеләр.

Юлда барганда үзара сөйләштеләр:

– Бу егетнең эшен кайгырту кирәк, алар ниятләгәнчә башкарып чыгу кирәк, – диешделәр.

Мөэминнәрнең әмире әйтте:

– Хәзинә ишекләрен ачсыннар, кырык дөя йөге Кәзирун комачы, җәймәләр, япмалар, чалмалар, яулыклар, кыйммәтле тукымалар чыгарсыннар, алтын белән чигелгән яулыклар, кыйммәтле тукымалар чыгарсыннар, күзләре кара, алтын белән баштан-аяк бизәлгән кырык курчакны дөяләргә атландырсыннар, биш төркем голәм дөяләрне җитәкләсеннәр. Мозаффарның кияве булган Шапурның атасы Габдулла авызыннан бер хат язсыннар, эчтәлеге шул булсын: «Әй, сөекле углым!

[2] Фиракънамә — гашыйкларның аерылышу җыры.
[3] Бәйт – ике юллык шигырь.
[4] Нәдим – шаһ янында киңәшче; фаворит.

Минем күз алдымнан син югалганнан бирле, сабырым һәм чыдамым калмады, кайтыр, дип өмет итә идек. Инде ярый, исәнлегең хакында безгә хәбәр килеп иреште. Безне ташлап, ул җирдә өйләнү ниятең бар икән. Зинһар, бу уеңны башыңнан чыгарсаң икән, өеңә юнәлсәң икән. Ә инде һич булмаса, шулай кирәк икән, өйләнер булсаң, бер олы йорттан җефет ал, насыйп ярың булсын. Аннан шуны бел: егетлек вакытында Багдад шәһәрендә булып, әмире-л-мөэминин[5] белән якынлыгыбыз бар иде, минем хакымда күп яхшылыклар иткән иде. Тагын бер хат белән аңа синең хәлеңне белдердем, мөгаен, сиңа нигъмәтләр бирер, сине газиз күрер. Аның хезмәтендә ышанычлы бер кешем бар, Җәүһәр исемле, ул да сиңа ярдәм итәр. Синең өчен кырык йөк төрле тукымалар йөкләтеп кырык дөя җибәрдем. Кайтырга ниятең бар икән, кайтырсың, әгәр инде, Алла сакласын, өйләнеп калачак булсаң, безгә хәбәр итәрсең. Тагын нинди кирәгең, хаҗәтең булса, җибәрербез, ниебез булса – синекедер. Үзең хат язып җибәр, зинһар тиз безгә хәлеңне белдер, чөнки күңелебез билгесезлектә тынгысызланып тора. Вәссәлам!»

Һарун әр-Рәшид тагын боерды:

– Хуҗа Габдулла авызыннан бер хат – васыятьнамә язсынар, болай дип: «Хәлифә хәзрәтләре! Шапур колыгызга игътибар итсәгез икән, аңа мәрхәмәт итеп, минем улым икәнлеген олыларга белдертсәгез икән». Тагын да шул хакта аңлатып берничә сүз язсыннар: Хуҗа Габдулла хатында күрсәтелгән әсбапларны бу көн әзерләсеннәр, – дип вәзирләренә күрсәтмә бирде.

Хәлифә сараенда бер күркәм сурәтле хезмәткәр бар иде, күп нәрсәләргә хуҗа иде, үзен һичкемнең күргәне юк иде. Аны катына чакырды, ул ике хатны кулына бирде:

– Бу төндә дөяләрне йөкләт, тагын биш төркем голәм әзер булсын. Шәһәрдән чыгыгыз, дала юнәлешендәге капкадан шәһәргә керерсез, качырыңа менеп алдан йөр, Хуҗа Мозаффар һәм Шапурны сораш, «Кәзируннан килдем, Хуҗа Габдулла колымын, аның углына килдем, бу дөяләр аныкыдыр», дип әйттеп йөр, – диде.

Хуҗа Җәүһәр аңлы кеше иде, хәлифәнең теләген, максатын белде, бу эшләрнең һәммәсе хәлифәнең яшерен сәдакасы, ярдәме икәнен төшенде. Ничек боерылса, шулай эшләде.

Бу якта хәлифә белән Яхъя кичәге төндәге кебек тордылар, көймәгә менделәр, Шапурның тәрәзә төбенә килделәр. Килеп капканы кактылар. Шапур кире чыкты, үзен үзе тыеп, тыныч булырга тырышып, кунакларны эчкә алып керде. Болар:

– Хәлең ничек, кичәге кайгы-хәсрәтләрең бетмәдеме әле? – диделәр. Шапур, гафулар үтенеп, ризык китерде, ашадылар. Аннан соң шәраб эчәргә мәшгуль булдылар. Шапурдан сорадылар:

– Дошманнарың белән эшләр ни хәлдә? – диделәр. Шапур әйтте:

– Бер көнем калды, инде берсекөнгә вакыт тәмам чыгар, мине Багдад капкасыннан тышка куярлар, – диде. Тагын күз яшьләрен агызып елады. Кунакларның эче көенде, Шапурны үгетләделәр:

– Хәсрәтләнмә, Тәңре юмарттыр, эшең теләгәнеңчә булыр, нигә елыйсың?! – диделәр. Шапур:

– Рас әйтәсез, яхшылыклар иясе Ходайдан үзгәгә һич өметем юктыр. Нигә генә инде Казый тирәсендә җыен ялган, уйдырма сөйләдем, Кәзируннан чыккан чагымда бер кирпеч калыбыннан башка нәрсәм юк иде, аны да саттым, нишлим, ниләр генә кылыйм?! – диде.

Алар әйттеләр:

– Күңелеңне Ходайга багла, Аллаһны күр: нишләтер, – диделәр, күңелен юатып киттеләр.

---

[5] Әмире-л-мөэминин – мөэминнәрнең әмире (Һарун әр-Рәшид).

Ул төнне иртәнгә тикле кыз белән Шапур кайгырышып, борчылып сөйләшеп чыктылар, туктаусыз еладылар, качу чарасын да уйлап карадылар, башкара алмадылар, Шулай төн үтеп китте.

Шапур иртән мунчага барып кайтты, кайтып, ишек катында меңнәрчә борчулы уйларга чумып утырганда, тыштан шау-шу авазы ишетелде. Шапур бу авазга колак тотып, тышка чыкты, бераздан күрде: кызның якыннары, шатлык-куаныч белән балкытып, яныннан Җәүһәр белән сөйләшеп киләләр.

– Кайда алар? – дигән сорау да ишетелде.

Йортта булган хезмәткәрләр Шапурның исемен белмиләр иде, аны эзләп төрлесе төрле якка йөгерештеләр. Килделәр, Шапурның кулын үптеләр.

(Шулай була бит ул: әгәр берәр файдасы тияр кешенең эшен рәтләр өчен берәүгә бер алтын бирсәң, җан вә тән белән мактап туя алмас.) Шапур күңелендә:

– Моның кебек эшләр күп булыр, әмма миңа карата мондый мөнәсәбәт кайдан килсен, ялгышканнардыр, башка берәү белән бутый торганнардыр. Мин кайдан да, дөяләр башлыгы Җәүһәр кайдан?! Кәзирундa каргага атар ташым юк иде, бу ни хәлдер?! – дип уйланып торганда, Җәүһәр килде, Шапурның кулын үпте, хатны бирде:

– Атаң-анаң сиңа сәлам әйтеп калдылар, якыннарың, карендәшләрең кулыңны үбәрләр, йөзеңне күрергә телиләр, күзләре-колаклары юлдадыр, – диде.

Җәүһәр бу сүзне сөйләгәндә Шапур гаҗиз булды:

– Эш гаҗәп якка борылырга мөмкин, әгәр бу мал иясе дөяләр килгәнен ишетсә, килер, таварын алыр, мин бик каты оятлы булып калырмын, — дияр иде, дүрт якны күзәтер иде. Бу хәлдә Җәүһәр әйтте:

– Әй, әфәндем! Боер, йөкләрне эчкә куйсыннар, дөяләрне карасыннар, юл йөреп арыганнардыр, уйланып тору вакыты түгелдер. Атаң әмире-л-мөәминин җәнабенә хат язып җибәрде, сине аңа васыять итте, күп бүләкләр җибәрде. Мин барыйм, хатны һәм бүләкләрне тапшырыйм, – диде.

Мозаффарның хезмәтче егетләре, уллары, дөячеләре йөкләрне өйгә куйдылар, тәртипкә алдылар, дөяләрне бер җиргә оештырып, ашарларына бирделәр, дөя куучыларны кунак иттеләр

Әмма Шапур бик нык борчылды, йөзе караңгыланды, әле ярый кич җитте, гадәттәге эшенә мәшгуль булды, әмма күз яшьләрен, зарларын арттырды.

Кинәт әүвәлгечә капка ачылды. Шапур чыкты, күрде: төнге әңгәмәдәшләре басып тора. Керделәр, баягы җиргә утырдылар, ашау-эчүгә мәшгуль булдылар. Шапурга:

– Дошманнарың белән эшләрең ни хәлдә? – диделәр. Шапур сөйләде:

– Хәлемне сорасагыз, хәлем шулдыр: бер гаҗәп нәрсә килеп чыкты, андыйны һичкем күрмәгәндер вә ишетмәгәндер. Бу көн иртән утырыр идем, шау-шу пәйда булды. Чыктым, күрдем: капка төбенә халык җыелган, миңа беравыздан кычкырдылар:

– Шатлан, атаң колы Җәүһәр килде, дөяләр белән йөкләр, әсбаплар китерде, – диделәр. Аптырап калдым, бераздан Җәүһәр килде, кулыма хат сузды. Габдулла сәүдәгәр үз углына язган икән, шулай-шулай дигән, хәлифәгә мине васыять иткән, бу Җәүһәрне аңа бүләк итеп биргән икән. Бу вакыйгадан уйга калдым, әгәр дә бу җибәрелгән әйберләрнең чын иясе килеп чыкса, миңа бик каты оят була, миңа буйсынганнар мине куалар һәм мин аерылышу ачысы белән җәфаланам. Тагын шуннан куркам ки: бу эшләр әмире-л-мөәминингә ишетелсә, тикшертә, ачыклый һәм мине җәзаларга боера. Башта кайгым бер иде, хәзер ике булды, – диде. Тагын елый башлады. Болар юаттылар:

– Артык кайгырма, уйланма, барча эшләрнең ахыры Ходадандыр, Ходасы булганның ни кайгысы бар, – диделәр. Бераз эчтеләр, хәерле теләкләр белән китеп бардылар.

Шапур ул төндә авыр уйлардан йоклый алмады. Иртән кызның атасы һәм карендәшләре килделәр, утырдылар, гафу үтенделәр, кичкән эшләр өчен оялуларын белдерделәр. Шапур үзе оят тиренә батып утырганда кинәт чаушлар[6], сәрһәңнәр[7] капкадан эчкә килеп керделәр:

– Хәлифә сәлам әйткән иде, Хуҗа Габдулла дустыбыздан бер васыятьнамә килде, Шапурны миңа тапшырган, яхшы киемнәрен киеп килеп, хатын күрдек, инде үзен күрик, авыр хәлендә ярдәм итәрмен, – диде.

Шапур бу дәһшәттән, бу куркудан тетрәде, чарасыздан киемнәрен киде, тышка чыкты, күрде: өстенә алтын-көмеш җепләр белән чигелгән япма түшәлгән, иярләнгән качыр хәзер тора. Ияр катында торучы качыр йөртүче качырның аягын үпте, Шапур качырның тезгенен үпте. Шапурны качырга мендерделәр, җәмәгать яныннан җәяү бардылар, чаушлар хөрмәт белән, олылап капкага илттеләр.

Эчкә керделәр. Шапур күрде, таныды: үзендә кунак булган өч егет утырганнар. Берсе хәлифәлек урынында, икесе тезләнеп әдәп белән утырышканнар. Шапурның, боларны күргәч, акылы китә язды, һушсыз-сүзсез калды, берникадәр хәйран булып торды.

Аннан тиз генә түргә таба үтте. Сарай уртасында туктап йөзен җиргә куйды, елады. Яхъя торды, янына килеп кулыннан алды, хәлифә катына китерде, «кулын үп!», – диде. Шапурның тәненә калтырау төште, үзен көчкә кулга алып, хәлифәнең җиңе очын үпте, тезләнеп, башын келәмгә салды. Аннан торды, әүвәл торган урынына кире килеп торды. Яхъя Шапурны үз янына чакырды, янына алды:

– Күрдеңме: ни булды! Күңелеңне хуш тот, каршылыклар китәр, әмире-лмөэминин дошманнарыңа үч итеп, сиңа нигъмәтләр бирде. Бу серне яшер, эчеңә биклә, Тәңрегә шөкер ит, алга таба бу эшеңдә ниләр булыр – күрерсең. Моннан соң хөрмәтең күккә чыгар, күп кешеләр сиңа ярдәм итәргә торырлар, – диде.

Шапур шунда булып үткән хәлләрне уеннан кичереп, мәсьәләне аңлады, тәмам тынычланып калды, көенечләре юкка чыкты.

Аннан соң аны тәмам мал-мөлкәт белән өенә озаттылар. Шапурның эше югары ашты, казый һәм әмир бу эшне, бу хәлне күреп, тиешле бүләкләрен алып, Шапурга илттеләр, гафу үтенделәр. Каенатасы һәм аңа мөнәсәбәтле якыннары, дус-ишләре һәм чит-ятлар да аның ярдәменә мохтаҗ булдылар.

Ә ул кызның әүвәлге ире һәм аның якыннары, бу хәлләрне күреп, нишләргә дә белмәделәр, бик нык рәнҗеш чиктеләр.

Һәр кә у кәнәд кәр накәрдәни,
Галие бәйәдәш хурәд нахурдани.
(Ул кем итәр тиеш булмас эшләрне,
Гамьдән җияр[8], «җимәм» дигән эшләрен.)

Бу төрле эшләр падишаһ белән әңгәмәдәш булып утыру аркасында булды, диделәр. Ә падишаһларның рәхимле карашы бик сирәкләргә тия, диләр. Хак Тәгалә бер капканы япса, башка капкаларны ачар.

Рәхмәт төшсен кичерә белә торган кешегә, кем, кызып китеп, хатынына тиз үк талак бирмәс, чөнки талак үтәлүе мәҗбүри булмаган бер кагыйдәдер, мөмкин булганча аннан саклану кирәк.

Афәрин бу китапны язганга, күчереп язучысына, укучысына һәм тыңлаучыга булсын!

*Текстны басмага **Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль** әзерләде.* ■

[6] Чауш – офицер.
[7] Сәрһәң – полковник.
[8] Җияр – татыр, ашар.

«ТУКАЙ МОНДЫЙ ТҮГЕЛ ИДЕ...»

Ләлә Мортазина

Тукай дигән дөнья... Үтә киң, мәгънәле һәм мәңгелек. Тукай исемен атамаган, аны искә алмаган, шигырьләрен кабат-кабат хәтерендә яңартмаган татар кешесе сирәктер. Бүген безнең өчен Тукай үзе генә түгел, аның белән аралашкан, аны якыннан белгән, күрепишетеп калган кешеләр турындагы истәлекләр дә кадерле. Ә алар һаман табылып тора. Тукаебыз халык хәтерендә яшәвен дәвам итә.

Бишбалтада татар балаларына белем биргән, ярты гасыр гомерен милләтебезгә хезмәткә багышлаган атаклы педагог **Габдрахман Рафиков** гаиләсендә Г.Тукай белән бәйле якты бер хатирә кадерләп саклана. Габдрахман ага **Фатих Әмирхан** белән бик якыннан аралашкан, хезмәттәшлек иткән: бергәләп татар балалары өчен 3 кисәктән торган «Ана теле» дәреслеге язып бастырганнар. Ф.Әмирхан Бишбалтада бик еш булган, бертуган апасы **Сәгадәт** һәм җизнәсе **Габдулла Әмирхановларга**[1] кунакка килгәндә, Габдрахман Рафиков гаиләсенә дә керми китмәгән. Кайвакытларны хәтта икешәр-өчәр көнгә куна да кала торган булган (Габдрахманның улы елга капитаны Хәбибрахман язучыны үзләренә ат җигеп алып килә тор-

Габдрахман һәм Рабига Рафиковлар. 1913 ел

[1] Габдулла Әмирханов — Казанның Бишбалта бистәсе мулласы (1871-1933). Хатыны Сәгадәт Зариф кызы Әмирханова (1882-1911) Фатих Әмирханның бертуган апасы була. Мөгаллимә, «Әмирхания» кызлар мәктәбендә укытучы Сәгадәт ханым бик яшьли, 29 яшендә үлеп китә, Разия (1904-1968), Мәхмүт (1906-1975), Зәкәрия (1909-1985) исемле балалары кала.

Камалетдин Кантиев

ган булган, пароходта Уфа шәһәренә алып баруы да билгеле). Габдрахман ага үзе дә Габдулла хәзрәт йортында көтеп алынган кунак була. Чөнки шәхси дуслыктан тыш, аларны эшлекле мөнәсәбәтләр дә бәйли: Габдулла хәзрәт Рафиков мәктәбендә дин гыйлеме укыткан, Габдрахман ага исә Бишбалта мәдрәсәсендә рус теле буенча дәресләр биргән. Шулай итеп, алар, өч татар зыялысы, мәгариф, әдәбият, мәдәният мәсьәләләре, милләтебезнең киләчәге турында сөйләшеп утырырга бик яраткан. Билгеле булганча, Габдулла Тукай да дусты Фатих белән Бишбалтага килеп йөргән. Менә шундый очрашулар вакытында Габдрахман Рафиковның да Тукай белән күрешкән булуы бик мөмкин, дип саныйлар мөгаллимнең оныклары. Алар искә алганча, Рафиковлар йортында Тукай китаплары һәрвакыт иң түрдә, кадерле урында сакланган. Габдрахман ага Тукайны гел искә ала, шигырьләрен балаларына яттан сөйли торган булган.

***

Икенче истәлек. Алда искә алынган Габдулла Әмирхановның улы **Әнәс Әмирханов**[2] үзенең бер истәлегендә Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Тукай һәйкәленә бәйле балачак хатирәсен сөйли[3]. «Мин әни белән театр яныннан узып барганда әнием: «Бу кем соң?» — дип сорады. Мин: «Бу Габдулла Тукайга куелган һәйкәл», — дип җавап бирдем. Әни бик гаҗәпләнде: «Тукай мондый түгел иде бит», — диде. «Ә син аны кайдан беләсең?» — дип гаҗәпләнеп сорадым». Шуннан соң **Гайшә ханым** ничек итеп Габдулла Тукай белән күрешүе, аның Фатих Әмирхан белән бергәләп үзләренә кунакка килеп йөрүләре турында сөйли. Фатихның Габдулла янына ул яшәгән кунакханәгә барып йөрүен дә искә ала. Алар Фатих абый белән бергә Бишбалтага кунакка килгәндә әнисе ике дусны чәй белән сыйлый торган булган[4].

***

Өченче истәлек Тукайның Җаектагы чоры белән бәйле. **Габдрахманның улы Хәбибрахман Рафиковның** хатыны **Әсма ханым** чыгышы белән Җаек шәһәреннән була. Аның әтисе **Камалетдин Кантиев** (ул якларда аны «сәгатьче Камали» буларак яхшы белгәннәр) Тукай белән шулай ук тыгыз аралашып яшәгән. Алар күршеләр булып, шактый күп вакытларын бергә үткәргән. Мәдрәсә шәкертләре (Г.Тукай да алар арасында була) бик еш кына табигатькә чыгып ял итә, көймәдә йөзә торган булалар. Галим Рафик Нәфыйгов язуынча, Тукай «сәгатьче Камали»ның көймәсенә утырып Чаган елгасында ял итәргә яраткан, алар бергәләп балык тотканнар. Камали дусты аны Хан бакчасына алып барган. Биредә шагыйрь И.Крылов мәсәлләрен тәрҗемә иткән. ■

[2] Әнәс Габдулла улы Әмирханов (1923) — Татарстанда танылган профессиональ рәссам, Бөек Ватан сугышы ветераны, озак еллар «Татарстан яшьләре» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарында рәссам булып эшли. Габдулла хәзрәтнең Гайшә Йосыф кызы Мишкина (1888-1960) белән никахыннан туган.
[3] Кулъязма истәлек Г.Рафиковның оныгы Наилә Рафикованың шәхси архивында саклана.
[4] Фатих Әмирхан турында истәлекләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. — Б.107.

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Кәләпүш — мөселман икәнлекне белгертер өчен киелә торган мәҗүс каләнсәвәсе[59].

● Өстеңдә әйбәт кием булгач, синең бәрәңге генә ашаганыңны кем белә?

***

● Балалар — безнең бәхетемез вә сәгадәтемез... Балалар безнең гомер нигеземезне тазарталар, балалар хезмәт өчен безнең көчемезне арттыралар.

● Балалар якты дөньяга килгәндә, гадәтән, бер бәхетлелек диңгезе булып киләләр. Ләкин шул балаларны туган минутыннан алып балигъ булганга кадәр, ата-ана үзләренә бәхет вә башка инсаннарга да шатлык булырлык итеп тәрбия итүе бик читен, ай-һай, бик читен!

● Бала, ир бала, әйбәт кенә тәрбия ителсә, ата-ана өчен, гомернең куркынычлы һөҗүмнәре вакытында шул бала шул ата-анасын сакларга күкрәп, нәгърә орып чыккан бер арыслан буладыр.

● Кыз бала бик матур гына тәрбия ителсә, бөтен дөнья байлыкларына сатылмаслык егетләрне, картларны, хәтта хатыннар вә карчыкларны үзенә таба тартып тора торган... бер фәрештә буладыр. Аның бер сүзен ишетер өчен, бер генә йөзен күрер өчен меңнәрчә җаннар атылып кына торадыр. Ул үзе шикелле тагы әллә ничә фәрештә кызлар вә әллә ничә арыслан йөрәкле, гайрәтле егетләр тәрбия итә аладыр.

● (Балалары. — *З.М.*) аналарын карасыннар, тәрбия итсеннәр, чөнки оҗмах аналар аяк астында табыла.

● Күз яшең дә кипмичә, егълап вафат булган әни!.. Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереӊ ташы — шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

V

● Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән.

● Ушбу Җир булды бөтен мәсҗедләрнең дә мәсҗеде.

● Билгеле ки, дин кешеләрдән аерым түгел.

● Ислам бит — хак дин, ә хаклык, һичшиксез, гел өстен булыр.

● Дин димәк — бетмәс-төкәнмәс бер хәзинә ул.

● Кешеләр белән бергә диннәр дә изелделәр; мөселманнар — Исламны, христианнар Гайса динен ташлады.

● Милләт иблис күләгәсен Тәңре күләгәсе ясамас.

● Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора. Бу ике дуст берсенә, чөнки аларның берсе тиң, бертигез тәгълимнәре[60] дә: берсе — дөнья, берсе — дин.

Сүзлекчә:

[59] Мәҗүс каләнсәвәсе — мәҗүсиләр бүреге;

[60] Тәгълим — өйрәтү, укыту.

Редакциядән: Габдулла Тукайның «Ачы тәҗрибә авазы» журналның 2014 елгы 9 нчы санынан басылып килде. Ниһаять, ул З.Мансуровның «Тукай белән әңгәмәләр» китабында тулысынча дөнья күрде.

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Вафа Бәхтияров

Быел танылган педагог, дәреслекләр төзүче галим Вәли ага Хаҗиевка 105 яшь тулыр иде, аяныч ки, ул 2002 елда (96 яшендә) фани дөньядан мәңгелек йортка күчте. Урыны җәннәттә булсын! Тукайның якын дусларыннан берсе — Вафа Бәхтияровның[1] кайбер язмалары, ягъни архивының бер өлеше Вәли агада сакланган. Вәли аганың тол карчыгы Мәстәгыйдә апа шуларны миңа тапшырган иде. Мин аларны тамгасарга (компьютерга) керттем. «Тукай турында замандашлары» исемле китапта бу истәлекләрнең беркадәре басылды инде[2].

Истәлекләр ниндидер исәп-хисап башкарылган саргылт кәгазьнең чиста ягына гарәп хәрефләре белән төшерелгән. Язмаларда «1942», «1949», «1950» саннары күренә. Язылган еллары, ахры. Кайбер өзекләрне кемдер (бәлки Вафа ага үзедер?) кириллицага күчергән. Җәмгысы өч юка дәфтәр. Тукайга һәм аның замандашларына кагылышлы җирләрне «Безнең мирас» журналы укучылары игътибарына тәкъдим итәм.

Вафа Бәхтияровның язу өслүбе сакланды. Танылмаган сүзләр урынына күп нокта куелды. Бүлек исемнәре минем тарафтан билгеләнде. Кайбер язмаларга астөшермә рәвешендә аңлатма бирү кирәк табылды.

Рабит Батулла

ҖИЛГӘ КАРШЫ ТӨКЕРМӘ

Тукай, гаскәри эштән калып, Казанга килгәч, Казан яшьләре арасында Ишми ишан турында төрле сүзләр ишетә. Аның яңалыкка каршы икәнен аңлап, яңалыкның чын дошманы дип санап, үзенең «Бер манигы тәрәкъкыйгә» («Алгарышка бер киртә») дигән шигырен яза.

Батарсың дим — йөгермә Нилгә каршы,
Кире кайтыр — төкермә җилгә каршы.

---

[1] Вафа Гали улы Бәхтияров 1881 елда Сарытау губернасы Хвалын өязе Зимница авылында туа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. 1907-1909 елларда Казанда чыккан «Әл-ислах» газетасының рәсми мөхәррире булып тора (фактик мөхәррире, белгәнебезчә, Фатих Әмирхан). Шулвакытта Габдулла Тукай белән бик якыннан танышып китәләр. Вафаты — 1960 елда.

[2] Җыентыкка истәлекләр «сөзелеп», «дөресләп» кертелүенә карамастан (мәсәлән, «Тукай белән Фатих Әмирхан бик еш сүзгә килешәләр иде» дигән җөмләдә оригиналдагы «карта уйнаганда» дигән сүзләр «төшеп калган» һ.б.), без ул урыннарны яңадан кабатлап бастырмаска уйладык. Киләчәктә алар да автор вариантындагыча урын алыр бәлки. Шунысын да искәртү мөһим: «Тукай турында замандашлары» җыентыгын төзүчеләр истәлекләрдәге кайбер фактик төгәлсезлекләрне табып уза. Шуңа күрә, ихтимал, бу мәкаләдә дә хаталардан хали түгелдер. Хәтер ничек шаярмас! Кыскасы, ул-бу булса, тукайчылардан хәбәр көтәбез. — *Редакция.*

«Әл-ислах» редакциясе. Сулдан уңга: Вафа Бәхтияров, Кәбир Бәкер, Фатих Әмирхан, Ибраһим Әмирхан, Габдулла Тукай. 1907-1909 еллар

Батыр дип мактасалар — чикмә зәхмәт;
Көчек! Зинһар, дим, өрмә филгә каршы.

Бу шигырь бөтенләе белән алынмады.

Тукай Казанда берничә айлар торгач, тагын да шул ук Ишмигә карата «Кайда?» шигырен яза.

Кем дисез бу фетнәле эшләр башы?
Кайда бер хаксызга тәфтишләр[3] башы?

Кем җигә безгә тәдәнни[4] арбасын?
Кемгә ләгънәт әйтәсе һәм каргасы?

Бәдбәхет, мәлгунь кеше кем, дусларым?
Бер авылның чалмалы карт марҗасы!

Халык җырларын үзгәртеп, шул ук Түнтәр Ишмигә карата:

Кушмый ишан капкасы, нарат икән тактасы,
Нарат булмый нәрсә булсын, бар да донос акчасы.
Безнең урам — таш урам, ташу ага басудан,
Сакалына хөрмәт беткәч, милләт сата ачудан.

[3] Тәфтиш — тикшерү, ревизия.
[4] Тәдәнни — артка китү, антипрогресс.

Бер ишан хәзрәт симерттем, күркә тавык ашатып,
Сагынсам корсагын карыйм чүмәләгә охшатып, — дип язды.

НИКАХ

1907 елның ахыргы айларында Казанга Вакыйф Җәлал исемле бер егет килеп чыга. Бу матур егетнең «Бәянелхак» һәм «Нур» газеталарында берничә назымнарыбәетләре басылып чыкканлыктан, [ул] газета укучыларга билгеле кеше иде. Бу матур егет Казанга килеп чыккач, Казанда калу теләге белән Казан татар газеталарында эш, урын эзләп, эзләп тә табалмагач, Казан байлары, сәүдәгәрләре арасына кереп китә.

№ 25 ١٣٢٦ سنه ١٥ ربيع الاول پنجشنبه ١٩٠٨ سنه ٣ آپريل

ЕЖЕНЕДѢЛЬНАЯ ГАЗЕТА „ЭЛЬ-ИСЛАХЪ"

Адрес: Казань, Редакція газ. „ЭЛЬИСЛАХЪ"

«Әл-ислах» газетасының бер саны

Бу егет татар байлары арасында дин, диянәт, Коръән, хәдистән «фәлсәфә сата». Кыскасы, панисламист Муса Бигиевнең агенты урынын тота. Вакыйф Җәлал Казан татар байлары, сәүдәгәрләре арасында яхшы кеше булып китә. Байлар арасында зур галим, белем иясе булып таныла. Байлар арасында мәҗлестән мәҗлескә бер дә калмый йөри. Кара көчләр арасында тәмам ышаныч казана. Шулай итеп, Вакыйф Җәлалны Казан байлары өйләндерү фикеренә төшәләр һәм мәшһүр бай Апанаевларның зур җир-су, урманнарга, шәһәрдә зур таш йортларга хуҗа булган илле-алтмыш яшьлек, кечерәк буйлы, артка-алга бөкресе чыккан, зур башлы, кечкенә борынлы, зур корсаклы, кәкре-камыт аяклы Фатыйма бикә Апанаевага өйләндерәләр. Бөтен байлар шау килеп, зур итеп, бөтен Казан аякка баскан хәлдә туй итәләр. (Насыйри урамы, 42 нче йорт[та].) Бу вакыйганы ишетеп һәм берничә тапкыр Вакыйфны югарыда күрсәткән бикәсе белән урамда атта барганын күреп, Тукай түбәндәге шигырен яза («Әл-ислах» газетасына бирә, шигырь басылып та чыга).

Күңелләр саф чагында шәп, матур кыз сайлыйлар анлар:
«Булыр безнең хатын булса, йөзе айдай», — диләр анлар.

Әгәр дә басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса,
Убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

Шул чорда озын буйлы бер ирнең тәбәнәк бер хатын белән үбешеп торганын күрсәткән открытка бар иде. Открыткада мондый сүзләр язылган иде: «Весь мир обойдешь, такой пары не найдешь!»

Бу открытка — Вакыйф Җәлалның шәүкый Фатыйма Апанаевага өйләнүе мөнәсәбәте белән берәү тарафыннан ясатылган рәсем иде.

ТИЗ КАРТАЕРСЫҢ

1907-1908 елларда Тукай еш-еш кына түбәндәге шигырьне кычкырып укый торган иде.

بيان الحق

НОЧЬ ЛЮБВИ.

— МАДАМЪ ШЕРИ —

ПРЕСТУПНАЯ СЕМЬЯ АНАТОЛЯ

«Бәянелхак» газетасының бер саны

Бер бай углы, бер җегет,
Кайтты Истамбул җөреп;
Сарфы төркине ятлап;
Французча лыгырдап.

Мин бу шигырь ... Йосыф Акчурин турында булса кирәк, дип уйлый торган идем. ... Йосыф Акчурин мәдрәсәи «Мөхәммәдия»дә берничә ел төрекчә «Сарфы[5] төрки» дәресләре укытты. [Тукай] татар укучыларына Истамбул-төрек сарфы укытуга эче пошып, татарлар өчен кирәксез бер эш, дип уйлаган булса кирәк, дип йөри идем.

1909-1910 елларда, шул ук шигырьне үзгәртеп, «бер бай углы, бер җегет» урынына «бер шәһәрнең бер җегет» дип җырлый торган булды. Монысы инде Ибраһим Әмирхан, дип уйлана иде. Ибраһим Бәйрут, Истамбулда берничә ел «укып» кайтты. Мин берничә тапкыр бу [шигырь] турында Тукайдан сорасам да, [ул] миңа:

— Күпне белсәң, тиз картаерсың! — дип кенә җавап кайтара иде.

ПОЖАЛТЕ, ГОСПОДА!

Ялгышмасам, Думаның III җыелышында «Мөселман фракциясе» тарафыннан 80 пункттан торган «Русия мөселманнарының төп теләкләре» исемендә чыгыш ясала. Бу теләкне мөселман депутатларыннан берсе, ялгышмасам, Җантурин, Дума трибунасына чыгып укый. Бу чыгыш урыс карагруһчыларына бер дә ошамый. Думада карагруһчылар башлыгы Пуришкевич, Мартов, октябристлар партиясе башлыгы Гучков, трибунага чыгып ... башка ... милләтләрне бик каты итеп сүгәләр, төрле былчыраклар аталар. ... Пуришкевич:

— Урыс хөкүмәтенең төп законнарына буйсынмыйсыз икән, Төркия солтаны җиренә күчеп китәсез! Анда фәс киеп йөрерсез! — дип мөселман фракциясенең теләкләренә каршы сөйли[6].

Тукай шул карагруһчыларның чыгышларына җавап итеп, «Китмибез»дә:

[5] Сарыф — морфология.

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
— Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа! — дип язды.

ХАТЫН-КЫЗ

1908 елның урталарында Тукайның мәхәббәт-сөю турында берничә шигыре басылып чыга. Шул шигырьләре чыгу белән Казан хатын-кызлары тузга язмаган хәбәрләр тараталар. «Бу шигыре минем турыда, минем хакта. Ул мине сөя, ул минем белән таныш», — дип сөйләп йөрүләрен, шул турыда төрле гайбәтләр ишетеп, шагыйрь бик-бик әрни, күңелсезләнә, борчыла иде. (Кояш, ай, матур кыз, мәхәббәт, сөю, табигатьне сурәтләү — болар бары[сы] да бөтен дөнья шагыйрьләре өчен уртак темалар икәнен аңламыйлар шул.)

Тукай һичбер хатын-кыз белән күрешмәде, сөйләшеп утырышмады. Хатын-кыз булган җирдән кача торган иде. Кыш көннәрне, көн саен диярлек, кич белән Фатихларга барыла иде. Шагыйрьгә күп ярдәме тигән Фатихның анасы Рабига абыстай Тукайны сөйләштерергә тырыша иде. Тукай башын аска иеп, кызарынып, бүртенеп, җавап кайтармый утыра иде.

Безнең җәйге квартирабызга (шул заман яшьләренең штабы, дияргә ярый) ул вакыттагы укымышлырак хатын-кызлар вакыт үткәрү өчен, сөйләшеп утырыр өчен киләләр иде. Алар килсә, Тукай нишләргә белми аптырап йөри башлый, ачулана, төсен үзгәртә торган иде.

Бервакыт берничә хатын-кыз кунаклар килде. Залда без шау килеп чәй эчәбез. Тукай кечкенә бүлмәдә. Чәйгә чыгарга берничә тапкыр чакырылды. Чыкмады. Тукай бүлмәнең урамга карап торган тәрәзәсен ачып, тәрәзә аркылы урамга чыгып киткән. Ишектән чыкса, зал аркылы чыгарга туры килә. Залда хатын-кызлар бар, алар Тукайны күрәчәкләр. «Болай качарга, кыргый булып йөрергә ярамый!» — дип әйтсәң, Тукай:

— Хатын-кыз дигән халык матурлыкны, байларны, акчалыларны ярата. Боларның берсе дә миндә юк. Мин ике [генә үзгә төрле] хатын-кызны беләм, берсе — Пушкинның Татьянасы, икенчесе — мине алманча укыткан Мария Константиновна! — дия торган иде.

ЯРӘШҮ

1908 елның җәендә, Тукайны күңелсез, кызганыч тормыштан котылдыру теләге белән, якыннары арасында Тукайны өйләндерү фикере туа.

Безнең идарәгә килеп йөри торган, яхшы гына хозяйка булырлык, Тукайны кулга алырлык, күңелсез тормышыннан котылдырырлык Ф.Ибраһимова сайлана. Кызга да әйтелә. Кыз күнә. Фатих Әмирханның әнисе Рабига абыстай аркылы кызның анасына сүз салына. Кызның анасы да риза була. Хәзерге Насыйри урамы белән Сафьян урамы чатында Апанаевларның ... ике катлы агач йортының югарыгы катыннан фатир да билгеләнә. Бу эшкә Тукаебыз бер күнә, бер кире

---

[6] Габдулла Тукайның күптомлыгында мондый искәрмә бар (1985, 1 том, 365 бит): Дәүләт Думасының 1907 ел маенда булган унбишенче мәҗлесендә, мәсәлән, Уфа губернасыннан сайланып килгән депутат, мөгаллим Кәлимулла Хәсәнов (1878-1949) мөселман мәктәпләренең хәле начарлыгыннан, хөкүмәтнең моңа бер чара да күрмәвеннән зарланып сөйли, суллар кул чабалар, ә уңнар (Пуришкевич, Сазонович һ.б. карагруһлар) урыннарыннан сикереп торып, йодрыкларын төйнәп, ораторга ташланалар һәм «Төркиягә китегез!» дип кычкыралар.

кага, тәмам аптырый, шаша, төрле хыялларга чума. Аннан бу эш барып чыкмый кала. Фатихның «Габделбасыйр гыйшкы» дигән хикәячеге шул турыда язылды.

БЕР РӘСЕМГӘ

Фатихның бүлмәсендә, өстәл өстендә бик матур бер рамкада гимназистский формада, яланбаш, озын калын чәчен икегә үреп, алга салып җибәргән, бик матур, һәркем сокланырлык яшь бер кызның рәсеме куелган. Бу рәсем Фатихның атасы белән бертуган Мәрьям Аппакованың икенче кызы — Гөлсем Аппакованың рәсеме иде. Гөлсем Аппакова көндезен гимназиядә, кичен музыкальный школада укучы яшь бер кыз иде. Тукай Фатихка барган саен шул матур кызның рәсеменә күз сала торган иде. Кайчакта рамканы кулына алып, бик озак карап торган чаклары да булгалый иде. Бу матур, тырыш кыз укуын да бетерми, яшьли үлеп китте.

Тукайның «Бер рәсемгә» дигән шигыре югарыда күрсәтелгән рәсемгә аталган иде.

Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә, кашына;
Мең вә мильюн афәрин бу сурәтнең нәкъкашына.

Бу озын сачны каян алган икән соң бу кояш?
Күр Ходайның кодрәтене, — бер күзең сал башына.

И Кояш! ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.

Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә.

ҮЛМӘСБАНУ

1908 елның җәендә мәшһүр фабрикант Акчуриннарның берсенең аерган хатыны Үлмәсбану Казанга килә. Бу хатын безнең җәйге фатирыбызга бик еш килә башлый. Бу хатын бераз әдәбият белән таныш, азмы-күпме укыган. Шул заманның аңлы хатыннарының берсе, дияргә ярый. Бу хатын Тукай турында сораша. Аның белән танышу турында сөйли. Шагыйрьне төрле яктан белергә тырыша. Аны кызганып сөйли. Шагыйрьне кызганып, котылдыру юлларын күрсәтә. Көнбатыш әдәбияты белән дә танышу тиешлеген аңлатырга тырыша. Алман телен белү шагыйрьгә бурыч, дип куя. Тукай Көнбатыш телләреннән берсен укырга теләсә, ярдәм итәчәген белдерә. Боларның барысы да Фатих аркылы сөйләнә. Чөнки Тукай бу хатын белән таныш түгел иде. Тукай алман телен укырга күнә. Каршыбызда гына торучы бер алман хатынынннан укый башлый. Бу Үлмәсбану ханым, яхшырак фатир алып, Казанда калу уен да сөйли. Тукай бу эшләрнең кая таба барганын сизеп ала да, укуын ташлый. Үлмәсбануның корган планы барып чыкмый. Фатихның «Хәят» хикәясендәге героиняны әнә шул Үлмәсбану дип белергә кирәк.

Шагыйрь ... хатыны исемен алу өчен Казанның йорт-җир хуҗасы булган берничә бай тол хатын Тукайга гыйшык тотып йөрде.

«Болгар» швейцары аркылы өстенә камыр белән «Тукайга» яки «Шагыйрьгә» дип язылган мәхәббәт бәлешләре дә бирелгән чаклар булгалады.

Дәвамы бар

Язмаларны ***Рабит Батулла*** *әзерләде.* ■

ҮЗ ХАЛКЫНЫҢ БАЛАСЫ ИДЕ...

Тәлгат Галиуллин

Яшерен-батырын түгел, XX йөз башы татар матбагасын, Тукай, Бабич, Дәрдемәнднең иҗатларын өйрәнгәндә, Зариф Бәшири исемен очратып, аның милләт язмышы, телебез өчен борчылып язылган «Сакла телеңне», «Телем» шикелле назымнарына юлыгып, самимилегенә игътибар итсәм дә, аны, үзенчәлекле язучы буларак, «Чуаш кызы Әнисә» бәяны буенча гына белә, таный идем.

Татар егете белән чуаш кызы арасындагы романтик мәхәббәтне реалистик күзәтүләр, тирән психологик нюанслар белән сәнгатьчә югары кимәлдә сурәтләгән әсәрнең абруе үсүгә янә бер вакыйга этәргеч бирде. Күренекле чуаш шагыйре Валерий Тургай әлеге әсәрне үзләрендә ике телдә бастырып, Халыклар дуслыгы йортында китапны тәкъдим итү кичәсен уздырды. Чабаксардан килгән чыгыш ясаучылар татар кешесе тарафыннан чуаш кызының матурлыгын, рухи күркәмлеген, кардәш халыкның холкын, эш сөюен, дуслыкка тугрылыгын яратып, белеп сурәтләвенә шаклар катып, татар әдипләренең киң күңелле булуына басым ясап, әсәрне

Сулдан уңга: Нәҗип Думави, Зариф Бәшири, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй, Мәҗит Гафури. 1916 ел. Әлеге фотосурәткә төшү мәрәкәсе турында Зариф Бәширинең «Сайланма әсәрләр» китабыннан укый аласыз

Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» белән янәшә куеп сөйләгән иде. Милләтләренә татар агае биргән бәя ничек күңелләрен эретмәсен ди: *«Чуашлар алар, тормышлары әшәке булса да, эчләре, намуслары белән пакь халык. Алар урламый, хыянәт итми, ялган сөйләшми, теләнчелек кылмыйлар»* (317 бит).

Бәянның фабула канвасына килсәк, ике милләт баласы арасындагы мәхәббәт хисе нинди генә дәртле булмасын, аның ахыры фаҗига белән бетәсе сиземләнә.

Татарстан китап нәшрияты 2014 ел ахырында бастырып чыгарган Зариф Бәширинең «Сайланма әсәрләр»е әдип турында тулырак мәгълүмат бирә. Язучының туганы, якташы Ркаил Зәйдулланың «Бәхетсез почмак әсире» дип аталган кереш мәкаләсе белән ачылган, үз эченә әдипнең замандашлары турында истәлекләрен, публицистик язмаларын һәм, әлбәттә инде, «Чуаш кызы Әнисә» бәянын туплаган мәҗмуга, әдип иҗаты, аның дөнья картинасын күрү, сурәтле фикерләү үзенчәлекләре белән якыннанрак таныштыра.

Форсаттан файдаланып, шуны да искәртеп үтү мөһим: чуаш халкы белән чиктәш авылларда туып-үскән Ф.Бурнаш, Ш.Мөдәррис, К.Латыйп, Р.Харис, Н.Каштан, Җ.Сөләйман, Р.Зәйдулла кебек төрле буын татар әдипләре күршеләр мәдәнияте белән кызыксынып, «тел-лөгать алмашып» яшәде һәм яши. Билгеле, бу исемлекнең башында З.Бәшири тора. 2014 елда «Безнең мирас» журналы тәкъдим иткән «Мишәрләр» исемле язмаларында да З.Бәшири ике милләт арасындагы җылы мөнәсәбәтләр турында кабат-кабат яза: *«Мишәрләр вә чуашларның бу көнгә кадәрле сакланган урыннары да Рәсәйнең шималь тарафындадыр... Мишәрләрнең татарларга караганда чуашларга булган мөнәсәбәтләре, кирәк тормышта вә кирәк гадәттә булсын, бик якындыр»* (277 бит).

Язучы мишәр кавеменә хас гореф-гадәтләргә, яшәү рәвешләренә киң тукталып, аларның сату-алуга маһирлыгына, гаиләдә күп бала үстерүгә омтылуларына, эш сөючәнлекләренә, диндарлыкларына югары бәя бирә: *«Мин берничә шәһәрдә күтәреп сәүдә итеп йөрүче мишәрләрнең арып-талып кайту өстенә һәр кичне уку белән булашуларын күреп гаҗәпләнә идем. Фәкать боларның укый торган китаплары Али батыр (хәзрәти Гали), Камыр батыр, Чилбәр батырның җиде башлы диюләр белән сугышкан, Әбүгалисина хәлен тасвир иткән кыйссалардан узмаганга», «хыялый» мишәрләр арасында гакылдан язган кешеләр бик күб очрый»* (286 бит).

Кан вә дин кардәшләрен чеметкәләп узса да, иҗатында үзе дә «моннан берничә мең еллар элек булган хәлләргә» тартылып тора ул. Җыентыкта урын алган, кытай халык риваятьләренә таянып язылган «Ефәк корты» кыйссасында, сергә ия кешеләрнең башларын кисеп, сөңгегә утыртып куюлар да, урман могҗизалары да тулып ята. Әдип ефәк тукымасының табылу, тыелу, таралу тарихын, аның могҗизасын ачкан Сунның, Сун улы Ши-кайның фаҗигасен, патшаларның рәхимсезлеген, акылның иң явыз хакимнәрдән дә өстенлеген мавыктыргыч сюжет канвасына салып сурәтли. З.Бәширинең мәҗмугага кермәгән «Ефәк күлмәк», «Кара тараканнар», «Шаян Фәһим», «Каракош явы» хикәя-бәяннарында да хыялый, хәтта авантюр гонсырлар шактый урын алган.

Туган кавеменә хас уку, эшләү, яшәү урыннарын алыштырып торуга хирыслык З.Бәширидә дә бар. Атаклы Шәкүр каракны биргән Чүти авылында атасыннан башлангыч белем алган үсмер Буа, Акъегет, Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем эстәгәннән соң, Оренбургта чыга торган «Чүкеч» сатирик журналында эшли, Пенза һәм Тамбов төбәкләрендә балалар укыта, аннары Үзәк Азия якларына

чыгып китә, Алматы, Җаркәнт, Ташкент һ.б. шәһәрләрдәге мәгариф оешмаларында, газета-журналларда төрле вазифалар башкара, Урта Азия дәүләт университеты каршындагы рабфакта уйгыр, үзбәк телләре һәм әдәбиятларын укыта. Үзе аралашкан халыкларның телләрен яхшы үзләштерүе «Чуаш әдәбияты» (1928), «Үзбәк әдәбияты» (1930), «Уйгыр әдәбияты» (1930) кебек җыентык-хрестоматияләр төзеп, аңлатмалар язып, бастырып чыгарырга мөмкинлек бирә.

1930 елда ул, М.Крыймов, Ә.Еники, Ш.Маннурлар шикелле, шул чорда эшчеләр сыйныфының үзәге саналган Донбасска юл тота һәм татарча нәшер ителгән «Пролетар» газетасында әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара. Әйтергә кирәк, З.Бәшири кайда гына яшәвенә, кем булып кына эшләвенә карамастан, тәнкыйтьчеләрнең һөҗүменә игътибар итмичә, ашыгыбрак язуда гаепләүләренә үпкәләмичә, шигырьләр «коюын», проза әсәрләре язуын дәвам итә. Киләчәге турында кайгыртып, Советлар сәясәтенә тугрылыгын күрсәтергә теләп булса кирәк, коммунистларның кычкыртып талавына түзә алмыйча баш күтәргән сәнәкчеләр хәрәкәте (узган гасырның егерменче еллары) турында «Каракош явы» исемле повесть та яза. Мәгәр «кызыл» шигырьләр дә, фетнәчеләрне «фаш итү» дә «үткен күзләрдән» коткарып кала алмый.

1938 елда аны кулга алып, бер гаепсезгә хөкем итәләр, биш елга хезмәт белән төзәтү лагерена озаталар. Җәза мөддәтен тутырганнан соң да, шәхес культы фаш ителеп, илдә ярым-йорты демократик тәртипләр урнашканчы, аңа мөнәсәбәт бер кәррә дә үзгәрми, ул әдәби-иҗтимагый хәрәкәттән читләштерелә, әсәрләре бастырылмый.

Үзе 1933 елдан Уфада яшәсә дә, ярдәм Татарстаннан килә. «Вак буржуа» яисә «мещан калдыклары» рәтендә йөртелгән байтак татар зыялыларының исемнәрен, әсәрләрен укучыга кайтарган кыю шәхес — профессор Мөхәммәт Гайнуллин 1958 елда (З.Бәшири 1962 елда вафат була), үзе кереш сүз язып, З.Бәширинең «Сайланма әсәрләр»ен бастырып чыгара. Мәкаләсен тулыландырып, «Татар әдипләре» (1978) китабына да кертә.

Озак еллар дәвамында исеме, әсәрләре искә алынмаган З.Бәшири иҗаты хәзер «икенче туу» чорын кичерә. 110 еллыгы уңае белән галим З.Рәмиев «Тукайлар замандашы», шагыйрь Р.Зәйдулла «Үткәнне белгән — бүгенгене биләгән» мәкаләләрен укучыга ирештерде. Шул чордан алып, үткәнебезгә, мәдәният маякларына игътибарлы Р.Зәйдулла З.Бәширинең тормыш юлын, иҗатын барлый, тикшерә башлый. Җыйнак кына кереш мәкаләсендә дә әдипнең башкалар игътибар итмәгән, кабатланмас үзенчәлекләрен үзәккә ала…

Әйтергә кирәк, З.Бәширине туган якларында, бигрәк тә Чүти авылында, беркайчан да онытмадылар. Йөзьеллыгын да район күләмендә зурлап билгеләгәннәр иде. Аннан соң да язучыга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр даими уздырыла килде. Әле 2014 елның ахырында гына Кайбычта «Зариф Бәшири эзләре буйлап» дип аталган семинар булды. Анда Башкортстан белән Чуашстаннан килгән татар теле, әдәбияты укытучылары катнашты. Кайбыч районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин үз чыгышында якташ язучысының бай иҗатын халыкка кайтару, бу эшнең әһәмияте турында сөйләде. «З.Бәшири бөтен төрки дөньяда зур урын тоткан язучы», — диде ул.

Ркаил Зәйдулла китапны, ничек кенә популяр булмасын, «Чуаш кызы Әнисә» бәяны белән башлап җибәрмәгән. Иң әүвәл итеп «Замандашларым белән очрашулар»ны урнаштырган ул. Чыннан да, бу әсәрне егерменче гасыр башындагы татар әдәби мохитен эчтән ачып биргән бердәнбер роман-хроника дип атасаң да мөмкиндер. Язучыларның,

гомумән, зыялы шәхесләрнең эшенә бәя биргәндә, «ул халкына нинди файдалы гамәлләр кылган, нинди мирас калдырган?» дигән сорау тууы табигый. Әсәрләр авторның үзе яшәгән чор истәлеге булып кына калмаганнармы, хәзерге яшәешебезгә рухи якынмы? Бу сорауларга төпле җавапны без «Замандашларыбыз белән очрашулар»да таба алабыз. Истәлекләрне укыганда аның авторы бай рухи дөньялы, төпле дини вә дөньяви белемле, үзенә һәм каләмдәшләренә төгәл, камил бәя бирә алган, җитлеккән, тормышның ачысын-төчесен татыган шәхес буларак күзаллана. Фикер хөрлеге ташып тору өстенә, һәр телгә алынган «тамашада катнашучыга» үз сүзен «әйтүгә ирек» бирү төгәллеге сокландыра. Җөмләдән, совет чорында «мәдрәсәләрдә шәкертләр гомерләрен заяга уздырып, әл-пи-тисидән ерак китә алмаганнар» дигән уйдырманы кире кагып, З.Бәшири «иң кадими фикерле мәдрәсәләрдә дә гарәп, фарсы, төрек телләрен белеп, дөньяви фәннәрдән дә хәбәрдар булып чыкканнар», дигән фикер уздыра. Ул барлык уку йортларын да бер рәткә куймый. Буа мәдрәсәсен тәнкыйтьләсә, Акъегет мәдрәсәсендә «пакь, таза, бөтен җирләре балавыздай итеп юылган һәм кара парталары тезелеп киткән бүлмәләрдә» утырган унбер-унике яшьлек шәкертләрнең белеме аны таң калдыра: «балалар географиядән сөйләгән чагында, барлык җир йөзе синең күз алдыңда уч өстенә төшерелгәндәй җанлана. Алар сине әле Пекинга, әле Парижга, әле Истанбулга илтеп кертәләр» (28 бит). Акъегет мәктәбе аның киләчәген билгеләүдә хәлиткеч әһәмияткә ия була: ул *«минем аңымны, дөньяга, тормышка булган карашымны киңәйтте... Әдәбият мәйданына кертеп, матбугат хезмәтчесе ясады»*, — ди автор.

«Замандашларым...»ның тагын бер мөһим үзенчәлеге шунда ки, автор төрле очрашуларда күргән, якыннан аралашкан К.Мотыйгый, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Дәрдеменд, Н.Думави, Ш.Камал, Г.Камал, Һ.Максуди, Г.Ибраһимов һ.б. олуг затларыбызны, хискә бирелеп, мактап, сокланып кына калмый, күбесенең холкын, иҗат үзенчәлеген ачарга, аңларга омтыла. Бу юлда бик уңышлы күзәтүләргә юлыгабыз. Менә берничә мисал. *«Фатих Әмирхан Казанның алдынгырак яшьләре, бигрәк тә укучылар арасындагы булган хәлләрне, вакыйгаларны вак-төягенә чаклы белеп, күзәтеп бара иде. Ләкин ул, гадәттә, чиксез дәрәҗәдә ачы телле, турыдан-туры суктыра торган кискен табигатьле бер кеше булуына да карамастан, беркемнең дә начар, килешсез якларын битенә бәрми, бу эш ярамый, дип үгет-нәсыйхәт тә бирми иде»* (60 бит). Замандашларына сәяси бәяләр биргәндә дә, З.Бәшири төгәл атамалар белән эш итә. *«Мәҗит Гафури белән Гаяз Исхакый арасындагы эчке каршылыкны мин шунда күрәм: Исхакый, эсерлыгыннан ваз кичеп, милләтчегә әверелсә, Гафури, киресенчә, милләтчелектән сыйнфый көрәш тәгълиматына күчеп бара иде»* (229 бит). З.Бәшири Исхакый исеменнән һәртөрле ярлыклар алынып, әсәрләре халыкка кайтканчы яшәмәсә дә, әдипнең татардагы төрле шивәләрне берләштергән *«әдәби тел булырга тиеш. Ә аны сабыйларның аңына мәктәп-мәдрәсәләрнең сеңдерүе зарур»*, — дигән фикерен җөпләп, теләктәшлек белдереп китерә. Шул ук вакытта, ул-бу булмасын, аңардан ераграк торсаң, исәнрәк булырсың дигәндәй, Исхакыйга шикләнебрәк карау да сизелә. Уфа бае Габдулла Госманов өендә уздырылган әдәби очрашудан соң, «Мәҗит агай, яңадан килегез! — дип кычкырды кемдер. Гаяз Исхакыйга алай кычкыручы булмады», — дип язуы аңлатма таләп итми.

З.Бәширинең М.Гафури иҗатына «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясен (1902), тәүге шигырьләрен укудан алган җылы мөнәсәбәте гомере буена саклана, ул остазының

иң тугрылыклы мөриде булып кала: *«байтак вакытка чаклы миндә татар дөньясында Мәҗит Гафуридан да югары торган бер әдип юктыр, дигән караш дәвам итеп килде»* (41 бит).

Татар шигърияте күгендә Тукай йолдызлыгы кабынгач та, аның бөеклеген, Ф.Әмирхан прозасының сәнгати яңалыгын таныгач та, М.Гафурига яшьлегендә кабынган хисси табынудан туктамый ул. З.Бәширинең яшәү урыны итеп Уфаны сайлавында (ул вакытта «Кара йөзләр» авторы исән-имин әле) остазына якынрак булу теләге дә үз ролен уйнагандыр. Усал телле, туры Тукай, серле ут кебек, үзенә тарта да, куркыта да. М.Гафури З.Бәширинең эзләнүләрен хуплап, үсендереп, аның да үзе шикелле, инкыйлаб хыялларына мөкиббән китеп яшәвен тели. Бергә төшкән рәсем артына өлкән каләмдәшенең: *«Бөтен дөнья эшче халкы белән / Алга барыйк — син һәм мин бергә»*, — дип язган сүзләре шуны расласа кирәк.

XX съездан соң иҗтимагый тормышның җанлануы, бәрәкәтле тәэсире З.Бәширигә дә өстәмә дәрт, дәрман бирә. Ул җиң сызганып хатирәләр дөньясына чума һәм үз чорының мәдәни-әдәби үсешен энциклопедик югарылыкта, саф әдәби тел белән сурәтләп бирә. Кызганыч, 700 биттән торган хатирәләрнең күп өлеше югалуга дучар була.

З.Бәширинең укучыга тәкъдим ителгән «Сайланма әсәрләр»е әдип мирасының бер өлешен генә эченә ала. «Әдипләребез» (2009) белешмәлегендә язылганча, автор үзе исән чакта ук тезмә әсәрләрен «Уйларым», «Гөлләрем», «Көннәрем» дигән исемнәр биреп, өч томга бүлеп әзерләп калдыра. «Авылларда давыллар» дигән күләмле шигъри бәяны, «Аумакайлыкта, яки Көннәр өстендә» романы һәм башка әсәрләренең кулъязмалары Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының мирасханәсендә саклана. Мирасының бер өлеше Уфада да калгандыр әле.

Язучының иҗатына моңарчы булган илтифатсызлыкның күзгә бәрелеп торган берничә сәбәбе бар. Беренчесе: дини, укымышлы нәселдән чыккан, үзе дә аң-белемгә ия бер генә шәхес тә совет чорында эзәрлекләүдән читтә калмаган. Мулла малае, алдынгы мәдрәсәләр узган З.Бәшири генә искәрмә була алмый. Икенчесе: татар мәдәнияте тарихына «алтын чор» дип кереп калган XX йөз башы әдәбияты олы талантларга гаҗәеп бай. Шуңа күрә икенче, өченче рәттәге язучыларның исемнәре, әсәрләре күләгәдәрәк калуы да табигый.

Документаль нигездә әсәр язуга алынган кешенең уйланулары аның үзе өчен генә түгел, ә җәмгыять вә киләчәк буыннар өчен дә кызыклы булырга тиеш. Укучыга тәкъдим ителгән әсәрләреннән күренгәнчә, З.Бәшири — туган халкының рухи дөньясын, теләк-ниятләрен тирәнтен аңлап, шулар белән дәртләнеп яшәгән шәхес. Иҗатында чагылган бай тормыш тәҗрибәсе, халкына мәхәббәте, киң күңеллеге Зариф Бәширинең бөтен мирасына якты нур сирпеп тора. ■



ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

«БОРҺАНЕ ТӘРӘККЪКЫЙ», 1906 елның маеннан 1911 елның февраленә кадәр Баку шәһәрендә Мостафа Исмәгыйлов-Ширванский наширлегендә, мөхәррирлегендә татар һәм гомумтөрки телләрдә чыккан («чуар мәсләкле», Р.Гайнанов) газета. Тукайның Уральскида яшәгәндә үк аның белән танышып барганлыгы күренә. Мәсәлән, «Фикер» газетасы битләренә төрле хәбәрләрне бергә туплап урнаштырганда, Тукай әлеге «могтәбәр газета»да «Сәхибҗамал Гали Халиева» имзасы белән «гаять мәгънәле вә файдалы бер мәктүп дәреҗ ителгән»леген яза. «Фикер» газетасына каршы кайбер Җаек кешеләренең хәрәкәтләрен яктырткан татар газеталары арасында «Борһане тәрәккъкый»не дә атый. Аларда «гаять кешелеклелек, кардәшлек хисләре тулы сүзләр» булуын билгеләп үтә. Бу газета Тукайның «Мөхәрриргә», «Авыл хатынының бала тибрәткәндә өмитләре» шигырьләрен күчереп тә баскан. Бераз соңрак исә Тукайның газетага карата публицистик чыгышларында тәнкыйди фикерләр дә әйтелә. Шагыйрь «Борһане тәрәккъкый» белән шулай ук Әстерханда басылган «Идел» газетасы арасында килеп чыккан каршылыкларны өнәми, аларны әтәчләргә тиңли: «Приёмныйның ишекләре тар ләхеттән тар икән; / Әстерханда ике әтәч — «Борһан», «Идел» бар икән» («Авыл җырлары»). Бу ике юллык 1911 елда «Ялт-йолт» журналында карикатура (ике әтәч сугыша) асты булып китерелгән, әмма автор шул елда чыккан «Яшен ташлары» җыентыгына (анда бөтен «Авыл җырлары» да урнаштырылган була) әлеге ике юлны кертми. «Идел» газетасында хәреф җыючы булып эшләгән Г.Утабалиев истәлегендә (Тукай Әстерханга килгәч) «Борһане тәрәккъкый»да С.Рәмиев белән Тукайга карата карикатура урнаштырылуы әйтелә. Бу уңайдан Тукай «Мостафа» исемле шигырь дә яза, ләкин иртәгәсен аның наборын үзе үк тараттыра (шулай да, соңыннан — 1912 елда шигырь, беркадәр үзгәртелеп, «Һазиһи касидәтен фи мәдхи Мостафа» исеме белән дөньяга чыга). «Йолдыз» газетасында (12 июль, 1907 ел) басылган «Аңлашу» исемле язмасында Тукай «Борһане тәрәккъкый»дә бер дә кирәкмәгәнгә урын алган бәгъзе шигырьләргә эчем пошадыр» диеп, моның «Мөтәшагыйрьгә» әсәрен язуга сәбәпче булу ихтималын әйтә.

Зөфәр Рәмиев

Әдәбият:

Габдулла Тукай Әстерханда // Тукай турындагы хатирәләр. К., 1976. — Б.117-118 (Г.Утабалиев истәлегеннән);
Нуруллин И. Габдулла Тукай. К., 1979. — Б.235.

ТАТАР ТҮБӘТӘЙЛӘРЕ

(ТР Милли музее фондларыннан)

Татар түбәтәенең төп ике төре билгеле: ярымшар формасындагы такыя һәм кисек конус формасындагы кәләпүш. Н.И.Воробьёв фикеренчә, ярымшарсыман такыя чын татар түбәтәе саналган. Ул урта гасыр сугышчыларының шлем астыннан кия торган баш киеменнән барлыкка килгән булырга мөмкин. Түбәтәйне тегү өчен бәрхет һәм вельвет материал кулланылган. Купшы түбәтәйләрне ефәктән һәм парчадан, гадәттә бер тонда, карасу тукымадан теккәннәр. XIX йөз уртасыннан төрле төсләрдәге тукымалар файдалана башлаганнар. Чигүдә үсемлек орнаментлары кулланалар.

Руфия Мөхетдинова *әзерләде.* ■

КЕМНӘР ИДЕК, КЕМНӘР БУЛДЫК...

(Бер сәфәр хатирәсе)

Ләбиб Лерон

Узган гасырның сиксәненче еллары ахырында без – бер төркем иҗат әһелләре – республикабыз буйлап сәфәрдә булып кайттык. Барыбыз да яшьләр – исемнәре халык теленә керә башлаган каләм ияләре, композиторлар, җырчылар, музыкантлар...

Юлдашларымның тәгаен кемнәр булганын яхшы хәтерләсәм дә, дөресен әйткәндә, әлеге сәфәрнең төгәл вакытын, аның нинди максат белән оештырылуын оныткан идем инде. «Казан утлары» журналының элекке саннарын (1987 ел төпләмәсен) актарып, караштырып утырганда, шушы юлларга юлыктым: *«9-13 мартта Әлмәт, Түбән Кама, Алабуга, Брежнев (Чаллы) шәһәрләрендә Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр булып узды. Бу кичәләр ВЛКСМ өлкә комитеты һәм ТАССР Композиторлар союзы тарафыннан оештырылган иде. Анда яшь шагыйрьләр Р.Зәйдуллин, Л.Лерон, яшь композиторлар Р.Еникеева, М.Шәмсетдинова, Р.Кәлимуллин, Ф.Шәрифуллин һәм яшь башкаручылар катнашты».*

Сүз уңаеннан, ошбу кыска хәбәрдәге («Казан утлары», №6, 1987 ел, 188 бит) «һәм башкалар»ның кемнәр булуын да ачыклап үтик: җырчы Зөфәр Хәйретдинов, флейтачы Дима Антонов, скрипкачы Әдилә Ибушева (ул чакта фамилиясе башкача иде). Ни кызганыч, ул сәфәребездән бер генә фотосурәт тә юк. Хәтерне яңартып торырга бер сәбәп булыр иде кана.

Кемнәр идек, кемнәр булдык, дигәндәй... Кайберләребез хакында берничә җөмлә.

Кайчандыр республикабыз мәктәпләрен, уку йортларын, тамаша залларын дер селкетеп шигырьләр укыган **Ркаил Зәйдулла**ны кем генә белми икән?! Бүген ул — күренекле шагыйрь, драматург, публицист һәм прозаик. Г.Тукай һәм М.Җәлил исемендәге мәртәбәле бүләкләр иясе. Пьесалары, спектакльгә әверелеп, Казан, Оренбург сәхнәләрендә бара, тезмә һәм чәчмә

1906 елда архитектор Фердинанд Амлонг проекты буенча төзелгән бинада (Лобачевский урамы, 10) бүгенге көндә Татарстан Композиторлар берлеге урнашкан

Ркаил Зәйдулла

Мәсгудә Шәмсетдинова

әсәрләрдән торган китаплары бер-бер артлы дөнья күрә, шөкер.

Бүген Татарстан Композиторлар берлеген җитәкләгән (1989 елдан башлап) **Рәшит Кәлимуллин** ул чакта Казан консерваториясендә эшли иде. Без сәфәрдә йөреп кайткан елда Р.Кәлимуллин «Габдулла Тукай истәлегенә» исемле Өченче кыллы квартеты өчен К.М.Вебер исемендәге Халыкара конкурсның (Дрезден) беренче премиясенә лаек булды. «Болгарлар» симфония-поэмасы, «Ерактагы кәккүк авазы» рок-операсы (И.Юзеев әсәрләре буенча) һәм башка бихисап музыкаль цикллар авторы. Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Россия композиторлар берлегенең Д.Шостакович исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты («Тукай моңы», «Казан турында кыйсса» (Х.Туфан шигырьләре буенча), «Урман авазлары» дигән симфоник әсәрләре өчен, 2007). Россия композиторлар берлеге рәисе урынбасары (2010 елдан бирле). Әсәрләре Европа илләрендә, АКШта, Японидә, Кытайда, Израильдә һәм Россиянең бик күп төбәкләрендә яңгырый.

Мәсгудә Шәмсетдинова ул вакытта телевидениедә музыкаль редактор булып эшли иде. Шул елда (1987)

Рәшит Кәлимуллин Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе алган көн. 26 апрель, 2007 ел

Дмитрий Антонов

Мәсгудә «Тукай әкиятләре» дигән симфоник сюита язды. Аңарчы мәшһүр шагыйребез әкиятләренә нигезләнеп «Кәҗә белән Сарык» дигән оперетта (1980) иҗат иткән иде. М.Шәмсетдиновага 1989 елда «Мәһди» рок-фольк-сюитасы зур танылу китерде. Ул — «Дастан» (1990), «Ибне Фадлан» (2001), «Чыңгызхан» (2004) симфонияләре, «Дәрвиш» (2005) симфоник поэма, «Адәм балалары» (1993) һәм «Фатыйма белән Сандугач» (2001) кантанталары, «Көмеш кашык болытта» балеты, «Авылдагы бала чагым» сюитасы, «Җир уллары» ораториясе, хор өчен «Зоопарк» циклы (Ш.Галиев шигырьләре нигезендә), шулай ук күп кенә спектакльләрнең («Итил суы ака торур...» (Н.Фәттах), «Апушның тылсымлы төше» (Р.Бохараев) көй авторы. Философия фәннәре кандидаты (диссертациясенең исеме — «Урта Идел буе мөселманнарында мәүлид бәйрәме», 2001). Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Бүгенге көндә (2002 елдан бирле) Американың Сиэтл шәһәрендә яши.

Флейтачы **Дима Антонов** (Дмитрий Константинович Антонов,1946-2007) — керәшен егете. Флейтада оста уйный иде. Виртуоз. Соңыннан танылган педагог-профессор булды, бик күп шәкерт тәрбияләде. Татартсанның атказанган артисты (1992). 2007 елның 23 июлендә фаҗигале төстә вафат булды.

Зөфәр Хәйретдинов — җырчы, композитор. Сәфәребез вакытында иң күп алкышлар аңа булды. Көен ул язган бик күп җыр халык арасында популярлык казанды. Биредә шулардан «Кайда син, гармун» (Х.Әюп шигыре), «Мишәр кызы» (М.Шиһапов), «Ай, җаный, вай, җаный» (халык сүзләре), «Буйдаклар» (Д.Гыйсметдин), «Миләшләрем» (М.Шакиров), «Актанышым-мактанычым»

Зөфәр Хәйретдинов

(Л.Лерон), «Карлы яңгыр» (Н.Камал), «Мәхәббәтнең соңгы төне» (Г.Сабирова) җырларын искә төшерү дә җитә. З.Хәйретдинов — Татарстанның халык артисты, Россия авторлар хокукы җәмгыятенең Татарстан филиалы җитәкчесе.

...Әлеге сәфәребездән соң егерме сигез ел вакыт бер мизгел кебек узган да киткән. Хәтер хатирәләрне яңарта...

Кемнәр бар да, кемнәр юк... Исәннәргә — яшәргә дә яшәргә әле... ■

КОЯШЛЫ РӘССАМ

Дания Гайнетдинова

Кеше гомере – диңгездәге бер тамчы, мәңгелекнең бер мизгеле генә. Шушы кыска вакыт эчендә кеше зур-зур планнар кора. Барлык уйлаганын эшләп өлгерергә, җирдә үзенең эзен калдырырга,үзен мәңгеләштерергә тели, һәрдаим шуңа омтыла. Татарстанның халык рәссамы Мадияр Хаҗиев та шундый илаһи затларның берсе. Аның иҗаты безне галәм киңлекләренә сәяхәткә дәшә сыман. Ходай аңа сәләтне мулдан биргән. Рәсемнәренә карап сокланмаска мөмкин түгел: һәркайсы пакьлек, матурлык нурлары чәчеп тора, табигатьнең үзе кебек үк чын, тыйнак. Мул, җылы буяулар белән сурәтләнгән картиналарына дөньяның әллә нинди гамь-гыйбрәтләре, сабыйларча самимилек,үзәк өзгеч моң-сагыш сыйган.

Мадияр Хаҗиев тумышы белән Саба районы Керәнле авылыннан. 1976 елда, Казан сәнгать көллиятен тәмамлагач, Чаллыга эшкә юллама ала. Шул елдан алып бүгенге көнгә кадәр ул биредәге сәнгать мәктәбендә балаларга рәсем ясау сабаклары бирә. Яшь буында гүзәллеккә мәхәббәт тәрбияләүче рәссам, ислам декоратив сәнгате үрнәкләрен заманча нәфис-эстетик йолалары белән бәйләп, этник авангард стилендә иҗат итә. Ул үз иҗатында халык фольклорына, милли йолаларыбызга еш мөрәҗәгать кыла. Туган ягына булган мәхәббәтен Мадияр Хаҗиев табигать һәм кеше образлары аша сурәтли. Аның шулай ук тарихи үткәнебез, төрки дөнья һәм, әлбәттә, Габдулла Тукай шәхесенә кагылышлы эшләре дә гаҗәеп бай итеп тудырылган.



«Болгар кызы»



«Айлы төндә»

Иҗатчының шактый эшләре Татарстан сәнгать музеенда, «Хәзинә» галереясында, Казандагы Габдулла Тукай, Максим Горький музейларында һәм башка бик күп музей-галереяларда саклана. Төркия, Италия, Алмания, Америка, Канада кебек илләрдәге шәхси тупланмаларда да аның күңел җимешләре бихисап.

«Әнкәмнең догалары»

«Авыл табигате, авыл тематикасы, үзебезгә генә хас милли төсләр — барысы да келәм, намазлыклардан, ашъяулык, күлмәк бизәкләреннән яңара», — ди кылкаләм остасы Мадияр Хаҗиев. — Мондый үзенчәлекле милли төсләр танылган рәссам Бакый ага Урманчеда бик мулдан. Аның иҗаты һәрчак яктылыкка өндәп тора». Үзенең остазы итеп тә иң элек Бакый ага Урманчены саный ул.

Рәссам төрле темаларга иҗат итә, мәңгелек кыйммәтләрнең югалуына, кеше гомеренең кадерсезлегенә, күңелләрнең торган саен тупаслана баруына борчыла. Кешеләрне үз гамәлләре турында уйланырга чакыра.

Майлы буяулар белән иҗат итәргә яраткан кылкаләм остасының шәмаилләре дә байтак. Тамашачыны иман нуры белән дә нурландыра, матурлык дөньясына алып керә ул. Һай, нинди тылсым, нинди серләр яшеренгән аларда! Игътибар белән күзәтә генә бел!..

Ә инде шигърият патшасы — Габдулла Тукайга багышланган тулы бер картиналар циклын тудырганда автор үзен дә шул чорга кайткан итеп күрә булса кирәк. Аның «Очрашу», «Тукай һәм без», «Тукайның балачагы» кебек картиналарына карап кемнәр генә сокланмас! Тикмәгә генә автор: «Тукай — безнең өчен ачылып бетмәгән якты образ, иҗат иткәндә мин үземне икенче галәмгә күчкәндәй тоям», — димидер.

Рәссамның шагыйранә җаны һәрчак эзләнүчән, ашкынучан. Аның тормышында илһамлы мизгелләр кабатланып тора. Хисси тойгылары кайчак яшен кебек бер балкып ала да күздән югала, ә кайчак кояшның үзе кебек күңел күгендә байтак эленеп тора. Аңа тиз күнегәсең, әле бик озак сүнмәсен аңлыйсың. Хыялны чынга ашыру өчен вакыт чиксез кебек тоела. Кылкаләм остасы Мадияр Хаҗиевның иҗатында кояш нурлары мәңгелек бугай — «Кояшлы иртә», «Авыл читендә», «Моң»,

«Моң»

«Әбиемә», «Болгарда яз» кебек иҗат үрнәкләре һәммәбезне дә иркәли,назлый... ерак гасырларга дәшә...

Сабый чакта тәпи йөргән чирәмлекләр, бәрәңге бакчалары, челтер чишмәләр, нурлы авыл өйләре күңелдән китеп тормый, китеп тора алмый да! Әйе, кеше табигать белән гел бергә. Ул табигатьтән төсләр җыя-җыя гүзәллеккә омтыла, сабырлыкка өйрәнә. Табигать — кешене, кеше дөньяны бизи. Син дә, кылкаләм остасы, шушы бергәлекне тулыландырып иҗат җимешләрең белән тамашачы күңелендә матурлык хисләре уятасың. Ялантәпи йөргән чирәмнәр төсен, әле генә чапкан печәннәрнең хуш исен оныттырмыйча, туган як табигатенең кадерен белергә, көмеш сулы елгалар, күлләр, саф сулы чишмәләрне яратырга өндисең. Олы иҗатың өчен рәхмәт сиңа!..

Юкка гына Халык рәссамы, Чаллы шәһәренең шәрәфле гражданины исемен йөртмисең син. Бер мәктәптән чыккан ике иҗатчының Халык рәссамы исемен йөртүе дә сирәк күренеш. Сез дустың Мөдәррис Минһаҗев белән Саба районының уңдырышлы туфрагында туып үскән ике олпат иҗатчыбыз бит. Син юкка гына, Сабаның табигате дә, кешеләре дә ихласлар, туган як, аның бәрәңге бакчалары әле дә төшкә кереп йөдәтә, димисеңдер шул. Әйе, безгә туган як, еракка киткәч сагындырыр өчен, олыгая башлагач сабый чакка кайтыр өчен кирәк тә!..

Иҗатчының шактый эшләре Татарстан сәнгать музеенда, «Хәзинә» галереясында, Казандагы Габдулла Тукай, Максим Горький исемендәге музейларда һәм башка бик күп музей-галереяларда саклана. Төркия, Италия, Алмания, Америка, Канада кебек илләрдәге шәхси тупланмаларда да аның иҗат эшләре шактый. Ә бүләк иткән әсәрләре әллә ничә дистәләр белән исәпләнә. Кулларыңнан куан дими, ни диярсең мондый юмарт, ихлас иҗатчыга!.. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ЕЛАН КУЛЬТЫ — Төрки халыкларда, аерым алганда болгар-татарда, еланга табыну борын-борынгыдан килә. Ибне Фазлан борынгы төркиләрдә (аерым кабиләләрдә) елан культы таралган булуын әйтә һәм болгарларда елан озын гомер символы булып каралган, дип яза. «Шайтан кала» дигән риваятьтә дә елан болгарларның ярдәмчесе һәм киңәшчесе итеп сурәтләнә. Гомумән, татар мифологиясендә еланнарны ике төргә — ак һәм кара еланнарга бүлеп караганнар. Кара елан һәрвакыт кешегә каршы, ә ак елан һәрвакыт аңа булыша, дип саналган.

Борынгылар елан — җирнең хуҗасы, дип уйлаганнар һәм аны үтерү, рәнҗетү яки куып җибәрү җирне хуҗасыз калдыруга тиң булган. Шәрыктә борынгы хәзинәләрне еланнар саклый, дип ышанганнар.

Ак (сары) еланнарга караш аеруча уңай булган. Алар кешегә бүләк бирәләр һәм аңа ярдәм итеп торалар, имеш (Л.Җамалетдинов). «Татар мифлары» китабының төзүчесе Г.Гыйльманов: *«Елан патшасы Шаһмара», «Ярлы егет белән патша кызы», «Аучы белән асрау кыз», «Ак елан» һ.б. халык әкиятләрендә нәкъ әнә шундый изге Елан күз алдына килеп баса»*, — дип яза.

Фатих Урманче үзенең «Ак елан һәм еланнар» дип исемләнгән зур мәкаләсендә: *«төрки-татар мифологиясендә бик киң чагылыш тапкан Елан бер яктан илаһи бер дәрәҗәдә торган уңай, изге зат буларак сурәтләнсә, соңгырак дәверләрдә Адәм балаларының куркыныч дошманы, коточкыч явыз зат итеп күзаллана»*, — дип яза һәм: *«Мондый капма-каршы, бер-берсен тулысынча инкяр итүче күзаллаулар кайсы тарихи чорларда һәм ничек барлыкка килгән?»* — дигән сорау куя.

Гадәттә бу сорауга җавап биргәндә «чит-ят мифлар йогынтысын» беренче сәбәп итеп куялар. Мәс., еланны явыз зат дип игълан итү зәрдәштлекнең изге китабы «Авеста»дан (я.э.к. VI гасыр) килә дип саныйлар (андагы Ажи Даһака — елан Даһака татар мифологиясендә

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

аждаһага әйләнгән). Аннары соңгырак дәверләрдә гарәп мифологиясенә яһүди һәм нәсариларның төп изге китабы булган «Библия»нең йогынтысын искә алалар. Мондый йогынтыларны кире кагып булмый, әлбәттә. Ләкин төп сәбәп кешенең үзендә, аның эчке сыйфатларында булырга тиеш.

Кызгану-җәлләү һәм ярату-сөю төшенчәләре, психология күзлегеннән караганда, бер тирәдәрәк йөри торган мәгънәгә ия. Шуның кебек үк, кемнәндер курку һәм кемгәдер табыну-буйсыну төшенчәләре дә күңел төпкелендә берберсенә якын урнашканнар. Болар җиңел генә бер-берсенә күчә алалар, дип фараз итәргә була. Кешедә еланнан курку тойгысы – эволюция мирасы һәм ул, асылда, инстинктлар тирәнлегендә, психик катламнарның хайвани тирәнлегендә үк ята. Күзәтүләргә караганда, елан белән очрашканнары булмаган маймылларны да аны күрүгә үк гадәттән тыш көчле курку хисе биләп ала. Кыскасы, мондый әверелеш диалектиканың гомуми канунына буйсына, ул капма-каршылыкларның бер-берсенә күчешеннән башка нәрсә түгел. Алла һәм Иблис төшенчәләренең бердәмлегенә философ Сартр күптән игътибар иткән иде. Бәс, шулай икән, вакыты белән еланга табынуның көнкүрештәге гадәти мәгънәсе — курку өстенлек алырга мөмкин һәм бу табыну күп кенә халыкларда нәкъ менә кире мәгънәдәге хискә — нәфрәткә әйләнгән дә. Шуңа күрә татарда еланга мөнәсәбәтнең капма-каршылыклы булуына гаҗәпләнәсе түгел.

Библиядән аермалы буларак, Коръәндә еланга аз урын бирелгән. Без анда Муса пәйгамбәрнең таягы (гаса) еланга әйләнгән могҗиза турындагы сюжетны гына очратабыз. Ә Адәм галәйһиссәлам белән аның хатыны Һәва ананы җәннәттәге тыелган агач җимешеннән авыз итәргә Иблис котыртуы гына әйтелә («Сыер» сүрәсе: 35,36). Ләкин шулай да мөселман кешесе бу очракта Иблиснең дүрт аяклы елан сурәтендә җәннәткә үтеп кергәнлеген хәдистән белә. Ягъни монда барыбер Библия белән тәңгәллек бар: елан – адәми затның дошманы. Шуңа күрә еланга мөнәсәбәт мәсьәләсендә Исламны христиан диненә катгый каршы кую хакыйкатьнең сыңар ягы гына.

Бервакыт Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатыны хәзрәти Гайшә елан үтерә һәм төшендә аңа «син мөселманны үтердең», дигән хәбәр килә.

Төштә елан күрү гадәттә дошманнарны, ялган дусларны, хыянәтне, зыян-зарар күрүне белдерә. «Төш юрау китабы»нда, мәсәлән: *«Әгәр кем ирсә төшендә ак елан күрсә, мөселман дошман булыр һәм кара елан күрсә, кяфир дошман булыр», «Әгәр кем ирсә төшендә елан күрсә, яман билге булып тора, садака бирергә кирәк», «Әгәр кем ирсә төшендә еланны күрсә, аңа ялганнан бәлаләр тияр»* кебек тәгъбирнамәләр бар. Әгәр елан ак төстә булып, ул сиңа карата дошманлык күрсәтми икән, төшне уңай мәгънәдә тәгъбир кылу тиеш икән. *«Әгәр кем ирсә төшендә елан тотканын күрсә, кулына бераз мал керер»*, дигән юрау бар. Төштә елан үтергәнне күрү еш кына дошманны җиңү, дип юрала.

Сихерләрне рәд кылу (кире кагу) догасында без мөселман дөньясында сары еланның да явыз зат итеп каралганлыгын күрәбез. *«Әйт: саклаучыны сорыймын Алладан – таңны яратучыдан, шул нәрсәләрнең явызлыгыннан (ул барлыкка китергән сары еланнардан, чаяннардан, дию-пәриләрдән), төн караңгылыгы җәелгәндәге явызлыктан, сихерчеләрнең явызлыкларыннан (унике төенгә укып өргән сихерче хатыннардан, көнчеләрнең хөсетлегеннән)».* Бу дога аятькә нигезләнгән (җәя эченнән башка өлеше).

Шул рәвешле, халыкта еланга капма-каршылыклы карашлар диалектик бердәмлек булып оеша.

//Йукса ут сүндереб — күз куймак, елан үлтереб — баласын бәсләмәк [тәрбияләү, туендыру] гакыйллар эше дәгел. Сәйф Сараи. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның апрель ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Татарча театрлар

Большой театрда. Соңгы вакытларда шәһәребездә һәр атна саен ике театрда (Большой һәм Малый) мөселманча спектакльләр була башлады. Ашказарский[1] труппасы озын, һичбер төрле мәгънә аңлашылмый торган «Фаҗигаи музыкаи исламия, беренче мөселман сәйяр труппасы» шикелле неграмотный исем илә аталган. Бу труппа көз көннәрендә Новый театр һәм Шәрык клубларында берничә спектакль куйган иде. Соңгы вакытларда Большой театр илә эш күрә башлап, анда спектакльләр куя башлады. Мин труппаның уенын бу ел берничә мәртәбә күргән идем. Монда җыен уйный белмәгән, артистлык куәтләре булмаган адәмнәр арасында, уенын карап тора алырлык итеп чыгара торган фәкать Арская ханым[2] гына бар. Апрель 10ында Большой театрда «Каениш» илә «Безнең шәһәрнең серләре» куелган иде. Боларның әүвәлгесендә Арская ханымнан башкаларының уйнаулары һәрбер тәнкыйтьтән түбән булган шикелле, соңгысы бөтенләй изелде.

Мәсьәлә бу уенда гына түгел. Казан халкы андый уеннарга театр һәвәскәрләре исемен алган артистларның уйнауларын күреп өйрәнеп җиткән. Хәтта шушы артистларның күбрәк зияратчеләре булган урта сыйныф халкының театр хакындагы зәвыгы да адашып бетеп, юлдан чыккан инде. Минем Большой театрдагы кичә турында әйтергә теләгәнем аның балеты хакындадыр. Ашказарский халыкны үзенә тарту өчен кичәсен афишалар илә бик зур итеп игълан итә һәм кичәгә баручыларга әллә нинди нәрсәләр вәгъдә итәдер. Бу кичәдә вәгъдә ителгән нәрсәләрдән берсе «Шәрык биюләре» исемендәге балет иде.

Меселманча спектакль дигәч, халык үзенең гафиф хатын вә кызларын һәм бала-чагаларын кичәгә алып бара. Әлбәттә театрга барган кеше аннан нинди генә булса да рухи азык алырга, күңелен шуның илә бераз кайгы вә агырлыктан тындырып тынычланырга барадыр. Менә шундый ният илә барган, яртысыннан артыгы гафиф булган халыкка Большой театр идарәсе Ашказарский илә бергә «Шәрык биюләре» исемендә ялангач марҗалар чыгарып, Парижның иң фәхеш урыннарында биелә торган әллә нинди танец страстныйларны тәкъдим итте. Башына чалма, өстенә чапан кидереп ислам солтан вә әмирен сәхнәгә чыгарып хурлау вә алардан ялангач марҗалар биеттерттерү илә генә ул биюләр «Шәрык биюләре» булмаган кебек, мондый биюләр бер җирдә дә гафиф публикага тәкъдим ителмиләр, бәлки шантаннарда[3], балаганнарда[4] гына боларны бик сирәк кенә күрергә

[1] Ашказарский — Кудашев Ашказарский Ильяс Батыргәрәй улы (1884-1942) — татар театрына нигез салучыларның берсе.

[2] Арская ханым — Кудашева-Арская (Әхмәдиева) Фәхрия Ибәтулла кызы (1880-1956) — артистка, Ашказарскийның хатыны.

[3] Шантан — кафешантан — эчемлекләр һәм ашлар бирелү белән бергә тамашалар күрсәтү өчен сәхнәсе дә булган ресторан, кафе.

[4] Балаган — ярминкәләрдә, зур базарларда тамаша оештыру өчен корылган зур чатыр яки корылма.

мөмкин буладыр. Ашказарский спектакльләренә бара торган урта сыйныф халкының әхлакый тәрбиясе хәят кысынкылыгы сәбәпле болай да бик зәгыйфь булганлыктан, бу сыйныф халкын театрга дип илтеп шундый танецлар илә извращать итә башласак, моның соңы ни булыр?

Большой театр идарәсенең мөселманнарны истиһза [мыскыл] итүе моның берлә генә бетмичә, ул һәр җомга көнне мөселман спектакльләреннән соң әдәпсез, бик пикантный булган фарслар[5] да куядыр. Шунда агай-энеләр, хаҗилар вә абзыйлар җәмәгатьләре вә бала-чагалары илә барып, шул әдәпсезлекләрне рәхәтләнеп карап торалар. Большой театрда фарс куелды исә, халыкның яртысыннан артыгы мөселман халкы буладыр. Мондый әдәпсез манзараларны караудa мөселман халкы үзе гаепле булса да, әдәпсез нәрсәләрне җомга көнгә хаслап куюы илә Большой театр идарәсе дә мөселманнарга сансызлык итәдер ки, мөселманнар үзләренә ителгән бу сансызлыкны аңларга тиеш иделәр.

Новый театрда. Новый театрда «Сәйяр» труппасы тарафыннан «Кемдә гаеп?» һәм «Хат болгатты» исемле пьесалар куелган иде. «Кемдә гаеп?» — пьесалыгы җәһәтеннән бөтенләй тәнкыйть күтәрерлек түгел, шуның илә бергә мәгънәви җәһәтеннән дә сәхнәгә куярлык нәрсә түгелдер. Артистлар шундый начар нәрсәләрне дә муаффәкыятьле [уңышлы] уйнап, халыкны канәгатьләндерә алдылар.

Т.Н.

Мөселман хәстәханәсе мәҗлесе

Кичә 12 апрельдә иртән сәгать 10да Болгар номерында Казан мөселман хәстәханәсе комитетының Галимҗан хәзрәт риясәте белән [җитәкчелегендә] җыены булды. 1) Хәстәханәнең караватларын арттыру мәсьәләсе каралып, мәҗлес бер агыздан әүвәлдәге 56 караватны 75кә җиткерергә карар бирде. 2) Арттырылган караватларның һәммә әсбапларын хәзерләп тиздән авырулар урнаштырырлык дәрәҗәгә җиткерү хәстәханәнең әүвәлдә сайланган хозяйственная комиссиясенә тапшырылды. 3) Хәстәханәнең аренда мәсьәләсе кузгалып, хәзергә кадәр йорт хуҗалары илә хәстәханә комитеты арасында аренда хосусында бер карарга киленеп бетмәгән булса да, һәр айга 150 сум фатир хакы бирә барырга карар бирелде. 11 сәгать тәмамында мәҗлес ябылды. Комитет әгъзаларының имзалары.

Кояш. — 1915. — №679. — 13 апрель.

Тукай каберенә таш кую мәсьәләсе

Габдулла Тукаев вафат булган көнне 2 нче апрельдә Вологда мөселманнарыннан бәгъзеләре мәрхүмне яд итү мәҗлесе ясаганнар. Бу мәҗлестә Тукайның намен тәэбид итү [исемен мәңгеләштерү] өчен эшләнәчәк нинди дә булса хәерле бер эшкә иганә итү йөзеннән үзара 22 сум 5 тиен акча җыйганнар. Бу акчаны туплап идарәбезгә җибәрүче Гыйльми әфәнде Мишәров, Тукай хатирәсенә бу көнгә кадәр һичнәрсә эшләнмәгәнгә тәәссеф итә [ачына]. Хәзер Тукайның вафатына 2 ел тулып үтте. Мәрхүмнең наменә нинди дә булса берәр хәер эш эшләргә кирәк иде, ди һәм бу акчаны Тукай җәмгыятенә тапшырып, шул сүзләрне җәмгыять әгъзаларына белдерергә куша.

[5] Фарс — комик алымнарга корылган, беркадәр әдәпсезрәк, уенчак һәм җиңел эчтәлекле комедия.

Без Гыйльми әфәндегә вә башка иганә итүчеләргә: «Тукай җәмгыяте дигән нәрсә юк, андый җәмгыять тәшкил итү мәрхүмнең вафаты вакытларында сөйләнсә дә, вөҗүдкә [барлыкка] килмәде», — дибез. Иганә итүчеләр разый булсалар, бу акча Тукай җәмгыятенә җибәрелеп тә, җәмгыять булмаганлыктан, идарәдә саклана торган башка акчалар илә Тукайның каберенә яхшы мәрмәрдән таш яздырып куймакчы булабыз. Шулай булмаганда җәмгыять кайчан булачак та, ул кайчан таш яздырып куячак?

Мөселман мәркәзләренең һәрберсеннән еракта тора торган вологдалы кардәшләребезнең милли шагыйребезне хәтерләренә төшереп торып, аның намен тәэбид итү юлында кулларыннан килгән тәшәббесләрдә булынулары[6] мактап бетермәслек кадершинаслык, бик бөек тәкъдир ителерлек милли аңлылыктыр. Ерактагы бу кардәшләргә иганәләре өчен идарә самими тәшәккерләрен гарыз итә һәм гомум иганә итүчеләрдән таш яздырып куюга муафәкать [килешү] җавабы көтәдер. Шул җавапларның алынуы белән идарә бернәрсәгә карамыйча Тукай мәрхүм кабере өчен таш яздырырга тәшәббес итәчәктер.

Кояш. — 1915. — №680. — 14 апрель.

Юнысовлар приютында

Бу елгы уку елында Юнысовлар приютын[7] 7 бала тәмам иткән. Болардан икесен мәзкүр приютның мөтәвәллисе Мөхәммәдрәхим әфәнде Юнысов үз тәрбиясенә алып, тәхсилләрен [укуларын] хөкүмәт мәктәпләрендә дәвам иттертергә карар биргән. Калган бишесе бу көндә үзләренә хезмәт табар өчен урын табу мәҗбүриятендә икәннәр. Мөселманча вә русча ибтидаи тәхсилне тырышып үткән бу балаларга мөселманнарның хезмәт бирүләрен үтенәбез. Кибетче булу өчен бу балалар бик муафыйктырлар [яраклылар]. Сәүдәгәрләребезнең дикъкатьләрен җәлеп итәбез.

Бу дарелятим Юнысовлар тарафыннан Казан фәкыйрь мөселманнары балаларын тәрбияләр өчен тәэсис ителгән [оешкан] булса да, хәзергә кадәр монда тәхсилдә булынган балалар һәммәсе диярлек авыл балалары икән. Казан фөкарасы никтер бу көнгә кадәр бу дарелятимнән файдалану юлына керешми, ятимнәрен сәдакага йөртсә йөртә, ләкин бу дарелятимгә куярга иҗтиһад итми икән.

Шулай да, табигый, мещан балалары булмаганга карап, дарелятим һичбер вакытта буш булмый гына түгел, бәлки үзенә мөрәҗәгать итүче бик күп авыл балаларын урын юклыктан рәд итәргә [кире кагырга] мәҗбүрият күрә икән.

Кояш. — 1915. — №681. — 15 апрель.

Су ташуы сәбәпле

20 нче апрельдәге давыл вакытында вокзалдан Усиягә[8] туры төшә торган шәһәр дамбаларының эчке елгасы аркылы салынган 30 сажин кадәр буйдагы агач күпернең яртысын су күтәреп алып киткән. Күпер хәзер дамбага китерелеп бәйләнеп куелган. Крепость астындагы күпернең читендәге балчык туфрагы, ташы ишелеп төшкән. Болак күперләре вә бүтән күп күперләрнең читләре бозгаланып беткән. Шул мөнәсәбәтләр белән шәһәр управасы үзенең мөһәндисләре

[6] Тәшәббесләрдә булынулары — эшкә тотынулары.
[7] Юнысовлар ятимханәсе — 1844 елда Ибраһим һәм Исхак Юнысовлар иганәсенә төзелә.
[8] Усия — Дальнее Устье пристане.

[инженер] вә мигъмарларыннан [төзүчеләреннән] мәзкүр күперләрне караттырырга вә бу күперләрне һичбер вакытта су күтәрмәслек рәвештә төзәттерер өчен планнар корырга уйлаган. Моны хәл итүне техника һәм малия [финанс] комиссияләренең мөштәрәк [уртак] карамагына тапшырган.

Кояш. — 1915. — №688. — 23 апрель.

Шәрык клубының гомум җыены

25 нче апрельдә кич берлә Шәрык клубының гомуми җыены булды. Җыен Ягъкуб әфәнде Хәлили[9] тәхте риясәтендә дәвам итеп, иң әүвәл 1913-1914 елгы сезонның хисабы кабул ителде. Аннан соң Петроградта мәҗрухлар вә аларның гаиләләренә мөселман ярдәм комитетының ачылачак мәхәлли шөгъбәсенә өч әгъза сайлау һәм шушы мәркәзи комитетка идарәнең ике йөз сум акча җибәрергә биргән карарын тасдыйк итү [раслау] мәсьәләләре каралып, җыен идарәнең акча җибәрү хакындагы карарын бер агыздан тасдыйк итте һәм Казандагы мәхәлли комитетка үз тарафыннан Вәлидхан Таначов, Вәли Апанаев, Ибраһим Бикколов әфәнделәрне әгъзалыкка сайлады.

Соңыннан идарә тарафыннан клуб бинасын лазаретка бирер өчен бинаны хуҗасына вакытлыча кайтарып торуның нинди шартлар илә эшләнгәнлеге җыенга гарыз ителеп, җыен идарәнең бина хуҗасы илә бинаны вакытлыча хуҗага кайтарып тору хакында ясаган шартларын яраклы вә мәгъкуль итеп тапты.

Кояш. — 1915. — №692. — 28 апрель.

Ташаяк[10] ярминкәсе

Ташаяк ярминкәсенә бу ел гадәттәгедән дә рухлырак хәзерләнүләр дәвам итә, зур кибетләр һәммәсе ачылып беткән, маллар һәммәсе урнаштырылып җиткән диярлек. Вак кибетчеләр — вакытлы гына агачтан корылганнарының да күбесе хәзерләнеп җиткән инде. Бик аз микъдарда алынмый калган урыннар соңгы көндә ашыгычлык белән алынып тормакта. Болар барлыгы 10-15 кечкенә урыннан гына гыйбарәттер.

Җәмгыяте хәйрия приюты

Казан шәһәрендә җәмгыяте хәйрияи мөслимин тарафыннан ачылмыш приютта укып һәм тәрбия кылынып, башка сәнәләрдәге кеби бу сәнә [ел] дә алты бала мөселманча һәм русча укуны тәмам итеп, 16 нчы апрельдә училищная комиссия хозурында имтихан кылынып шәһадәтнамәләр алып чыгарга муаффәкъ булдылар. Югарыда зикер ителгән алты баладан икесе һәр фәннән «биш»ле алып тәмам иттеләр, ярдәм итүче әфәнделәр табылса, бу ике ятимне югырырак мәктәпләргә бирсәк — гүзәл эш булыр иде. Инде бу ятимнәргә үзләренә муафыйк урыннар табып бирү кадәрлесе калды. Хезмәт өчен бала кирәк, дигән әфәнделәр мәзкүр приютның назыйрына [мөдиренә] мөрәҗәгать итсеннәр.

М.Мөштәриф.

Кояш. — 1915. — № 693. — 29 апрель.

[9] Ягъкуб Ибраһим улы Хәлиуллин (1877-1945) — журналист, педагог, мәгърифәтче, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире.

[10] Ташаяк ярминкәсе — Болак буенда май-июнь айларында эшләгән ярминкә. Хәзер бу сәүдә үзәгеннән мирас булып Ташаяк урамы калды.

1

ТАТАР ИМӘНЕ

2

3

2011 елның сентябрендә төшерелгән фоторәсемнәр

Голҗа шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) мөһаҗир татарлар утырткан агачлар: *1-2 нче рәсемнәрдә* — 1890 елда утыртылган карыйгач (карагач). Борынгы татар зираты янәшәсендәге бу мәгърур агачны да җирле халык «татар имәне» дип атап йөртә. *3 нче рәсемдә* — 1894 елда утыртылган биш имәннең берсе. Агачлар дәүләт тарафыннан саклана. ■

Көлке көлә килә...

Габдулла ТУКАЙ
(1886-1913)

ЕГЕТ ИЛӘ КЫЗ

Е г е т:
Сөям чүмеч кеби борныңны, җаным,
Гашыйк булдым, тәмам бетте
мәҗалем*.
Җанашым, аһ, иләк аузыңны үпсәм!
Ни кайгы, инде мин шул чакта
үлсәм.

К ы з:
Мәхәббәтсез! Лыгырдый шунда
җукны,
Үзеңдә килмәгән җир бер дә
җукмы?

Е г е т:
Ачуланмасана, Гайниҗамалым,
Сине мин кимсетеп әйтмим лә,
җаным.
Синең төсле матур кызлар
сирәк бит,
Хатын алсаң, иләк,
чүмеч кирәк бит.
Сине алсам, чүмечле һәм иләкле
Булам ич, акча туздырмак кирәкми.

*Мәҗалем — көчем, чыдамлыгым.

Муса ҖӘЛИЛ
(1906-1944)

БӘЛА

— Мин яратам бер хатынны,
Матурның да матуры.
Тик шунсы бар: ул матурым
Үзе бер ир хатыны.

— Гаҗәп түгел ансы, тик әйт:
Ул ирен яратамы?
Яратмаса, кыен түгел
Төзәтү бу хатаны.

—Ул яратмый бер дә ирен,
Җене белән бер күрә.
Утырып-утырып бу иренә
Чыкканына үкенә.

— Ә алайса ул иреннән
Аерылсын, әйт син аңа,
Гөрләтеп бер туй итәрсез,
Кояш чыгар сиңа да.

—Аһ, туганкай, рәхмәт сиңа,
Алтын синең бу сүзең,
Ләкин бөтен бәла шунда:
Аның ире —
Мин үзем.

Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Фәнис ЯРУЛЛИН
(1938-2011)

ШАУ-ШУСЫЗ ГЫНА

Ниһаять, мин дә яңа фатирлы булдым! Фатирның да нindие әләкте әле: газы дисеңме, кайнар суы — бары да, бары да һәйбәт! Шуның өстенә стеналары музыка уйнап тора... Безнең заманда кешеләр ни генә уйлап тапмыйлар! Иртән дә музыка яңгырый, кичен дә, көндезләрен дә туктамый. Тора-бара без музыканың стенаның үзеннән түгел, күрше фатирдан яңгыравын аңладык. Аңладык та сукрана башладык:

— Нинди бетмәс черелдәү булды инде бу!

— Ичмасам, берәр көн ял бирсеннәр иде!

Юк, күршеләр үзләре белеп туктамадылар. Көннәрдән беркөнне мин түзмәдем, кызып-ярсып, күршемә барып кердем. Тап-таза хатын, чуар диванга сузылып ятып, радио тыңлый.

— Исәнмесез, — дидем.

— Комачаулама! — ди бу. — Бик шәп тапшыру бара!

Бер күрешүдә генә аңлата алмадым. Ялынып тагын кердем. Тузынып, йортлар идарәсенә бардым. Булмады. Көн туды исә, куркынып, стенага карыйм. Шуны белгән сыман, стена бөтен көченә җырлап җибәрә!

Яхшылап та әйтеп карадым, ачуланып та, хәйләләп, юмалап та йөрдем. Сигезенче март көнне унике сумлык парфюмерия наборы алып кайттым, тик стеналар һаман гүләп, җырлап-биеп тордылар. Радиода эшләүче бер танышым белән ызгыштым, невропатологка йөри башладым, иске фатирыма кайтаруларын сорап, гариза бирдем. Үз радиоалгычымны күралмас булдым. Һәм беркөнне:

— Тукта әле, күз күеген чыгарып сатыйм да, аз булса да ачуымны алыйм, — дип, радиоалгычымны ак сатинга төреп, күтәреп чыгып киттем. Ишектән чыгуым булды, каршымда күршем калыкты. Кулымдагы ак төенне күрсәтеп:

— Нәрсә бу? — дип сорады ул.

— Радиоалгыч, — мин әйтәм.

— Көйсезләнеп торамы әллә?

— Юк, — димен. — Кирәге калмады. Хәзер без көне-төне сезнең радиоалгычны тыңлыйбыз. Безгә шул җиткән! Монысын сатарга алып барам!

— Әһә, — диде хатын, зәһәрләнеп. — Үзегезнекен сатып, бушка гына минекен тыңлап ятарга уйлыйсызмыни? Тәтеми торсын әле!

Башын-күзен тондырып кереп китте хатын һәм шуннан бирле радио тавышы ник бер мәртәбә ишетелсен! Әллә кайчан радиомны илтеп сатасы калган! ■

Мирасворд

Су, кымыз салу өчен капчык сыман савыт

... Насыйри

Татар халкының милли ризыгы

Кысу, эксплуатацияләү

Кыйммәтле мехлы җәнлек

Ут, ялкын (иск.)

... Гамзатов

Галимҗан ... (журналист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе)

... Кунанбаев

Нәзек

Урта Азия халкы

Хан хезмәтендәге хәрби

Иордания каласы

Икейөзлелек, монафыйклык (иск.)

Шарык поэзиясендә ике юллык шигырь

Актриса ... Галиева

Антик философиядәге төп категорияләрнең берсе

... - хөрмәт

Ял итү өчен тукталыш (бор.)

Артист гәүдәләндергән образ

Какшамас

Алма сорты

Гайсин, Әхмәдиев

Пөхтә, җыйнак, ипле (диал.)

Шиһабетдин Мәрҗани туган авыл

... Кәһиров

Халык авыз иҗаты әсәре

Борынгы грек шагыйре

«... төннәр» (Г.Әпсәләмов)

... Пугачев

Җиделе лампа, бишле ...

Бакый Урманченың һөнәре

Мәшһүр немец фәлсәфәчесе

Н.Фәттах романы

Кирәкле, тиешле, зарур (иск.)

Удмуртларның элекке атамасы

К.Тинчурин драмасы

Киемнең әчке ягына тегелгән тукыма

Чуаш телендә чыгучы әдәби журнал

«Азатлык» радиосының штаб-фатиры урнашкан шәһәр

Рус рәссамы

Рәис Габдулла *төзеде.*

3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Җөри, им, Егоров, Нина, Ив, ку, Хәй, Албай, хыял, анорак, Питрау, Ява, ама, «Туганайлар», ияр, Емельянов, Ибушев, Зита, һун.
Өстән аска: падре, ре, Рәхим, Татый, Җыен, яр, Луиза, Ги, фланг, би, Риони, якут, имра, юнан, шаһ, Ваня, Оле, Гаврилов, «Вий», Ван, бра, ля, Каа, Марс, уйку.

Кытай Халык Республикасы. Өремче шәһәре. XIX гасыр ахырында нигезләнеп, 1919 елда киңәйтелеп салынган татар мәчете

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / апрель

• 1075 ел элек (940)

Шәрыкнең бөек шагыйре Әбүлкасыйм Фирдәүси (якынча 940-1020 яки 1030) дөньяга килә.

• 130 ел элек (1885)

Казанда «Шахмат уеннары белән кызыксынучылар» оешмасы («Шахмат клубы» ачыла).

• 120 ел элек (1895)

3 апрельдә җәмәгать эшлеклесе, журналист, «Чаян» журналына нигез салучыларның берсе Мәхмүт Бөдәйли (1895-1975) дөньяга килә.

5 апрельдә Казанда Татарстан Республикасының Милли музее ачыла.

• 100 ел элек (1915)

24 апрельдә күренекле җырчы Усман Әлмиев (1915-2011) дөньяга килә.

• 90 ел элек (1925)

Мәскәү шәһәрендә «Яшь авыл» журналы чыга башлый.

• 85 ел элек (1930)

12 апрельдә «Кызыл Татарстан» газетасында Һади Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасыннан «Беренче хат»ы дөнья күрә.

• 80 ел элек (1935)

Казан дәүләт университетының Гыйльми китапханәсендә көнчыгыш халыклары телләрендәге кулъязмалар арасыннан Әбүлкасыйм Фирдәүсинең «Шаһнамә» исемле поэмасының төрекчәгә тәрҗемә ителгән ике бүлеге табыла. Оригиналына караганда күп озайтылып, шигырь белән нәсер аралаштырып тәрҗемә кылынган бу кулъязманы XV йөзнең ахырларында язылган, дип исәплиләр.

• 75 ел элек (1940)

27 апрельдә Татар дәүләт академия театрында Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» әсәре сәхнәләштерелә.

• 60 ел элек (1955)

«Совет әдәбияты» журналында Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы дөнья күрә башлый.

• 50 ел элек (1965)

6 апрельдә РСФСРның Министрлар Советы Казан пионерлар сараена Абдулла Алиш исемен бирү турында карар кабул итә.! ■



Камил Вәлиәхмәт улы Муллашев 1944 елның 27 октябрендә Кытай Халык Республикасының Өремче шәһәрендә дөньяга килә. Алматы сәнгать училищесын (1967), Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать институтын тәмамлый. 1980 елдан — СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы. 2003 елдан — Татарстанның халык рәссамы. 2009 елда ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Камил Муллашевның әсәрләре Россиянең һәм чит илләрнең шәхси вә дәүләти тупланмаларында саклана.

КАМИЛ МУЛЛАШЕВ

«Бәхет кошы». 2001 ел. Киндер, майлы буяу



«Урак өсте». 2001 ел. Киндер, майлы буяу

«Әнием портреты». 1986 ел. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

«1898 елда Көнчыгыш Кытайга тимер юлы төзелешенә һәм сәүдә эшләре белән татарлар күпләп барып урнаша башлаган. Берничә елдан андагы тимер юл буе кибетләре һәм рестораннары, тулаем диярлек, татар эшкуарлары карамагында булган».
РАИФ МӘРДАНОВ. «ЮЛЫБЫЗ ТУГРЫ, МИЛЛӘТЕБЕЗ КӨЧЛЕ».

«Әсән Кайгы кешеләр арасындагы дуслык, татулык, йомшаклык, әдәп, туганлык сыйфатларына дан җырлый. Җәмгыятьтә очраган шапырыну, наданлык, минминлек, кеше белән санлашмау кебек күренешләрне нык тәнкыйтьли».
МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ. «КИҢӘШСЕЗ СҮЗ БАШЛАМА...» (ӘСӘН КАЙГЫ ИҖАТЫ).

«Гаҗәп, шушы русча бер сүз әйтә алмаган татар солдатлары арасында мишеньнең күзенә үк бәрүче дә бар икән. Ул ятып атарга тиеш булса да, чүгәләп яки аягүрә басып атарга рөхсәт сорый: «Мин – охотник, ятып аны сукыр да ата…»
ЗАРИФ МӨЭМИНОВ. СОЛДАТ ЙӨРӘГЕ.

ИНДЕКС:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275

www.beznenmiras.ru

Икенче ярты еллыкка почтада язылу бәясе – 498 сум.
Редакциядә язылу бәясе – 380 сум.

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай урамы, 74) сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172

Безнең мирас №04 / 2015